ИЛДАР ЮЗЕЕВ

# Шагыйрь сәхнәсе



**Драмалар, комедияләр**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2002

ББК 84(2Рос=Тат)–6
Ю25

**Илдар Юзеев**

Ю25 Шагыйрь сәхнәсе: Драмалар, комедияләр.— Казан,: Тат.кит.нәшр., 2002.— 191 б.

Шагыйрьнең бу китабына соңгы елларда иҗат ителгән сәхнә әсәрләре тупланды.

ISBN 5-298-01093-8
©Татарстан китап нәшрияты, 2002

# Безнең эти мировой

*Ике пәрдәле комедия*

**Катнашалар**

Габбас Шәйморзин — 44 яшьтә.
Әнисә — аның хатыны, 42 яшьтә.
Люция — аларның кызлары, 18 яшьтә.
Рева — аларның кызлары, 17 яшьтә.
Мирослав — 18 яшьтә.
Мамалеев Аван Казбекович
Мин Ханович
Ким Замович

1960 елларда Казанда булган вакыйга.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бүлек мөдире Мамалеевның кабинеты.

Мамалеев *(телефоннан сөйләшә)*. Шәхсән үзе! Мамалеев! Нинди мәсьәлә? Фатир? Җир астында яшибез? Син аңла, кем, Җамалетдинов абзыкай, хәзергә хәл авыр, киләчәк бер көн, егерме ел үтсә үтәр, синең кебекләр һәммәсе дә җир өстенә менәр! Син аңла: Америка небоскреблары безнең коммунизм корылмалары алдында шырпы кабы кебек кенә калыр! Ун ел көткәнне егерме ел гына көтәрсең, иптәш Җамалетдинов абзый! *(Трубканы куя. Тагын телефон чылтырый.)* Мамалеев! Юк! Фатир юк! Егерме елдан соң булыр, бәлкем?! Син аңла! Без әле 60 нчы елларда гына яшибез! Ә... ә... гафу... иптәш полковник... Шәйморзинны миңа җибәрдегез? Килсен! Һәммәсе уйланылган! Син аңла: чит ил кунагы алдында бөек Ватаныбызның абруен төшермәбез! *(Трубканы куя. Авыз эченнән генә җырлый.)*

Дулкынланып сулар кеpә
Пароход идәненнән...

Эш киеменнән, сакал-мыек баскан Габбас Шәйморзин керә.

Кем кертте? Син аңла: фатир юк! Егерме елдан кил! Кругом марш! Син аңла!

Габбас. Сез мине үзегез чакырттыгыз, иптәш Мамалеев. Мин — Шәйморзин.

Мамалеев *(тора)*. Шәйморзин?

Габбас *(үрә катып)*. Мин!

Мамалеев *(алдындагы «Личное дело»ны карап)*. Шәхсән үзе?

Габбас *(шүрләберәк)*. Мин... үзем...

Мамалеев. Чехословакияне азат итүдә катнашучы Шәйморзин?

Габбас. Нәкъ үзе!

Мамалеев. Беренче Украина фронты?

Габбас. Так точно!

Мамалеев. Командующий?

Габбас. Конев!

Мамалеев. Хәрби комиссариатта булдыгызмы?

Габбас. Булдым.

Мамалеев. Тормыш иптәшегез, балаларыгыз сезнең фронтта кылган батырлыкны беләме?

Габбас. Батырлык дип... бөтен дөньяга күкрәк сугып мактанырлык түгел инде...

Мамалеев. Димәк, гаиләгез белми? Афәрин! Егет икәнсең! Тыйнаклык геройга хас сыйфат!

Габбас. Минем урында һәрбер ир-егет югалып калмастыр дип уйлыйм.

Мамалеев. Һәм дә дөрес! Син аңла: чит ил кунагы нәкъ менә синең шикелле тыйнак та, булдыклы да егеткә килеп ялгышмый. *(Якынаеп, дустанә.)* Хәлең ничек, шәһәребезнең горурлыгы? Син аңла: фатир турында әйтеп торма...

Габбас. Йортларны без үзебез төзибез. Итекченең итеге була димени, иптәш Мамалеев?!

Мамалеев. Менә дөрес! Син аңла: егерме елдан итеге дә, читеге дә булыр!

Габбас. Үзебез генә булмабыз...

Мамалеев. Анысы кечкенә мәсьәлә! Син аңла: без — киләчәк идеаллары белән яшәүче яңа чор кешеләре. Мин, иптәш Шәйморзин, синең кебек фатир сорамаучы аңлы гражданнарны ихтирам итәм, ә андыйлар хәзергесе көндә юк. Инде килеп, төп мәсьәләгә күчик. Син аңла: сине эзләп, күрергә теләп, юкка гына чит илдән килмиләр.

Синең өчен без кулдан килгәннең барысын да эшләрбез. Хәрби комиссариатта әйткәннәрдер — чит ил хәбәрчесе нәкъ сине күрергә килә!

Габбас. Мин аптырап калдым. Нигә миңа килә? Максаты нидә?

Мамалеев. Аптырама! Син аңла: совет кешесенең иң асыл сыйфатлары именно синдә чагыла. Ни әйтсәң дә бернигә карышмаучы, алдынгы карашлы эшче, фронтовик... Ул барысын да фотога төшерер, кайткач газеталарына язар...

Габбас. Иптәш Мамалеев, зинһар, коткарыгыз, мине уңайсыз хәлдә калдырмагыз. Мине сайлап ялгышканнар. Минемчә, шәһәребезнең абруе...

Мамалеев. Күтәреләчәк!

Габбас. Юк! Юк! Минем бик күп кимчелекләрем бар: тәмәке тартам, салам, ачуым килгәндә җиде катлы итеп сүгенәм... эчемнән генә булса да...

Мамалеев. Анысы кечкенә мәсьәлә!

Габбас. Бик нервада уйнаса, хатынымны да кыйнап ташлый алам... Аннан соң әле мин...

Мамалеев. Җитте! Син аңла! Менә мин тәмәке тартмыйм, салуын салам анысы, кул бик кычытса да, хатынымны кыйнамыйча түзәм. Ә ул түзә алмый, явыз! Анысы кечкенә мәсьәлә... Ләкин бит мине эзләп килми хәбәрче, нәкъ менә сине, ә, Шәйморзин! Нинди олы җаваплылык, нинди зур хөрмәт!

Габбас. Юк, булмый! Башканы табыгыз. Ул миңа кая... баракка килсенме? Бөтен дөньяга көлкегә калабыз, иптәш Мамалеев! Килсә, егерме елдан килсен!

Мамалеев. Борчылма, Шәйморзин, синең өчен барысы да уйланылган, хәл ителгән! Көзгегә карап җибәр!

Габбас көзге алдына баса.

Рәзве мировой егет шундый мескен кыяфәттә йөрергә тиеш?!

Кнопкага баса. Ярдәмчеләре килеп керә.

Чишендерегез!

Габбасны тиз генә чишендерәләр.

Габбас. Туктагыз, нишлисез сез? Хатын ни әйтер?

Мамалеев. Дөньяви проблемаларны хәл иткәндә, вак мәсьәләләрне онытып торыгыз! Киендерегез!

Тегеләр Габбасны баштанаяк киендерәләр. Хәзер аның өстендә өр-яңа костюм, кара галстуклы ап-ак күлмәк, башында — эшләпә, кулында — япон зонтигы.

Көзгегә! Таныйсыңмы?

Габбас *(көзгегә карап)*. Сәлам, хөрмәтле иптәш Шәйморзин!

Мамалеев. Тыңла!

Габбас. Тыңлыйм!

Мамалеев. Син аңла: хәзер сиңа бер мин генә түгел, калабыз гына түгел, ә бөтен мир карап тора! Сизәсеңме син шуны?!

Габбас. Сизәм, иптәш Мамалеев!

Мамалеев. Менә сиңа ярдәмчеләр. Син «Айт!» дигәндә, алар «Тайт!» дип торырлар. Җаның ни тели, алар сиңа барысын да табып бирерләр. Итәк астыннан гына түгел, хәтта җир астыннан да! *(Ярдәмчеләргә.)* Мировой егетебезне һәм дә аның гаиләсен игътибар белән чолгап алыгыз. Беренче чиратта... сөйләшкәнчә... барактан күчерегез...

Габбас. Барактан?! Рәхмәт, иптәш Мамалеев!

Мамалеев. Рәхмәт әйтергә ашыкмагыз. Син аңла: анысы егерме елдан. Барысы да вакытлыча...

Габбас. Вакытлыча?

Мамалеев. Әйе. *(Пауза.)* Кунак киткәнче.

Габбас. Кунак киткәнче?!

Мамалеев. Син нәрсә?!

Габбас. Үзем...

Мамалеев. Үзең турында уйлама... Төшендеңме? Син аңла: бу — безнең шәһәребезнең, халкыбызның, илебезнең престижы, киләчәге өчен кирәк. Төшендеңме?

Габбас. Төшендем. Киләчәк өчен яңадан эт күрмәгәннәрне дә күрергә ризамын, иптәш Мамалеев!

Мамалеев. Үтәгез!

Ярдәмчеләр чыгалар.

Киттек аэропортка — кадерле кунакны каршы алырга! Минем арттан!

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Иске баракта Габбас Шәйморзиннар бүлмәсе. Арзанлы гади мебель. Диварда — журналдан кисеп алынган фоторәсемнәр.

Рева белән Люция әтиләрен каршы алырга әзерләнәләр. Люция өстәл әзерли. Рева радиола янында кайнаша.

Рева. Люция!

Люция. Ни бар, Рева?

Р е в а. Монысы ничек булыр?

Л ю ц и я. Үзебезчә берәр маршың юкмы?

Р е в а. Әтигә — мировой көй!

Л ю ц и я. Ишек ачылуга — барабыз да кочаклыйбыз!

Р е в а. Кочаклаганчы, ишек янында почетлы каравылга басып, «Геройга дан!» дип кычкырабыз.

Л ю ц и я. Әй лә... арттырма әле... Орден тагып кайтса да бик җиткән.

Р е в а. Әйтте диярсең, әтинең күкрәгендә Алтын Йолдыз булыр! Военкоматка юкка гына чакырмыйлар. Хәбәрчеләр дә була дип өстәп язганнар.

Л ю ц и я. Кичә чакыру кәгазе килгәч, сөйләп утырды утыруын... Аны бер һөҗүмнән соң, Геройга тәкъдим иткәннәр икән. Бомбежка вакытында документлары юкка чыккан... алдамаса...

Р е в а. Әти алдашмый.

Л ю ц и я. Арттыра торган гадәте бар барын. Әй, медаль тагып кайтса да ярый — җиденче медаль!

Р е в а. Әни күпме әйтте үзенә: «Алты медалең булганчы, бер алтын медалең булсын!» — ие дип.

Көләләр.

Р е в а. Әни үзе ияреп китте.

Л ю ц и я. Әтинең бер дә алып барасы килмәгән иде аны.

Р е в а. Их, Люция. Әгәр дә мин герой кызы дигән дәрәҗәгә ирешсәмме?!

Л ю ц и я. Нишләр идең?

Р е в а. Бәләкәй генә борынымны күккә чөеп, урамнардан «мине күрәсезме?» дигән кебек, малай-шалайларга өстән генә карап узар идем, менә шулай итеп. *(Күрсәтә.)* Кызлар көнләшүдән шартлар иде!

Л ю ц и я. Хыял!

Р е в а. Хыял безнең өчен чит бер нәрсә,
Һәрбер хыял якын киләчәк!

Шушы шигырьне сөйләп, бәйгедә диплом алган Шәйморзина булам мин!

Л ю ц и я. Мактанчык!

Р е в а. Люция, кил әле, колагыңа гына бер сер әйтәм...

Л ю ц и я. Әйт.

Р е в а. Сатмассыңмы?

Л ю ц и я. Юк.

Р е в а. Аллаһи-билләһи! диген.

Л ю ц и я. Аллаһи-билләһи!

Р е в а. Син Аллага ышанмыйсың. «Честное комсомольское» диген.

Л ю ц и я. Мин комсомолга да ышанмыйм.

Р е в а. Кемгә ышанасың?

Л ю ц и я. Үземә. Әтигә, әнигә. Йә, әйт инде сереңне, Рева, әйт?!

Р е в а. Әнигә әйтмисеңме?

Л ю ц и я. Әйтмим инде, әйтмим. Йә...

Р е в а. Мин кичә эчтем.

Л ю ц и я. Лимонадмы?

Р е в а. Белмәдең.

Л ю ц и я. Коктейль?

Р е в а. Юк. Брудершафт.

Л ю ц и я. Нәрсә ул?

Р е в а. Шуны да белмисеңме? *(Бокалларга су сала.)* Мә, тот! Менә шулай эчтек. Аракы!

Л ю ц и я. Син... аракы!

Р е в а. Тс-с-с!

Л ю ц и я. Кемнәр белән?

Р е в а. Үзебезнең педучилище малайлары белән.

Л ю ц и я. Эчкәч нишләдегез?

Р е в а. Эчеп җибәрүгә, күз алларым яктырып китте. Бөтен тәнем рәхәтлек диңгезенә чумды. Шул халәттән чыгасы килмичә, назлы дулкыннарда тирбәлдем, аннары, мин сиңа әйтим, малайларның мут күзләренә карап, өздереп җырлап җибәрдем:

Сөям сине, сөям сине,
Сөям сине, чәчәгем,
Мин сине сөям, чәчәгем,
Мәңгегә сөячәгем! Их!

Л ю ц и я. Аннары?

Р е в а. Аннарымы? Малайларның мине аңламауларына үпкәләп, елап җибәрдем.

Л ю ц и я. Чын сәрхуш кебек сөйлисең!

Р е в а. Аннары киттем биеп, малай, киттем биеп!

Л ю ц и я. Ахыры ничек бетәр моның? Сеңлем, эчмә бүтән, бетәсең бит!

Р е в а. Ахыры болай бетте: самбо алымы белән өч малайның өчесен өч якка очырдым. Алар мине исерек дип уйладылар. Ә мин аракы урынына су эчкән идем.

Л ю ц и я. Әй лә, котны алдың. Чынлап эчкәнсең дип курыктым.

Р е в а. Алла бирсә, чынлап эчкән чаклар да булыр әле.

Л ю ц и я. Самбо дигәне ярый... Әни әйтмешли, кызларга да бер ярап куяр.

Р е в а. Әти әйтмешли, егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

Л ю ц и я. Егеткә әйләнеп барасың түгелме, җаным? Беләм, әтигә ярарга тырышасың.

Р е в а. Дөрес! Мин әтине кызганам. Ул мине малай булыр дип көткән. Мин туар алдыннан исемен дә әзерләп куйган: Рева! Их, үзем бер малай алып кайтырдай булам әтиемә!

Л ю ц и я. Малай алып кайткан чакларың да булыр әле, Алла бирсә, әни әйтмешли...

Р е в а *(тәрәзәдән карап)*. Ура! Әни кайта!

Л ю ц и я. Үзе генә. Әти юк.

Әнисә керә.

Ә н и с ә. Кызлар!

Л ю ц и я. Ни булды?

Р е в а. Әти кайда?

Ә н и с ә. Нишләргә?

Л ю ц и я. Героймы?

Ә н и с ә. Уф Алла!

Р е в а. Кремльгә алып киттеләрме әллә?

Ә н и с ә. Ниләр генә эшләргә?

Л ю ц и я. Черек күлгәме?

Ә н и с ә. Күрәселәр бар икән...

Р е в а. Әти!

Л ю ц и я. Әллә сөенечтән йөрәге...

Ә н и с ә. Хәзер үз йөрәгем ярыла...

Л ю ц и я. Алтын медаль кайда?

Ә н и с ә. Уф... килә!

Л ю ц и я. Кем?

Р е в а. Каян? Кемгә?

Ә н и с ә. Безгә! Баракка!

Л ю ц и я. Нигә? Каян?

Ә н и с ә. Чит илдән?! Хәбәрче!

Л ю ц и я. Чит илдән?!

Р е в а. Хәбәрче?!

Л ю ц и я. Булмас!

Р е в а. Ура! Әни, яшьме, картмы?

Л ю ц и я. Егетме? Кызмы?

Р е в а. Негрмы? Эфиопмы?

Ә н и с ә. Кем икәнен дә, каян икәнен дә белмим.

Л ю ц и я. Кайчан килә?

Р е в а. Сәгать ничәдә?

Ә н и с ә. Туктагыз, сөйләргә ирек бирегез... Бардым ияреп Габбас артыннан хәрби комиссариатка. Көтәм коридорда. Берзаман, мин сиңа әйтим, килеп чыкты бу — күзләре ялтырый, куллары калтырый җаныемның. «Бар, өйгә чап, әзерлән, безгә чит илдән хәбәрче килә!» —

ди. Ә үзен хөрмәтләп, машинага утыртып, каядыр алып киттеләр. Мин өйгә чаптым.

Люция. Башка бер сүз дә әйтмәдемени?

Әнисә. Юк!

Рева. Аны бүләкләргә Кремльгә алып киткәннәр!

Әнисә. Ой, кызлар, харап булабыз! Адәм мәсхәрәсенә калабыз! Шушы баракта! Кияргә җүнле күлмәгем дә юк бит, ичмасам!

Люция. Ә минем? Мехкомбинатта эшләсәм дә...

Рева. Ә минем?

Әнисә. Күпме йорт салып, яшәргә өең булмасын инде?!

Люция. Борчылма, әни, менә үзе герой булып кайткач, барысын да бирерләр.

Рева. Алла бирсә...

Әнисә. Алла бирәм дип торганда да, бирмәгән шәһәр советы бар бит әле аның. Түрәләрдән калтырап торган ул куркакка кем фатир бирсен?!

Рева. Әтигә «Батырлык өчен» медален юкка гына бирмәгәннәр...

Әнисә. Шәхси батырлык өчен бит ул. Үзе өчен генә. Ул батырлыкның безгә бирәр файдасы тидеме? Герой исеме, фактически, миңа тиеш! Габбас Шәйморзин белән егерме елга якын бергә яши алуым өчен. *(Тәрәзәне ача.)* И-и, карагыз инде, кызлар, бөтен дөнья шау чәчәктә!

Люция. Әтине каршы алырга әллә берәр бәйләм чәчәк алып керимме?

Рева. Мин! Мин алып керәм!

Әнисә. Туктагыз! Кирәкми! Ул башта Алтын медален күрсәтсен!

Рева. Ул чәчәкләр ярата. Май җиттеме — тәрәзәне ача да, аккордеонына кушылып, шашып-шашып җырлый...

Люция. Май аенда әллә нишли ул. Уйчан, моңсу, эчүдән-ашаудан туктый...

Әнисә. Мәхлукның шул бер җыры бар инде...

Люция *(көйләп)*. «Каштаннар, каштаннар...»

Әнисә. Онытыгыз әле шуны! Безгә чит илдән кунак килә! Ничек каршыларга? Ничек кунак итәргә? Кайда утыртырга? Нәрсә ашатырга? Йа Алла, буржуйлар алдында хурлыкка калабыз бит... Һинд чәе дә юк! Мәй дә юк... Эчеп бетергән. Социализм дошманнары бот чабып көләрләр инде! Бәет чыгарырлар!

Рева. Фельетон язарлар!

Люция. Таптым! Әни, бездә аларда булмаган, чит илгә чыгарылмый торган нәрсә бар бит...

Ә н и с ә. Нәрсә ул?
Р е в а. Әтине шаштыра торган...
Л ю ц и я. Әтидән яшереп куйган...
Ә н и с ә. Ә-ә-ә, самагон! Ярамас, кызлар, аны куган өчен, Алла сакласын, шушы алачыгыбыздан да куарлар... Нишләргә?
Р е в а. Их, теге әкияттәге кебек, алтын балык йөзеп килсен иде дә: «Җаныгыз ни тели, сорагыз!» — дисен иде икән...
Ә н и с ә. Фәрештәнең «Амин!» дигән чагына туры килсен!

Мамалеевның ярдәмчеләре пәйда була.

М и н  Х а н о в и ч. Җаныгыз ни тели?
К и м  З а м о в и ч. Сорагыз!
Р е в а. Әллә сез әкияттәге чуртан кушуы буенча эш итәсезме?
М и н  Х а н о в и ч. Мамалеев...
К и м  З а м о в и ч. Кушуы буенча!
М и н  Х а н о в и ч. Затлы кунакны каршы алу өчен сезгә иң беренче чиратта...
К и м  З а м о в и ч. Ни кирәк?
Р е в а. Кәнфит!
Л ю ц и я. Күлмәк!
Ә н и с ә. Һинд чәе!
М и н  Х а н о в и ч. Вакланмагыз! Иң беренче чиратта, сезгә чираттан тыш алынган...
К и м  З а м о в и ч. Өй!.. Кирәк!
Ә н и с ә. Анысына ышанмыйм. Егерме елдан булса булыр...
М и н  Х а н о в и ч. Шундый олы кунак килгәндә, нигә егерме ел көтәргә. Без сезне...
К и м  З а м о в и ч. Егерме ел алга...
М и н  Х а н о в и ч. Киләчәккә күчерәбез!

Машина сигналы.

К и м  З а м о в и ч. Киттек!
М и н  Х а н о в и ч. Минем арттан! Алга!
Ә н и с ә. Туктагыз! Чүмеч булса да алыйм инде...
Р е в а. Көзгем...
Л ю ц и я. Тарагым...
Р е в а. Аккордеон! Әти... *(Ала.)*
М и н  Х а н о в и ч. Берни дә алмыйсыз. Ул шуның өчен дә киләчәк дип атала, анда...
К и м  З а м о в и ч. Юк нәрсә — юк!

Көй ритмына ияреп бииләр.
Декорация үзгәрә. Кыйммәтле мебель белән җиһазланган яңа йортның бер бүлмәсе пәйда була.

Мин Ханович. Рәхим итегез! Сез егерме елдан алачак өр-яңа өегездә!

Ким Замович. Оҗмах ишекләре ачык: төкле аягыгыз белән!!

Әнисә. Йа Аллам, күрәселәр бар икән!

Рева. Магнитофон!

Люция. Телевизор!

Әнисә. Келәм!

Рева. Сифон!

Мин Ханович. Кер юу машинасы!

Ким Замович. Суыткыч!

Мин Ханович. Ял итү залы!

Люция. Бакча!

Рева. Беседка!

Мин Ханович. Сауна!

Ким Замович. Кирәк икән ванна... ваннасында Анна...

Мин Ханович *(күз кысып)*. Аз шаула!

Әнисә. Ярабби, ничә бүлмәле соң бу?

Мин Ханович. Ничә катлы диеп сорагыз.

Әнисә. Мин инде беркатлымын. Ничә катлы соң?

Мин Ханович. Ике катлы!

Әнисә. Бу оҗмахта кем яши соң?

Мин Ханович. Җитәкче работниклар! Алар халкыбызны шундый тормышка күчерү алдыннан озак еллар экспримент ясап карадылар. Хәзер алар оҗмахның тагын да югарырак фазасына күчтеләр.

Ким Замович. Вакытлыча.

Мин Ханович. Сиксәненче елларда барлык совет кешеләре оҗмахның беренче фазасына аяк басачак.

Ким Замович. Вакытлыча.

Мин Ханович. Ә хәзергә монда яшәү бәхете сезгә эләкте.

Әнисә. Аллаһе Тәгаләнең кодрәте...

Мин Ханович. Безнең партиябез хезмәт ияләренең тормышын ал да гөл итүгә...

Ким Замович. Зур әһәмият бирә. Совет власте елларында...

Әнисә. Эт оясында яшәдек...

Мин Ханович. Тс...с... Бу турыда ләм-мим! Ә тегеләрдә? Чит илдә?

Ким Замович. Эшләр харап анда! Череп таркалган! Төртсәң аварга тора.

Ә н и с ә. Нигә тәртмибез соң? Хәл юкмыни?

М и н  Х а н о в и ч. Кунак алдында бу хакта ләм-мим! Бу инструктаж сезнең өчен генә... Тагын шуны белегез, аларда җинаятьчелек елдан-ел арта...

К и м  З а м о в и ч. Урамнар караңгы...

М и н  Х а н о в и ч. Чөнки лампочка, шырпы кебек әйберләрне көндез шәм тотып эзләсәң дә табалмыйсың... Ә сезнең люстрадан күзләр чагыла!

К и м  З а м о в и ч. Аларда бүрек киеп чыксаң бүрегеңне, тун кисәң, туныңны салдырып китәләр...

Ә н и с ә. Аларда тун бармыни?

М и н  Х а н о в и ч. Миллионерлар турында сүз бара. Ә менә сезнең кебекләр кулларына талон тотып эзләсәләр дә, кибетләрдә кирәк әйбер табалмыйлар.

Ә н и с ә. Нигә махсус магазиннан алмыйлар икән?

М и н  Х а н о в и ч. Бу хакта кунакка ләм-мим! Менә болар, Әнисә ханым, барысы да шуннан инде, үзегез генә белегез дә, телегезне бик озайтмагыз... Хөрмәтле ханым һәм туташлар, хәзер үзегезне «совет кешесе!» дип әйтерлек кыяфәткә кертегез!

К и м  З а м о в и ч. Чишенегез! Салыгыз!

М и н  Х а н о в и ч. Ягъни баштанаяк киенегез! Әнә теге бүлмәдә үзегез теләгән киемне сайлап алыгыз. Кунак үзегездән күзен алмаслык булсын! Сезгә — биш минут вакыт!

Ә н и с ә *(чыгып китәр алдыннан)*. Әй, сез!

К и м  З а м о в и ч. Боерыгыз, ханым!

Ә н и с ә. Суыткычны яхшы саклагыз! Бушатмасыннар! *(Чыгалар.)*

М и н  Х а н о в и ч. Кара, кара моны, ничек сөйләшкән була. Әкияттәге балыкчы хатыны диярсең... *(Суыткычны ачып.)* Ким Замович!

К и м  З а м о в и ч. Мин Ханыч!..

М и н  Х а н о в и ч *(бокалларга коньяк салып)*.
Без үзебез дөнья җаен
Таба торган егетләр!

К и м  З а м о в и ч. Җае килгән чагында
Каба торган егетләр!

*(Эчәләр.)*

М и н  Х а н о в и ч. Оҗмахка да без кертәбез,
Тәмугка да без!

К и м  З а м о в и ч. Үзебез-шайтан... Һәм үзебез
Фәрештә дә без!

М и н  Х а н о в и ч. Сакта торабыз оҗмахның
Ишек төбендә.

К и м  З а м о в и ч *(ишеккә барып)*.

Кем ул? Юк! Юк! Сезгә оҗмах —
Әнә тегендә! Ха-ха-ха!

Мин Ханович. Үзебезнең — советский:
Оҗмах, тәмуг та!

Ким Замович. Бер типтереп калыйк әле
Хуҗалар юкта!

Мин Ханович. Ким!

Ким Замович. Мин Ханыч, әйт әле, нигә мине эте-бете кимсетә: тегендә — Мамалеев, монда — болар... Нигә мин — Ким, мин кемнән ким?

Мин Ханович. Исем-фамилияңнең койрыгын мин кисмәдем, Хәким Ни-Замович...

Ким Замович. Син дә бит Мөхәммәтәмин Миңнехановиch, Мин Ханыч!

Мин Ханович. И дөрес! На кой чорт безгә, русча не белмес бабаларның дилбегә озынлыгы исемнәре!

Ким Замович. Мин Ханыч! Халык исәнлегенә! Дәүләт исәбенә!

Мин Ханович. Эчмим! Каршы киләм!

Ким Замович. Мин Ханыч, убедительно прошу вас не отказать в моей просьбе! Имзам...

Мин Ханович. Нишләп без халык исәнлегенә эчәргә тиеш? Безнең исәнлек өчен халык эчсен, и баста!

Ким Замович. Мин Ханыч, гениально!

Мин Ханович. Ә беләсеңме ни өчен?

Ким Замович. Мин Ханыч... сездән узып әйтә алмыйм...

Мин Ханович. Халык... бездән башка юк! Без булсак, халык бар, без булмасак...

Ким Замович. Халык юк и булмас та! И баста! Үзебез өчен!

Мин Ханович. То-то!

Ким Замович. Мин Ханыч, убедительно прошу... Гаҗәеп шул матур тавышыгыз белән бер җырлагыз әле... *(Кулына алма ала.)* Теге алманы...

Мин Ханович *(көчәнә)*. Бер алманы бишкә бүләек! *(Чыкмый.)* Давай син!

Ким Замович. Була ул!
Бер алманы бишкә бүлмәем,
Биш алманы үзем ашаем!

Мин Ханович. Афәрин!

Ким Замович. Хан Кимович!

Мин Ханович. Мин? Минме Хан? Хайван!

Ким Замович. Во! Хайван! Менә образлы итеп әйттегез, Мин... Хайванович... әй лә... Мин Ханыч...

Мин Ханович. Айны!

Ким Замович. Сез «хайван» дип дөресен әйтеп бирү белән үк айныдым... Рәхмәт... Хан.... хан... Мин Ханыч... Йөрәккә үтәрлек итеп әйттегез!

Хатын-кызлар тавышы.

Мин Ханович. Полундра!

Затлы киенгән-ясанган хатын-кызлар керә. Кигән киемнәре килешми, шунлыктандыр карачкыга охшап калганнар.

Хөрмәтле хатын-кызларыбыз, үзегезнең киләчәктә киячәк затлы вә кыйммәтле киемнәрегезне күрсәтеп узыгыз!

Хатын-кызлар сәхнәдән үтәләр.

Мин Ханович. Күлмәк...
Ким Замович. Индийский!
Мин Ханович. Шләпә...
Ким Замович. Польский!
Мин Ханович. Сәгать...
Ким Замович. Чистопольский!
Мин Ханович. Җилпәзә...
Ким Замович. Иранский!
Мин Ханович. Джинсы...
Ким Замович. Американский!
Мин Ханович. Духи...
Ким Замович. Французский!
Мин Ханович. Фәрештәләр!
Ким Замович. Хур кызлары!
Әнисә. Кунак алдында хурга калмасак ярый инде...
Мин Ханович. Так точно! Без аларны ничек тотарга өйрәтербез.
Рева. Әни, джинсы килешәме? Кунак ошатыр микән?
Әнисә. Курчактан һич ким түгел... Ә мин буржуйлар алдында башымны менә шулай югары тотарга исәп!
Люция. Мине күрегез, мине!

Көзге алдында бизәнәләр.

Мин Ханович. Хөрмәтле иптәш Шәйморзина, машина сезнең карамакта! Әнә!
Әнисә *(тәрәзәгә карап)*. Минеке?
Мин Ханович. Сезнеке!
Әнисә. Шул кара машинамы?
Мин Ханович. Шул кара машина.
Әнисә. Мин утырырга да хыялланмаган, түрә хатыннары узганда көнләшергә дә базмаган... мин... шуңа утыраеммы?
Мин Ханович. Һичшиксез!

Әнисә. Мин аңа нигә утырам соң? Әллә кая алып китмәсләрме?

Мин Ханович. Борчылмагыз, сезне «ялт!» иттереп китереп куярлар.

Әнисә. Ә мин кая барыйм соң?

Мин Ханович. Кая барасыгыз килә?

Әнисә. Әйтергә дә оялам...

Мин Ханович. Оялып тормагыз.

Әнисә. Машинага утырып бер шәһәрне әйләнергә дигән хыялым бар ие барын...

Мин Ханович. Әйләнегез!

Рева. Мин дә!

Люция. Мин дә!

Мин Ханович. Юк, кызлар, сезгә ярамый!

Ким Замович. Сез монда каласыз.

Әнисә. Минем белән бер җилләнеп килсеннәр әйдә!

Мин Ханович. Мөһим дәүләт эше! Без аларга хәзер инструктаж үткәрәбез.

Рева. Мин риза!

Люция. Нинди инструктаж?

Мин Ханович. Сыйнфый сизгерлегегезне чамалап карыйбыз.

Рева. Мин риза!

Люция. Чамалап?

Әнисә. Алайса минем сизгерлекне дә карагыз.

Ким Замович. Мин Ханович, инструкция бу өлкәдә тәҗрибәсе әзрәк булган яшьрәк кешеләрне күз алдында тота.

Әнисә. Хәерлегә булсын... Кызлар, карагыз аны, мин биргән инструкциядән чыкмагыз! *(Китә.)*

Мин Ханович. Ситуация шундый, кызлар... Абыстай китте. Кая, Ким Замович, фәрештәләр белән бер сайрашып алыйк әле...

Ким Замович. Өстәлгә елышыгыз, сандугачлар!

Рева тиз генә килеп утыра.

Люция. Сез... инструкция дидегез...

Мин Ханович. Инструктаж менә шул инде. Ягъни затлы кунак белән өстәл янында ничек утырырга, ничек аңа ярарга?

Люция утыра.

Рева. Каян алдыгыз шундый тәмле шоколадны?

Ким Замович *(бокалларга коеп)*.

Эчеп җибәр салганны,
Сорама каян алганны! Их!

Рева. Кунак шулай җырлаячакмы?

Мин Ханович. Юк! Болай тупас кыланмас. Ул сүзен менә ничек башлар... *(Кулына бокал тотып.)* Ким Замович, теге кунак ничек күтәрткән иде әле?

Ким Замович *(торып)*. Мөхтәрәм әфәнделәр һәм сөйкемле туташлар! Мин бөтен дөньяны әйләнеп чыгып, сездәй совет кызларыннан да гүзәл затларны күрмәдем. Сезнең энҗедәй ак тешләрегез, беленер-беленмәс кенә тибрәнгән ак түшләрегез, аккошныкыдай саф муенна-рыгыз хөрмәтенә... Нәрсә? Бер тост!

Мин Ханович. Кызлар, басыгыз, эчегез!

Люция. Мин эчмим.

Рева. Мин дә!

Мин Ханович. Кунак моны үзенең дәүләтен хөрмәт итмәү дип кабул итәчәк. Сезнең тарафтан бу сәяси сукырлык... Ягъни илебезнең абруен төшерү... Ягъни ике дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләрне какшатырга омтылу...

Рева. Мин эчәм... брудершафт!

Люция. Мин дә... брудершафт!

Кызлар, эчкән булып яшереп кенә шәрабне түгәләр.

Мин Ханович. Сәяси яктан өлгереп киләсез... Мак-тыйм!

Рева. Мин исердем.

Люция. Мин дә.

Мин Ханович. Исергәнегезне каян беләсез?

Рева. Җырлыйсым килә!

Люция. Минем дә!

Мин Ханович. Рөхсәт!

Рева *(көйләп)*. «Апасыннан матур сеңлесе...»

Люция *(бүлдереп)*. «Сеңлесеннән матур апасы...»

Мин Ханович. Ким Замович, сиңа апасы!

Ким Замович. Мин Ханович, сиңа сеңлесе!

Мин Ханович. Инструктаж үткәрү өчен шәп мо-мент! Ким Замович, сез инструктажны апасы белән ае-рым бүлмәдә үткәрәсез!

Ким Замович. Тыңлыйм, Мин Ханович! Люция иптәш, узыгыз!

Люция. Мин... иптәш түгел!

Ким Замович. Люция, киттек...

Люция. Кермим!

Ким Замович. Мин Ханович?

Мин Ханович. Иптәш Шәйморзина, сез нәрсә, иле-безнең абруен төшерергә уйлыйсызмы?

Люция. Юк, уйламыйм!

Ким Замович. Рәхим итегез.

Икенче бүлмәгә чыгалар.

Рева. Йә?

Ким Замович. Нәрсә йә?

Рева. Башладык!

Мин Ханович. Ягъни? Нәрсәне?

Рева. Инструктажны.

Мин Ханович. Ә...ә... ә... Әйе, Рева, әллә, мин әйтәм...

Рева. Юк, мин әйтәм!

Мин Ханович. Әллә... мәйтәм... инструктаж алдыннан бер... нитеп алабызмы?

Рева. Нитеп?

Мин Ханович. Әйе... нитеп... ягъни...

Рева. Сез дә мин уйлаганны уйлыйсыз икән.

Мин Ханович. Мактыйм!

Рева. Әйдә соң...

Мин Ханович. Без башта кыюлык өчен... нитү алдыннан... нитеп алыйк... Брудершафт?

Рева. Нәкъ шулай. *(Рюмкаларга сала.)* Тотыгыз!

Мин Ханович. Яшәсен Рева-люция!

Рева. Ура! *(Эчкән булып, шәрабны түгә.)* Ничек мин моңа кадәр эчмәгәнмен. Искиткеч рәхәт! Эшли башлагач мин бөтен хезмәт хакымны эчүгә тотачакмын...

Мин Ханович. Нәкъ шулай. Сиксәненче елларның кызлары менә синең кебек кыю булачаклар! Ягъни үзләрен шулай тотачаклар!

Рева. Тотачаклар? Кемнәр тотачак? Без тотканны көтеп тормаячакбыз. Үзебез тотачакбыз! Йә, башлагыз инструктажны, Мин Ханович!

Мин Ханович. Тәк... тәк... син менә бу кәнәфидә тирбәнеп китап укып утырган буласың, янәсе... шулвакыт... янына теге без көткән чит ил хәбәрчесе килеп керә. Но, Рева, искәртеп куям: ул ни тели — син шуны эшләргә тиеш! Аңладың? *(Музыка куя.)*

Рева. Мин һәрвакыт әзер!

Мин Ханович *(чыгып китә дә, кыяфәтен үзгәртеп, кире керә)*. Чао, мадам!

Рева. Мао!

Мин Ханович. Тукта! Кузгалмагыз! Күкрәгегезне ача төшегез! Тагын... тагын... тагын да! *(Ревага якыная.)* Сездә нинди мәкаль бар әле? «Татар тотып карамыйча ышанмый», шулаймы?! Дөрес әйткәннәр сезнекеләр... *(Кызга үрелә.)* Мадам... мадам...

Рева. Надан! Мин мадам түгел!

Мин Ханович. Тс... с... с... Инструктажны бозмагыз... Хәзер, Рева, диван янынарак утырыгыз. Тәк. Шулай. Әйбәт! Сез кунакка кычкыра күрмәгез! Престиж! Ярамый! *(Кунак булып.)* Гүзәл кыз, сезнең яныгызга утырырга мөмкинме?

Рева. Утырыгыз!

Мин Ханович. Йомшак кына әйт. «Утырыгыз...» Кунак теләсә теләмәсә дә, утырырлык булсын. Мөмкинме?

Рева. Утыра бирегез...

Мин Ханович. Әйбәт! Онытма, көнбатышта кызларның гүзәллеген мактап тормыйлар, шундук киемнән тотыналар. О! Бу джинсы сезгә ничек килешә! Сез аны кимәсәгез, тагын да чибәррәк күренер идегез. Тәнегезнең назлылыгын джинсы аркылы да тоеп торам. *(Реваны капшарга тотына.)* О, эфиоп джинсысы! О!

Рева. Эфиопиядән кулыгызны алыгыз!

Мин Ханович. Ярый... ярый... алайса... Европага күчик.

Кызга үрелә. Реваны екмакчы була. Рева кинәт аны самбо алымы белән атып бәрә. Мин Ханович келәмгә барып төшә. Икенче ишектән Ким Замович та аның янына очып төшә. Алар бер-берсенә аптырап карап торалар.

Ким Замович. Хан... мин... Син — Ханович?

Мин Ханович. Мин — Ханович... Ә син... Зам?

Ким Замович. Ким Замович...

Мин Ханович. Рева!

Ким Замович. Люция!

Мин Ханович. Доложить итегез: инструктаж уңышлы тәгәлләндеме?

Ким Замович. Сездән калышмаска тырыштык, Мин Ханович!

Люция керә.

Люция. Шуның белән бетте дәмени?

Әнисә керә.

Әнисә. Әй, дөнья рәхәтләре! Инструктаж? Сез нишләп келәмдә?

Мин Ханович. Келәмнең сыйфатын сыныйбыз... *(Тора.)*

Ким Замович. Шактый каты! *(Тора.)*

Рева. Иптәшләр, шундый уңышлы инструктаждан соң әллә бераз... нитеп алабызмы?

Мин Ханович. Юк, юк, юк! Мөһим чаралар вакытында безгә ярамый! *(Югалалар.)*

Машина сигналы ишетелә.

Люция (*тәрәзәгә бара*). Килде!
Әнисә. Утырышыгыз!
Рева. Машинасыннан төште!
Люция. Джентльмен!
Рева. Маэстро! Итальяно!
Әнисә. Урыннарыгызга!
Люция. Туп-туры безгә килә!
Рева. Өебезгә сокланып карап тора...
Әнисә. Уф, Алла! Сәяси хатадан саклый күр!
Рева. Магнитофон!

Музыка куя. Утырышалар. Ишектә — танымаслык итеп киендерелгән Габбас.

Габбас (*тегеләрне күргәч, аптырап кала*). Чао!
Әнисә. Чего? Кого? Татарчао!
Рева. Чао, джентльмен!
Люция. Чао, камарадо!
Габбас (*бүлмәне карап йөри, өстәл янына килеп, япманы ачып карый.*) Грандиоз! Грацио!
Әнисә (*артыннан бара*). Биш бүлмәле... лоджи!
Габбас. О, лоджи!
Люция. Ванна...
Рева. Душ...
Габбас. Кит аннан! Булмас! Валлаһи-билләһи, диегез!

Барысы да аптырап калалар.

Рева. Әти?!
Люция. Ә без сине...
Әнисә. Шадра шайтан, синмени бу?!
Габбас. Бу мин, кызлар, мин... (*Идәнгә җәелгән келәмгә басарга да кыймыйча, сак кына атлап зур көзге алдына баса.*) Исәнмесез, кадерле Габбас Садыйкович! Ниһаять, сине гомереңдә бер мәртәбә хөрмәтләделәр. Шушы көнгә килеп җитү турында син күпме хыялландың. Кырык дүрт ел гомер итеп, шушы башыңа бер тапкыр эшләпә алып киялмәдең, атаңнан, абыеңнан калган иске бишмәттән, гимнастеркадан, шинельдән башка җүнле кием күрмәдең, күпме адәмнәрне өйле итеп, үзеңә бер куыш салалмадың, гел хыял эчендә яшәдең. Хакың бар идеме адәмчә бер тормыш күрергә? Әллә юкмы? Бар хакың, хөрмәтле иптәш Шәйморзин, бар! Сәлам! Чао!
Люция. Әти, чит ил кунагы кайда?

Габбас. Самолет соңлый. Фатирны күрергә дип, тиз генә машинада кайттым. Хәзер китәм.

Рева. Әти, герой булдыңмы?

Габбас. Шул чама.

Рева. Әйттем бит!

Люция. Котлыйм, әти!

Рева. Нинди вакыйга өчен?

Габбас. Чехословакия. 1945.

Люция. Әти, сөйлә!

Рева. Сөйлә!

Габбас. Хәзергә вакыт юк... Шунда... бер һөҗүм өчен инде...

Люция. Нинди һөҗүм?

Рева. Кемгә?

Габбас. Гап-гади бер һөҗүм...

Рева. Әти, тыйнак булып кыланма. Бәлки, син күкрәгең белән дошман амбразурасын каплагансыңдыр?

Габбас. Амбразура түгел түгелен. Тик шул чама... Сез хатын-кыз халкы аңларлык түгел! Катлаулы!

Рева. Берүзең бик күп фашистларны дөмектергәнсеңдер, әти, шулаймы?

Габбас. Юк. Үтергән өчен түгел. Киресенчә.

Люция. Ничек киресенчә? Үтермәгән өченме?

Габбас. Әйе! Әйе! Әллә сез, сугыш дигәч тә гел үтереп, штык белән кадап, чәнчеп кенә йөриләр дисезме?

Әнисә *(озак карап, күзәтеп торганнан соң)*. Габбас!

Габбас *(куркып китә, урә катып)*. Тыңлыйм!

Әнисә. Кил әле яныма!

Габбас. Килдем.

Әнисә. Утыр.

Габбас. Утырдым.

Әнисә. Карале күзләремә.

Габбас *(күзләрен читкә алып)*. Карадым.

Әнисә. Күзләреңне нигә яшерәсең?

Габбас. Яшермим, менә ич... тутырып карыйм...

Әнисә. Кызлар, сез дә утырыгыз. *(Габбасны урап алып утыралар.)* Әйт хәзер: син героймы, түгелме?

Габбас. Кем ничек карый бит...

Әнисә. Ничек?

Габбас. Мин үземне, мәсәлән, герой итеп тоям.

Әнисә. Тоясың?

Габбас. Тоям... шикелле... сыман...

Әнисә. Алты медалеңне унҗиде ел күреп торам. Алтын медалең кайда?

Габбас. Алтын медаль алмыйча да геройлык күрсәтергә мөмкин әле.

Әнисә. Документ?!

Габбас. Документ?! Әлегә юк...

Әнисә. Кайда?!

Габбас. Батырлык күрсәткән җирдә. Тиздән кайтып җитәр, диделәр.

Әнисә *(Габбасның өстенә бара.)* Шадра шайтан, нинди батырлык кылдың, ә?! Әйтәсеңме, юкмы?!

Уратып алалар.

Габбас *(чыдамлыгы бетеп, сикереп тора)*. Сез нигә миннән гестапо сымак сорау аласыз?! Фашистлар кулына эләгеп тә Габбас Шәйморзиннан бер сер алалмадылар! Бәлки, минем кылган батырлыгым хәрби сердер! Бәлки, ул серне үз хатыныңа, балаларыңа әйтергә ярамыйдыр? Килер бер көн: кайчандыр яшерен саналган серләр ачылыр... Бәлки, әле Габбас Шәйморзинны берзаман мировой масштабтагы герой дип сагынып, елап искә алырлар. *(Кычкырудан туктап, әкрен генә.)* Сезгә генә серенең бик кечкенә өлешен ачам: бәлки, минем геройлыкны әлегә халыктан яшерергә кирәк булгандыр? Бәлки, ул бүгенге хәбәрдарлык рамкаларына сыймый торгандыр? Шуңа күрә сез дә минем серемне берәүгә дә, беркемгә дә ачмагыз... Төшендегезме? *(Машина сигналы.)* Мин — аэропортка! Көтегез! Сынатмагыз! Чао! *(Чыга.)*

Әнисә. Тәмам бутады башны, берни дә аңламыйм.

Рева (табын янына килеп). Әни, түзәр хәл калмады, ачыктым... *(Шоколад ала.)*

Люция *(тартып алып, кире куя)*. Читләр өлешенә кермә, бер тамагыңа хуҗа бул!

Әнисә. Гомер буе ачлы-туклы яшәп, күпкә түзгәнне әзгә генә түзегез инде, балалар!

Рева. Әни, фокус! *(Өстәлдәге япманы ача.)* Ой!

Люция. Әфлисун! Йөзем!

Әнисә. Кара икра, кызыл икра!

Рева. Әрмән коньягы!

Әнисә. Оҗмахның...

Люция. Беренче фазасы!

Әнисә. Ни өчен Ходай Тәгалә күпләр арасыннан безне генә якын күреп, оҗмахка кертеп куйды икән? Әллә безнең гомер буе газап чигеп яшәвебезне күреп кызганды инде... Тәмам хур кызларына әйләндек бит.

Рева *(йөземне кабып)*. Телне йотарлык!

Люция. Әбәү, тәмсез! Икра... Тфү!

Ә н и с ә. Кызлар, бер генә локма ризыкка да кагыласы булмагыз! Ул безгә түгел, чит ил кунагына. Соңыннан рәхәтләнеп ашарбыз... калса...

Р е в а. Калмаса?..

Ә н и с ә. Утырыгыз әле табынга. Репетиция ясап карыйк. Кунак алдында мин сезне үтереп кыстаган булырмын, яме? Ә сез?

Л ю ц и я. Рәхмәт, ашыйсым килми...

Р е в а. Мерси! Их бин нихт ессен...

Ә н и с ә. ...дигән булырсыз.

Р е в а. Ярый, әни.

Л ю ц и я. Түзәргә тырышырбыз. Синең үзеңне дә кыстыйкмы?

Р е в а. Кыстыйбыз!

Ә н и с ә. Кыстый күрмәгез, онытып җибәреп, өстәлдәге бөтен ризыкны харап итәрмен. Ходай безнең һәммәбезгә аерым-аерым түземлек бирсен! Аллага шөкер, сезнең авызларыгыз уймак кебек кенә, үземә охшагансыз, балакайлар! *(Табынны ябып куя.)* Кызыктырып тормасын!

Рева *(күреп)*. Телефон! Нигә безгә беркем дә шылтыратмый?

Л ю ц и я. Җүләр, бездә телефон барын кем белә!

Р е в а. Барак кызлары нишләп яткан була икән, месkeннәр?

Л ю ц и я. Борчылма, алар да егерме елдан безне куып җитәрләр.

Р е в а. Ә без ул чакта тагын егерме елга алга киткән булырбыз!

Л ю ц и я. Кызлар мине күргәч танымаслар да инде.

Кыңгырау тавышы. Үз урыннарына утыралар.

Рәхим итегез!

М и р о с л а в керә. Гади генә киенгән. Иңендә — фотоаппарат.

М и р о с л а в. Исәнмесез?

Тегеләр рәсми тонда, теләмичә генә исәнләшәләр.

Мин ялгыш кермәдемме?

Ә н и с ә. Ни йомыш? Безгә зур кунак киләсе... син аяк астында бик буталып йөрмә инде, энекәш!

М и р о с л а в. Гафу итегез. Бу — Шеймурзин фатирымы?

Ә н и с ә. Дөрес кергәнсез. Узыгыз!

М и р о с л а в. Рәхмәт. Шеймурзин үзе кайда соң?

Ә н и с ә. Мөһим дәүләт эше белән китте.

М и р о с л а в. Сезнең үзегезне кем дип белик?

Ә н и с ә. Без үзебез Шәйморзинның, китапча әйткәндә, тормыш иптәше, искечә әйткәндә, җәмәгате, дөресен әйткәндә, хатыны булабыз.

М и р о с л а в. Шеймурзин өйләнгән кешемени? Уйламаган идем.

Р е в а *(Әнисәнең колагына)*. Казан хәбәрчесе...

Ә н и с ә. Ул да уйламаганда өйләнде. Фронттан кайтты да, шушы биш айлык Люция кызым белән тотты да алды. Әмма хатыныннан бик уңды.

М и р о с л а в. Бу кызлар Шеймурзинның балалары? Гаҗәп!

Ә н и с ә. Алар минеке дә!

М и р о с л а в. Гаҗәп! Көтмәгән идем...

Ә н и с ә. Әллә сез минем герой-иремне бала тудырырга да сәләтсез дип уйлыйсызмы?

М и р о с л а в. Юк, Шеймурзина ханым, киресенчә...

Ә н и с ә. Ничек киресенчә?

М и р о с л а в. Бу өлкәдә зур уңышларга ирешкән димәкче булам.

Ә н и с ә. Иреште, бик иреште, Аллага шөкер. Без аның белән горурланабыз.

Р е в а. Ул минем малай булуны бик теләгән.

М и р о с л а в. Сез Шеймурзинны теләгенә ирешә алмас дип уйлыйсызмы?

Ә н и с ә. Соң инде... Аның өчен сугышта герой булу гына җитми.

М и р о с л а в. Мин Шеймурзинга ышанычымны югалтмыйм.

Л ю ц и я. Әллә сез безнең әтине беләсезме, иптәш хәбәрче?!

М и р о с л а в. Кызганыч, минем аны күргәнем юк. Әмма бик күрәсем килә. Сез минем шәһәр хәбәрчесе икәнне каян беләсез? Кем дип әйтим...

Р е в а. Рева.

М и р о с л а в. Рева сеңлем...

Л ю ц и я. Люция.

М и р о с л а в. Люция сеңлем...

Ә н и с ә. Әнисә.

М и р о с л а в. Әни... сә? Таныш булыйк: шәһәр газетасының штаттан тыш хәбәрчесе Мирослав.

Ә н и с ә. Сез, иптәш, чит ил кунагы килгәнче, тормыш шартлары белән таныша торыгыз. Менә без шулай яшибез инде! Яхшы яшибез!

М и р о с л а в *(исе китмичә генә карап йөри дә, аккордеон янында туктап кала)*. О, аккордеон!

Ә н и с ә. Игътибар итмәгез. Иске ул... сугыш трофее... Безнең барысы да өр-яңа! Карагыз! Телефон да бар!

М и р о с л а в. Тотып карарга мөмкинме?

Р е в а. Мөмкин!

М и р о с л а в *(кулына гармунны ала да әкрен генә уйный, аннары җырлый)*.

Каштаннар, каштаннар,
Җылы язда бөреләнеп
Чәчәкләрен ачканнар.
Каштаннар, каштаннар,
Нурда коенырга теләп,
Зәңгәр күккә ашканнар.
Каштаннар, каштаннар,
Язларың да, назларың да
Йөрәккә тоташканнар.

Җырга Люция белән Рева да кушыла.

Л ю ц и я. Сез әти җырын каян беләсез?

М и р о с л а в. Әти җыры? Юк, бу әтиләр җыры гына түгел, әниләр җыры да.

Ә н и с ә. Табынга игътибар итегез, иптәш! *(Табынның өстен ача.)* Без менә шушылай яшибез инде, энекәш! Җаныбыз ни тели, шуны ашыйбыз, эчәбез! Балда-майда йөзәбез! *(Табынны ябып куя.)* Аллага шөкер, җитмәгән нәрсәбез юк! Блокнотыңа язып куй! Өебез дә стадион кебек!

Машина сигналы ишетелә.

Л ю ц и я. Әти кайта!

Р е в а. Кунакны алып кайта! Әтиебез!

М и р о с л а в. Әтиебез?!

Г а б б а с кайтып керә.

Р е в а. Әти, безгә хәбәрче килде!

Ә н и с ә. Кайда чит ил кунагы?

Г а б б а с. Самолет килгән... Каршыларга өлгермәдем...

М и р о с л а в. Шеймурзин Аббас?

Г а б б а с *(хәвефкә төшеп)*. Әйе... мин... Шәйморзин Габбас...

М и р о с л а в. Мин сезне чит илдән, Чехословакиядән эзләп килдем...

Р е в а. Чит илдән?

Л ю ц и я. Чехословакиядән?
Ә н и с ә. Эзләп... килдең?
М и р о с л а в. Мин... синең улың... Мирослав. Исәнме, эти?

Габбаска таба атлый. Туктап кала. Барысы да бер мизгелгә хәрәкәтсез басып торалар.

П ә р д ә

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук фатир. Шул ук күренеш. Г а б б а с , Ә н и с ә , Л ю ц и я , Р е в а , М и р о с л а в.

Ә н и с ә. Әти?! Нинди әти?
Р е в а. Ул минем әти!
Л ю ц и я. Ул минем дә әти!
Ә н и с ә. Ул — безнеке!
М и р о с л а в *(уңайсызланып)*. Гафу итегез... Бәлки, мин ялгышамдыр...
Ә н и с ә. Ялгышасыз, ялгышасыз... *(Габбаска.)* Нигә катып калдың? Әйт ялгыш килгәнсең дип... *(Габбас дәшми.)* Әйт, Габбас җаным, әйт!
М и р о с л а в. Сез 1945 елның маенда Наход каласын фашистлардан азат итүдә катнаштыгызмы?
Г а б б а с. Катнаштым.
Ә н и с ә. Анда миллион Шәйморзин катнашкан. Шулаймы, Габбасик? Ник дәшмисең? Әллә шулай түгелме?
Г а б б а с. Анысы — хәрби сер.
М и р о с л а в. Сез госпитальдә яттыгызмы?
Ә н и с ә. Ятмады, ятмады!
М и р о с л а в. Яттыгызмы?
Ә н и с ә. Габбас җаным, ятмадың бит?
Г а б б а с. Яттым!
М и р о с л а в. Шунда сезне дәвалаган унсигез яшьлек шәфкать туташын хәтерлисезме?
Ә н и с ә. Юк, юк, хәтерләми! Мин үзем дә шәфкать туташы... миллион кеше дәваладым, тик берсе дә эзләп килми...
М и р о с л а в. Хәтерлисезме, Орлицкий тауларын?!
Г а б б а с. Орлицкий таулары? Наход каласы? *(Ерактан әкрен генә таныш көй ишетелә.)*

М и р о с л а в. Сез әле әнигә менә шундый җыр җырлагансыз. Хәзер аны бөтен шәһәр белә. *(Рева аңа аккордеон суза. Мирослав уйнап җырлый.)*

Каштаннар, каштаннар...

Г а б б а с *(түзә алмыйча кушыла)*.

Каштаннар, каштаннар...
Җылы язда бөреләнеп
Чәчәкләрен ачканнар.

Люция белән Рева да кушыла.

Каштаннар, каштаннар,
Әллә инде минем сыман
Каштаннар да шашканнар.
Каштаннар, каштаннар,
Йөрәк серен ачканнар да
Үкси-үкси качканнар...

Әнисә кызганыч кыяфәттә бер читтә басып тора.

Г а б б а с *(кочагын җәеп Мирославка таба бара)*. Улым! *(Кочаклый.)*

М и р о с л а в. Әти! Мин сине күрү турында гомерем буе хыялландым...

Әнисә кызларын икенче бүлмәгә алып кереп китә.

Г а б б а с. Кичер мине, балам... Мин сине күрермен дип уйламаган да идем. Төшләремә керә идең керүен...

М и р о с л а в. Мин сине төшләремдә зур гәүдәле, озын буйлы баһадир итеп күрә идем.

Г а б б а с. Чәчләрең нәкъ минеке сыман саргылт, йомшак... *(Башыннан сыйпый.)*

М и р о с л а в. Нинди рәхәт... Тагын бер генә чәчләремнән сыйпа, әти. Башкаларны әтиләре иркәләгәндә, мин качып елый идем.

Г а б б а с. Хәзер сине беркем дә кимсетә алмас... Әниең исәнме, Мирослав?

М и р о с л а в. Исән-сау.

Г а б б а с. Сез икегез генә яшисезме?

М и р о с л а в. Без — дүртәү.

Г а б б а с. Тагын кемнәрегез бар?

М и р о с л а в. Тагын бер әти. Тагын бер сеңлем.

Г а б б а с. Ул... бәхетлеме?

Мирослав. Без бәхет турында сөйләшмичә генә яшибез, әти.

Габбас. Әйе, шулайдыр шул...

Мирослав. Әти, син минем әнине чынлап та яраттыңмы?

Габбас. Яратмасам, син булыр идеңмени? Улым...

Мирослав. Син минем дөньяда барлыгымны белдеңме?

Габбас. Мин синең йөрәк тибешеңне тоеп киттем. Юк, мин китмәдем. Мине хәрби часть белән алып киттеләр.

Мирослав. Димәк, син миннән баш тартмыйсың, Шеймурзин?

Габбас. Юк. Үз балаңнан ничек баш тартмак кирәк?!

Мирослав. Димәк, әни сине юкка гына яратмаган, син аның мәхәббәтенә лаек.

Габбас. «Әти!» дип, бөтен дөньяга кычкырып әйтәләсең, улым Мирослав. Сине әниең җибәрдеме, әллә үзең мине эзләп килдеңме?

Мирослав. Мин сине үзем эзләп килдем, әти.

Габбас. Әниең?

Мирослав. Әни миңа унсигез яшь тулуны өзелеп көтте. Бездә шундый гадәт бар: атасыз үскән бала, унсигез яше тулгач, үзенең әтисен эзләп табарга тиеш. Әтисе аны эзләмәсә дә... Үз баласы итеп танымаса да, ул аны гомерендә бер тапкыр булса да күреп китәргә тиеш. Әти, әйт әле, нигә сез, бер-берегезне яраткан ике яшь кеше, кавыша алмадыгыз?

Габбас. Бу сорауга мин үзем дә гомерем буе җавап эзлим. Нигә без кавыша алмадык? Замана, дәүләт кануннары безгә «Ярамый!» диделәр, арабызга тимер пәрдә кордылар. «Ярамый!», «Ярамый!», «Ярамый!» Безнең мәхәббәтебез шәфкатьсез чор язган кыргый кануннарның корбаны иде. Мине чех кызын ятратканым өчен гаепләделәр, җәзага тарттылар, аңардан баш тартырга мәҗбүр иттеләр.

Мирослав. Син безнең илебезне фашист өереннән азат иткән герой. Ни өчен соң син шул кешелексез канунлардан да дөньяны азат итмәдең?

Габбас. Үзебезнең дәүләт канунларына без икебез дә сукырларча табына идек, Мирослав. Димәк, минем геройлыгым дошманга каршы көрәшкәндә генә күренгән. Мәхәббәт корбаннар сорый!

Мирослав. Юк, әти, миңа синең исән булуың кадерлерәк. Мин әти кешеләрне, нәкъ менә синең кебек итеп, күз алдыма китерә идем.

Габбас. Күз тимәсен, гел үземнең яшь чагыма охшаган егет булып өлгергәнсең! Әнисе! (Әнисә керә.) Рева! Люция! *(Керәләр.)* Менә... ир туганыгыз килгән. Мирослав...

Мирослав. Шеймурзин.

Габбас. Мирослав Шәйморзин! (*Тегеләр аптырап карап торалар.)*

Рева *(сөенеп)*. Исәнме, абый?

Габбас. Рева сине абыең итеп таныды. Люция?

Люция. Исәнмесез... *(Әнисәгә карый.)* Шәйморзин.

Габбас. Тагын бер кызым туганы итеп таныды. Факт! Әнисе? Әнисә, хәзер эш синдә калды...

Мирослав. Әни?

Әнисә. Мин... Әни... сә!

Габбас. Дөрес! Мирославның да әнисе!

Мирослав. Әни...сә, сезгә Чехословакиядә калган әни... сәдән сәлам!

Габбас. Вәгаләйкем әссәләм!

Әнисә. Габбас, җаным, шулай ук синнән колак кагармын микәнни? Юк, мин сине читләргә бирмим! *(Габбасның кулларыннан тотып.)* Бирмим! Син үзебезнең... советский әти!

Рева. Әни, безнең әти советский гына түгел, безнең әти — мировой!

Габбас *(Әнисәне читкәрәк алып китеп)*. Хөрмәтле тормыш иптәшем... Онытма, бу минутларда безгә бөтен дөнья карап тора! Иреңнең генә түгел, илеңнең киләчәге турында да уйла! Мамалеев... *(Ымлап квартираны күрсәтә.)*

Әнисә *(аңлап, уйнап)*. Хуш киләсез, төкле аягыгыз белән, чит илләрдән килгән...

Габбас. Балабыз...

Әнисә. Балагыз... *(Габбас ишетелерлек итеп кенә.)* Шадра шайтан, күрсәтермен әле мин сиңа күрмәгәнеңне!

Габбас. Балабыз Мирослав...

Әнисә. Балабыз кебек кадерлебез Мирослав! *(Габбаска.)* «Сине генә яратам», имеш... Иблис! *(кычкырып)* Әтисе, чит илләрдән килгән кунакны табынга чакыр! Рәхим итегез, Мирослав! *(Габбаска.)* Кунагың гына китсен, кызган табага бастырам әле мин сине!

Мирослав. Таба дидегезме?.. Аңламадым...

Әнисә. Коммунизмга таба барабыз димәкче идем... Хөрмәтле тормыш иптәшем, сез дә утырыгыз... *(Габбаска.)* Җаныңны алам әле мин синең, егерме ел яшереп йөргәнең өчен!

Мирослав. Җаныңны... Нинди матур сүз!

Ә н и с ә. Без шулай аның белән «җаным-бәгърем» дип кенә сөйләшәбез инде, гаеп итмәссез. *(Табын өстен ачып җибәрә.)* Шушы әтиебез аркасында без менә шул хәлләргә ирештек инде, Мирослав! Аллага шөкер, шәһәр советы безнең хакта бик кайгырта. Тормышыбыз ал да гөл! Социализмның аргы ягына чыгып, аяк салындырып утырабыз. Шушындый зур уңышларга ирештек әтиебез аркасында!

М и р о с л а в. Мин дә үземне киләчәктә яшәгән кебек хис итәм.

Г а б б а с. Дөрес, улым... Фактически без бүген мең дә бер йөз алтмышынчы елларда түгел, туксанынчы елларда яшәп ятабыз! Барлык мәсьәләләр хәл ителгән!

М и р о с л а в. Урамнарыгыз, ишегаллары да чиста булса...

Г а б б а с. Күзләреңә ялгыш күренгәндер, бездә чүп савытлары да юк. Ни өчен дигәндә...

Р е в а. Ташларга чүп юк...

Ә н и с ә. Иске-москы үзебездән дә артмый...

М и р о с л а в. Бараклар да булмаса...

Г а б б а с. Бараклар? Аларда яшәмиләр бит...

Ә н и с ә. Хезмәт ияләре менә шундый хәлдә яшәгән заманнар да булган дип күрсәтү өчен генә саклыйлар аларны...

Р е в а. Безнең ярты шәһәр музей!

Г а б б а с *(бокалларга коеп)*. Безгә күрмәгәннәрне күрсәтүче шәһәр советы яшәсен!

Ә н и с ә *(Габбаска)*. Күрмәгәннәреңне күрсәтермен әле! Яшәсен Мамалеев!

Ишектә Мамалеев ярдәмчеләре пәйда була.

М и н Х а н о в и ч *(укый)*. Интернациональ максат белән безгә килгән хөрмәтле Мирослав иптәш!

К и м З а м о в и ч *(укый)*. Шәһәр советы сезне безнең калабызга аяк басуыгыз белән...

М и н Х а н о в и ч. Кайнар котлый!

К и м З а м о в и ч. Яшәсен безнең халыклар арасындагы корычтай, тимердәй дуслык! *(Чәчәк бәйләме бирәләр.)*

М и р о с л а в. Рәхмәт. Мин бик шат.

М и н Х а н о в и ч. Кадерле Мирослав... фамилиягезне...

М и р о с л а в. Шеймурзин.

М и н Х а н о в и ч. Шәйморзин? Шаян кеше икәнсез... Хе-хе-хе...

Ким Замович. Без сезне коммунистик калабыз белән таныштырырбыз.

Мин Ханович. Сез, иптәш Шәйморзин...

Габбас. Кайсы Шәйморзин? Кунакмы?

Мин Ханович. Бутамагыз. Сезнең хакта сүз бара. Ягъни сез үзегезнең шәхси машинагызда...

Габбас. Шәхси? Минем?

Мин Ханович. Үзегезнең шәхси машинагызда барырсыз.

Ким Замович *(пышылдап)*. Вакытлыча...

Рева. Ә мин?

Люция. Мин?

Мирослав. Мөмкин булса, мин үземнең әти, әни һәм туганнарым белән бер машинада барыр идем...

Мин Ханович. Әти? Әни? Сез үзегез генә килмәдегезмени?

Ким Замович. Мирослав иптәш юморист...

Мин Ханович. Интернациональ туганлык... аңлашыла...

Мирослав. Миңа үз әтиемне табып бирүегез өчен, сезгә бик зур рәхмәт! *(Тегеләр аптырап бер-берсенә карашалар.)* Киттек, әти, туганнар!

Сәхнә караңгылана. Ут яктысында шәүләләр күренә, тавышлар ишетелә.

Габбас. Сез мине кая алып килдегез?

Мин Ханович. Тәмугка!

Ким Замович. Онытма, Шәйморзин, безнең оҗмахыбыз булган кебек, тәмугыбыз да бар.

Габбас. Сез әллә Нәнкир белән Мөнкирме? Мин сезне оҗмахта күргән кебекмен. Анда, ялгышмасам, сез фәрештәләр идегез...

Мин Ханович. Таныдың.
Кирәк булганда — фәрештә,

Ким Замович. Кирәк чакта — шайтан без!

Мин Ханович. Терә, ныклабрак терә диварга!

Ким Замович. Терәдем!

Мин Ханович. Әгәренки булса, җанын ал! Анда чит системага бала үрчетеп йөрмәсен!

Ким Замович. Җавап бир, бәдбәхет, гөнаһ кылу өчен үзебездә мөмкинлек юкмыни?

Габбас. Минем тамчы да гаебем юк. Оҗмахка кире илтегез!

Мин Ханович. Оҗмахка? Ха-ха-ха!

Ким Замович. Гөнаһы юк! Хи-хи-хи...

Мин Ханович. Билетын ал!
Ким Замович. Билетыңны өстәлгә!
Габбас. Мәгез!
Мин Ханович. Әһә, гаебеңне таныйсың?!
Габбас. Мин кем алдында гаепле?
Мин Ханович. Безнең алда.
Габбас. Минем иблисләр белән бернинди дә алышбирешем юк.
Мин Ханович. Син безне иблисләр белән тиңлисең?!
Ким Замович. Олы сәяси хата!
Мин Ханович. Ваз кич гөнаһыңнан!
Ким Замович. Тәүбә ит!
Мин Ханович. Җавап бир, син капиталистик сиситемадагы хатын белән эш иттеңме, юкмы?!
Габбас. Мин аны яраттым!
Мин Ханович. Эш иттеңме, юкмы?
Ким Замович. Бала ясадыңмы?
Габбас. Әйе, безнең балабыз бар. Мин аны үз балам итеп таныйм.
Мин Ханович. Баш тарт балаңнан!
Ким Замович. Ваз кич!
Габбас. Ул минем балам!
Мин Ханович. Ах, шулаймы? Тәмугка!
Ким Замович. Тәмуг ишекләре ачык!
Мин Ханович. Яндыр тәмуг утын! Тиз!
Ким Замович. Янмый!
Мин Ханович. Янмый?! Сәбәбе?
Ким Замович. Ягулык юк...
Мин Ханович. Күршеләрдән сорадыңмы?
Ким Замович. Файдасыз. Бөтен системада юк.
Мин Ханович. Шеф, нишләргә боерасыз?

Мамалеев күренә.

Мамалеев. Ягулык тапканчы, хатыны янына озатыгыз. Бәлки, хатыны акылга утыртыр... Киткәнче чукмар белән тагын бер тондырыгыз! *(Габбас кычкыра.)*

Яктыра. Габбас, эшләпәсе белән күзләрен каплап, өйдә кәнәфидә утыра.

Әнисә. Әй, шадра шайтан, ник акырасың? Уян!
Габбас. Мин кайда? Аллага шөкер, синең янга кайтып җиткәнмен икән. Саташып уяндым... Авыр миңа, Әнисә!
Әнисә. Шулай инде... Ике хатын белән яшәү җиңел

түгел. Карт иблис! Кара аны, икенче чит ил дип авызыңны ачасы булма! Алла бирсә, аяк та атлатмыйм. Синең әле, кем белә, бәлкем башка илләрдә дә балаларың бардыр?! Әллә чынлап та шулаймы, җирбит?! Җаныңны алыр идем алуын, тик җаныңны дөнья чибәрләренә өләшеп бетергәнсең... Мәлгунь, кыяфәтсез, адәм гыйбрәте, карачкы... (*Й о м ш а к к ы н а.*) Габбас җаным, ни булды, әллә берәр күңелсез хәбәр бармы?

Г а б б а с. Тегендә... кысалар, имансызлар!

Ә н и с ә. Кемнәр?

Г а б б а с. Мамалеевлар.

Ә н и с ә. Ни диләр?

Г а б б а с. Без сине күпме еллар Алланың кашка тәкәсе урынына тоттык, диләр...

Ә н и с ә. Кашка тәкә? Син? Ни дигән сүз ул?

Г а б б а с. Ялган шөһрәтеңне тудырып гел түрдә йөрттек, диләр. Кадерен бел, диләр. Мине капиталистик илгә барачак делегация составына кертмәкчеләр...

Ә н и с ә. Юк! Юк! Юк!

Г а б б а с. Безнең эшчеләрнең нинди яхшы шартларда яшәве турында сөйләрсең, диләр. Мондый биография белән бара алмыйсың, балаңнан баш тарт, диләр...

Ә н и с ә. Баш тартмасаң?

Г а б б а с. Егерме елдан соң да рәхәт күрсәтмәбез, диләр!

Ә н и с ә. И Алла, бар икән күрәселәр...

Г а б б а с. Синең белән киңәшергә кайтардылар. (*Машина сигналы.*) Анда... көтеп торалар... (*Ишекле-түрле йөри.*) Нишләргә, Әнисә?

Ә н и с ә. Гомереңдә бер тапкыр үз башың белән уйлап, хәл ит!

Г а б б а с. Хәл иттем.

Ә н и с ә. Әйт!

Г а б б а с. Миңа бит бер җөмлә әйтү җитә: ул минем... бала... түгел... Шуннан соң без авыр тормыштан котылабыз...

Ә н и с ә. Шулай әйтәсеңме?

Г а б б а с. Синең, балаларның бәхете өчен... кирәк икән...

Ә н и с ә. Габбас, синме бу?

Г а б б а с. Мин.

Ә н и с ә. Юк, бу — син түгел...

Г а б б а с. Бу — мин, Әнисә.

Ә н и с ә. Мирославның әнисен син чынлап яраттыңмы?

Г а б б а с. Чынлап.

Ә н и с ә. Мирославның үз балаң икәнлегенә бер шигең дә юкмы?

Г а б б а с. Юк! Юк! Юк!

Ә н и с ә. Син сугыштан кайткач, биш айлык Люцияне күтәреп, синең өеңә килдем. Син аны да үз кызың кебек яраттың. Аннан Рева туды. Хатын-кыз йөрәге сизә бит: син малай тели идең... Әмма мин сиңа ир бала бүләк итә алмадым. Гаиләбезгә нидер җитмәвен сизеп, синең алдыңда үземне гаепле тоя идем. Аллага шөкер, дөньябыз түгәрәкләнде... малаең...

Г а б б а с. Әнисә, тагын кабатла шул сүзеңне... Малаең, дидеңме?

Ә н и с ә. Малаебызны... дип тә әйтер идем әйтүен...

Г а б б а с. Нидән куркасың, әнисе?

Ә н и с ә. Син герой белән яшәп, үзем дә куркакка әйләнеп беттем инде. Куркам, Габбас!

Г а б б а с. Нидән куркасың?

Ә н и с ә. Мине, безне ташлап, малаең белән бергә чит илгә китеп барсаң?

Г а б б а с. Минме?

Ә н и с ә. Син!

Г а б б а с. Чит илгә?

Ә н и с ә. Чит илгә.

Г а б б а с. Их, Әнисә, миңа да ышанмагач, кемгә ышанырга кала бу дөньяда! Күзләремә сөйкемле булып күренә башладың шушы сүзләреңнән соң!

Ә н и с ә. Шалтырат!

Г а б б а с. Кемгә?

Ә н и с ә. Тегеләргә!

Г а б б а с. Ә... ә... Мамалеевларга?! *(Телефонга.)* Иптәш Мамалеев! Бу — мин, Шәйморзин! Сезнең боерыкны үтәп, хатын белән киңәштем. Малай... минеке! Минеке! Минеке!

Ә н и с ә *(трубканы тартып алып)*. Минеке дә! Сәлам белән Шәйморзина!

Г а б б а с. Их-ма! *(Гармунын алып җырлый, Әнисә кушыла.)*

Каштаннар, каштаннар,
Яшьлекнең нәкъ үзе сыман
Ярсуланып ташканнар.
Каштаннар, каштаннар,
Язларың да, назларың да
Йөрәккә тоташканнар...

Л ю ц и я белән Р е в а керә.

Люция (*кайгылы*). Әти!
Габбас. Ни булды?
Рева. Уф, башым!
Люция. Нишләргә?
Габбас. Нәрсә булды?!
Әнисә. Мирослав?!
Габбас. Бәхетсезлек?!
Әнисә. Авария?!
Люция. Аннан да авыррак!
Әнисә. Йә Хода!
Рева. Кем уйлаган шундый бәла килер дип...
Габбас. Улым!.. Әллә?
Әнисә. Мирослав кайда?
Габбас. Ул исәнме?!
Люция. Исәнен исән... әмма...
Габбас. Нәрсә әмма?!
Люция. Ул...
Рева. ...безнеке...
Люция. ...түгел!
Рева, Люция. Безнеке түгел!
Габбас, Әнисә. Безнеке түгел?!
Габбас. Ничек?
Әнисә. Йә Алла, әллә... әллә... шпион булып чыктымы?
Габбас. Юкны сөйләмә!
Әнисә. Кулга алдылармы? Күңелемә килгән ие лә...
Габбас. Яп авызыңны! Люция, Рева, нинди генә авыр хәбәр булса да, әйтегез, күтәрермен...
Люция. Әйтергә тел бармый!
Рева. Мин әле һаман ышанмыйм...
Габбас. Кайда ул үзе? Нинди генә хәлдә калса да, ул минем балам...
Люция. Әнә үзе!

Мирослав керә. Кыяфәте киткән.

Габбас. Мирослав... улым...
Мирослав. Иптәш... Шәйморзин...
Габбас. Иптәш Шәйморзин?! Нигә минем белән шундый рәсми тонда сөйләшәсең? Улым, мин сине аңламыйм...
Мирослав. Мин дә аңламыйм.
Люция, Рева. Без дә аңламыйбыз!

Мирослав. Иптәш Шәйморзин... мин... ялгышканмын...

Габбас. Ялгышкансың?.. Димәк, син мине әтиең итеп танымыйсың?

Мирослав. Кызганыч, әмма мәҗбүрмен.

Габбас. Мәҗбүрсең? Мин, Шәйморзин, Габбас... сиңа ата булырга лаек түгел, димәк?

Мирослав. Шулай дип әйтергә туры килә.

Габбас. Ни өчен? Нигә?

Мирослав. Бөтен фаҗига да шунда шул. Сез — Габбас Шәйморзин. Кыскасы, без: мин дә, сез дә бик нык ялгышканбыз. Анда миңа аңлаттылар!

Габбас. Юк, мин моны аңлаудан баш тартам. Мин бит, мин бит инде Габбас Шәйморзин! Әниеңнең исеме Алена бит?

Мирослав. Әйе, Алена. Анысы туры килә.

Габбас. Шулай булгач! Фамилиясе? Урбанкова?

Мирослав. Урбанкова. Анысы да туры килә. Кызганычка каршы, очраклылык. Бездә андый исем-фамилияләр күп шул.

Габбас. Мин бит, мин Габбас Шәйморзин!

Мирослав. Комиссариатта минем чын әтиемне тапканнар. Ул — Аббаз Шеймурзин. Мин сезгә башта ук әйттем: Аббаз Шеймурзин! *(Телефон чылтырый.)*

Габбас *(трубканы ала)*. Шәйморзин Габбас тыңлый. Ә?! Гафу үтенәсез? Мирославның чын атасын таптыгыз?! Аббаз? *(Хәлсезләнеп кәнәфигә утыра.)* Ә ул... чын Аббаз Шеймурзин кайда соң? Мин аның үзен күрмичә торып, ышанмыйм!

Мирослав. Минем чын әтием Аббаз Шеймурзин... сугышта алган авыр яраларыннан терелә алмыйча... үлгән.

Габбас. Үлгән? Ничек болай булды соң әле? Ничек болай булды? Син бит... әле генә минем балам идең...

Әнисә. Юк, мин моңа ышанмыйм! Ул баштанаяк минем Габбасыма охшаган! Юк, Габбас, ул синең балаң! Кара инде күзләренә, чәчләренә!

Рева. Мирослав... абый... без бөтенләй туганлашкан идек...

Люция. Кал бездә... Мирослав... туганым...

Әнисә. Кал, балам...

Габбас. Кал... улым...

Мирослав. Кызганычка каршы, тормыш фактлары — аяусыз. Мин үземнең әтиемне эзләп табарга сүз бирдем. Мин аны эзләп табарга тиеш! Каберен булса да... Рәхмәт сезгә... әтием... әнием... апам... сеңлем... кебек

кабул иткән мәрхәмәтле җаннар! Рәхмәт изге күңелле кешеләрне сыендырган шушы ягымлы өйгә! Мин сезне үзебезгә кунакка чакырам, иптәш Шәйморзин... Менә минем визиткам.

Габбас. Әнисә... әнисе...

Әнисә. Үзеңне генә җибәрмим. Мин дә барам!

Рева. Мин дә!

Люция. Мин дә!

Мирослав. Дүртегез дә килегез! Ә хәзергә... хушыгыз! Мин этине эзләргә китәм. Хатыны дүрт баласы белән баракта яши икән.

Габбас. Баракта?..

Рева. Мирослав абый, мин дә синең белән барам!

Люция. Мин дә!

Әнисә. Барыгыз, кызлар! Аннан соң Мирославны безгә алып кайтыгыз!

Мирослав. Габбас... Садыйкович... хушыгыз...

Габбас Мирославны кочагына ала. Икенче яктан Әнисә килеп кочаклый. Люция белән Рева да аңа елышалар. Үзәк өзгеч бер аваз белән әллә җырлыйлар, әллә елыйлар...

Каштаннар, каштаннар,
Әллә инде минем кебек
Каштаннар да шашканнар.
Каштаннар, каштаннар,
Йөрәк серен ачканнар да
Үкси-үкси качканнар...

Мирославны озаталар. Люция белән Рева да аңа ияреләр.
Тынлык. Габбас бер якка, Әнисә, аңа комачауламас өчен, икенче якка килеп утыра. Музыка дәвам итә.

Габбас. Их, Әнисә, белсәң иде, үкенеч тырный йөрәгемне...

Әнисә. *(Габбасның җилкәсенә кулын куя)*. Аңлыйм хәлеңне, түз...

Габбас. Үземнең балам дип ышанган хәлдә, ата буларак, мин аны алдадым. Мин аңа менә хәзер, кайтып кергәч, ул серне ачарга җыенган идем...

Әнисә. Нинди сер?

Габбас. Мин аны гына түгел... сезне дә алдадым, Әнисә. Бу оҗмах та вакытлыча гына, чит ил кунагы киткәнче генә.

Әнисә. Вакытлыча? Күңелем сизгән иде шул!

Габбас. Үз балам булмавы ачыклангач, вөҗданым бераз тынычланды кебек.

Әнисә. Габбас, син ни сөйлисең? Безне курчак итеп

уйнаттыларммыни? Шуңа риза булдыңмы? Син... уен уйнадыңмы? Без бит болай да гомер буе, киләчәк өчен дип, вакытлыча яшәдек, дөресрәге, яшәмәдек. Ә мамалилар без хыялланган, үз кулларыбыз белән төзегән киләчәктә яшәде, яши... Без яшәмәдек.

Габбас. Яшәдек, Әнисә, әмма бер-беребезне, балаларны, киләчәкне алдап яшәгәнбез.

Ике ярдәмчесен ияртеп, Мамалеев керә.

Мамалеев *(боерып)*. Шәйморзин! *(Габбас кузгалмый.)* Шәйморзин, сиңа әйтәләр!

Габбас *(боерып)*. Мамалеев! *(Мамалеев дәшми.)* Мамалеев, сиңа әйтәләр!

Мамалеев *(бүртенеп)*. Аван Казбекович...

Габбас. Габбас Садыйкович!

Мамалеев. Ярый, синеңчә булсын...

Габбас. Әй, син!

Мамалеев. Ярый, сезнеңчә булсын, Габбас Садыйкович! Үзегезгә мәгълүм, хәтерлисездер, кайсыдыр ки шушы май аенда, минем рәсми ярдәмчеләрем катнашында сезнең белән килешү төзегән идек. Кайсыдыр ки аның шартлары нигезендә, ягъни мәсәлән, сез, шәһәребезнең һәм дә илебезнең болай да югары булган абруен төшермәү максатыннан чыгып, шушы фатирга вакытлыча, кабатлап әйтәм, вакытлыча күчеп торырга җаваплы йөкләмә алган идегез. Бүгенгесе көндә безгә шул мәгълүм булды, кайсыдыр ки үзебезнең социалистик системадан килгән хөрмәтле кунагыбызның сезнең шәхесегезгә мөнәсәбәте булмавы ачыкланды. Шунлыктан, сез хәзер үк фатирны бушатып, үзегезнең иске баракка китәргә тиешсез! *(Ярдәмчеләренә)*. Мебельләрне Шеймурзин Аббазга, кабатлап әйтәм, Шеймурзин Аббазга вакытлыча бирелгән яңа фатирына күчерегез! *(Ярдәмчеләр үз эшләренә тотыналар.)*

Габбас. Туктагыз! Кагылмагыз!

Әнисә *(куркып)*. Габбас, нишлисең?

Габбас. Ә бу костюм, ботинкалар, галстук, эшләпә?

Мамалеев. Әлбәттә сездә калмый, Шеймурзин Аббазга күчә. Вакытлыча.

Габбас. Ә сезгә билгелеме: Шеймурзин Аббаз сугышта алган авыр яраларыннан дөнья куйган. Ул бу киемнәрне кия алмаячак!

Мамалеев. Анысы әһәмиятле түгел! Аның улы бар.

Габбас. Шуны белегез, әгәр дә Аббаз Шеймурзин исән булса, сезнең шартларга күнеп, карачкыга әйләнмәс иде! Ул сезнең тәкъдимнәрне ишетү белән, эшләпәгезне бер

якка *(ыргытып)*, костюмыгызны икенче якка *(салып)*, бозау муенчагын өченче якка... *(галстугын атып)* бәрер иде! Ул сугыш кырында гына түгел, тыныч чорда да үзенең дошманнарына каршы тигезсез көрәшкә чыгар иде!

Әнисә. Габбас, туфлиләреңне оныттың...

Габбас *(туфлиләрен салып ыргыта)*. Җитте! Мин болай да теләсә нинди хаксызлыкка түзеп, куркып, баш иеп яшәдем! Дөресрәге, яшәмәдем! Мин чын Шәйморзин түгел, хәтта карга да курыкмаслык карачкы, сезнең кулыгызда курчак булганмын. Ул Шәйморзинны гамәлдән чыккан дип санагыз! *(Чалбарын да атып бәрә.)*

Әнисә. Майка, трусик үзебезнеке, Габбас. Башкасын хәләл көчебез белән табарбыз!

Мамалеев. Шәйморзин, карагыз аны, дәүләт киемнәре өстеннән көлүегез өчен җавап бирерсез! Ә хәзер бушатыгыз йортны! Бу өй махсус кешеләр өчен салынды, ягъни мәсәлән, престижлы! Син аңла, монда хәзер үзәктән килгән зур кунак керәчәк! Мәсьәлә ачыкмы?

Габбас. Ул монда кермәячәк!

Мамалеев. Керәчәк!

Габбас. Ә сез бу йортны үз куллары белән салган эшче Шәйморзиннан рөхсәт алдыгызмы?

Мамалеев. Акылыңны югалттыңмы? Кемгә каршы килгәнеңне чамалыйсыңмы?!

Габбас. Акылымны югалтсам да, вөҗданымны югалтмам, шулаймы, энисе?

Әнисә. Шулай, әтисе! Үземә дә бераз батырлык керә башлады бугай. Нишлибез, кашка тәкәм, киңәш бир!

Габбас. Тәкәнең мөгезләре дә була аның!

Мамалеев. Саботаж! Авантюризм! Башыгыз белән җавап бирерсез!

Габбас. Киләчәк алдында башыбыз белән генә түгел, җаныбыз белән дә җавап бирәсебез бар. Сезнең дә, безнең дә!

Мамалеев. Ах, сез, вакытлыча булса да киләчәктә яшәүнең кадерен белмәдегез!

Габбас. Без киләчәккә вакытлыча түгел, бөтенләйгә яшәргә барабыз!

Мамалеев. Марш үзегезнең иске барагыгызга! *(Ярдәмчеләргә.)* Алга!

Габбас. Бер адым да артка чикмибез! *(Мебельләрдән баррикада кора. Мин белән Ким һөҗүмгә күчәләр. Габбас белән Әнисәдән кире чигенәләр.)*

Әнисә *(ярдәм итеп)*. Бер адым да артка чикмибез! *(Кулына нәрсә эләгә, шуны ала.)*

Машина сигналы ишетелә.

М а м а л е е в *(тәрәзәдән карап)*. Хуш киләсез, кадерлебез Фердинанд Имамович! Өегез котлы булсын! Рәхим итегез! Рәхим итегез! *(Габбас белән Әнисәгә.)* Бушатыгыз!

Г а б б а с. Монда Киләчәк өчен һәлак булган Шеймурзин Аббазның гаиләсен бөтенләйгә кертмичә торып, бер адым да артка чикмибез! Кабатлап әйтәм: бөтенләйгә!

Р е в а *(йөгереп керә)*. Әти!

Л ю ц и я *(йөгереп керә)*. Әтием!

Г а б б а с. Нәрсә булды?

Л ю ц и я. Нишләргә?

Р е в а. Уф, башым!

Г а б б а с. Ни булды?

Ә н и с ә. Мирослав?!

Г а б б а с. Бәхетсезлекме?!

М а м а л е е в. Безнең илдә авариянең булуы мөмкин түгел!

Л ю ц и я. Коточкыч!

Ә н и с ә. Йә Хода!

Р е в а. Кем уйлаган!

Г а б б а с. Әллә?..

Ә н и с ә. Мирослав кайда?

Ә н и с ә. Ул... исәнме?

Л ю ц и я. Исән!!!

Р е в а. Ул...

Л ю ц и я. ...безнеке!!!

Р е в а<br>Л ю ц и я } Безнеке!!!

Г а б б а с<br>Ә н и с ә } Безнеке?!

Г а б б а с. Ничек?

Р е в а. Аббаз Шеймурзинның өен эзләп таптык. Мәрхүмнең Чехословакиядә булмавы ачыкланды.

Л ю ц и я. Ни өчендер, гел документларны бутыйлар?!

Р е в а. Ялгыш юлга җибәрергә тырышалар.

М а м а л е е в. Иптәш Шәйморзин, без сезне мораль бозыклыктан күпме саклап калырга тырыштык! Аңламадыгыз!

Г а б б а с *(усал)*. Мин сезне бик яхшы аңладым, Мамалеев! Улым! Кайда ул?!

М и р о с л а в кайтып керә. Йөзе ачык.

М и р о с л а в. Әти! Әни! Туганнарым!

Габбас. Балам!

Әнисә. Улым!

Рева. Абыем!

Люция. Туганым! *(«Каштаннар» җырын җырлап кочаклашалар.)*

Мамалеев *(телефон трубкасын алып)*. Иптәш Бархаруллин! Мамалеев сөйли! Хәлләр катлауланды. Операция без теләгәнчә бармый... Нишләргә?

Пәрдә.

*1989*

# Ак калфагым төшердем кулдан...

*Халык драмасы*

**Сан-Франциско — Казан телевизион күперендә катнашалар**

САН-ФРАНЦИСКО ЯГЫННАН
Сафия Нурхан — очраштыручы.
Тайфур Кормаш — 35 яшьтә.
Жак — 67 яшьтә.
Катрин Люсиль — 57 яшьтә.
Майк Стерн — 67 яшьтә.
Клиффорд Стреттон — 40 яшьтә.
Гөлнур Галәветдин — 35 яшьтә.
Ратмир Зәкиевский
Зөбәйдә Прайс
КАЗАН ЯГЫННАН
Клара Измайлова — очраштыручы.
Регина — 35 яшьтә.
Шәмсия Ишмуллина — 85 яшьтә.
Исмай Акчурин — 57 яшьтә.
Иванов Павел Николаевич — 70 яшьтә.

Алар безнең көннәрдә берьюлы Сан-Франциcкода һәм Казанда очрашалар.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Казан телестудиясендә Клара Измайлованың эш бүлмәсе.

Клара *(телефоннан сөйләшә)*. Димәк, сценарийны расладыгыз? Рәхмәт! Бер генә кимчелеге? Әйтегез, шеф! Кадрия ханымны төшереп калдырырга? Кырмыска оясына таяк тыгарга кирәкмәс? Аннан котылу җиңел булмас...

Ярый, җаен табарбыз! Ышанычыгызны акларга тырышырбыз!

Акчурин керә.

Акчурин. Мөмкинме?

Клара. Әйдәгез, Исмай Саттарович, узыгыз!

Акчурин. Исәнмесез, Клара Измайлова! Тагын нинди олы мәшәкатьләр көтә безне?

Клара. Сизеп торасыз, бер генә сәяси чара да сездән башка үтә алмый. Сан-Франциско телевидениесе безне очрашуга чакыра.

Акчурин. Американнар белән?

Клара. Татарлар белән!

Акчурин. Юк, юк! Мине катнаштырмагыз, бу юлы миннән башка!..

Клара. Исмай Саттарович, сез бу очрашуның тоткасы...

Акчурин. Гафу үтенәм... Мине сызыгыз! Дөнья — куласа...

Клара. Исмай Саттарович, сез бөтен дөньяга күрсәтеп горурланырлык мәшһүр рәссамыбыз!

Акчурин. Башканы табыгыз! Вакытым юк! Иҗат!

Клара. Сценарий расланган, фамилияләр хәл ителгән!

Акчурин. Шулаен шулай да... авырып торам...

Клара. Борчылмагыз. Сценарийда сүзләрегез язылган. *(Бирә.)*

Акчурин. Анысы ярый. Нигә соң мин, нигә мин?!

Клара. Кыскасы, сезне Майк Стерн әфәнде очрашуга үзе чакыра.

Акчурин. Майк... Стерн?

Клара. Аны Сан-Францискодагы коллегаларыбыз эзләп тапканнар.

Акчурин. Ул... исән?

Клара. Үз күзләрегез белән күргәч, ышанырсыз.

Акчурин. Әйе... сез миңа гаять авыр җаваплы миссия йөклисез. Сез бит татарлар белән генә дигән идегез?

Клара. Милли чикләнүдән коткару өчен, без сезне чакырдык та инде, Исмай Саттарович... Киләсе якшәмбегә, сәгать бишкә көтәбез!

Акчурин. Хуш иттек! *(Чыга.)*

Шәмсия керә.

Шәмсия. Рөхсәтме?

Клара. Рәхим итегез! Сез Шәмсия апа Ишмуллинамы?

Ш ә м с и я. Рәхмәт, сеңлем, әллә каян табып торасың.
К л а р а. Утырыгыз, апа!
Ш ә м с и я. Шулкадәр еракта килгәч, утырмый да булмас. Сиксән биш яшьлек карчыкның кемгә кирәге чыкты, сеңлем?
К л а р а. Без сине бөтен дөньяга күрсәтергә уйлыйбыз, Шәмсия апа.
Ш ә м с и я. Беткәнмени унҗиде яшьлек чибәрләр, дөньяның тоткасы булырлык асыл хатын-кызлар?
К л а р а. Сез бер дә алардан ким түгел. Бездә татарча да, русча да, инглизчә дә белүчеләр бармак белән генә санарлык.
Ш ә м с и я. Анысы шулайдыр... Минем инглизчә сөйләшүне каян белдегез, кызым?
К л а р а. Әтиегез Фәтхетдин Ишмуллинның революциягә кадәр үк инде Америкада укуын беләбез.
Ш ә м с и я. Дөрес, атам бик тә мәгълүматлы кеше булган. Әмма чит ил белән бәйләнешләре өчен аны революциядән соң атканнар...
К л а р а. Тапшыруда сез анысын әйтмәссез.
Ш ә м с и я. Нинди тапшыру?
К л а р а. Без сезне Америка татарлары белән үткәреләчәк телевизион күпердә катнашырга чакырабыз.
Ш ә м с и я. Атам язмышы кабатланмасмы?
К л а р а. Дөнья үзгәрде, апа, курыкмагыз.
Ш ә м с и я. Нинди телдә сөйләшергә?
К л а р а. Нигездә, татарча... Кирәге чыкса, инглизчә дә... Сценарийда сүзләрегез язылган. Шушы фикер кысасыннан чыкмагыз.
Ш ә м с и я. Алар... качып киткән татарлармы?
К л а р а. Төрлесе бар. Анда туганнары да...
Ш ә м с и я. Минем өчен алар... илен сатучы хыянәтчеләр. Кызып китеп, әллә ниләр сөйләп ташламасам ярый...
К л а р а. Шуның өчен сценарий төзелә дә инде. Без сезнең патриотик хисләрегезгә ышанабыз.
Ш ә м с и я. Тормышым-язмышым турында сорасалар?
К л а р а. Ягъни мәсәлән?
Ш ә м с и я. Сез бәхетлеме, бәхетсезме? дип...
К л а р а. Ничек җавап бирер идегез?
Ш ә м с и я. Мин бәхетле...
К л а р а. Аргумент?
Ш ә м с и я. Совет илендә яшәвем белән...
К л а р а. Дөрес!
Ш ә м с и я. Мин бәхетсез дә... үзара әйткәндә...
К л а р а. Ни өчен?

Ш ә м с и я. Гомеремдә бер тынычлык күрмәдем. Сугыш та ачлык... Ачлык та сугыш... «Атаң революция дошманы» дип, яшьлегемне сүндерделәр. Аннан сугышта ирем, балам ятып калды. Бердәнбер юанычым шул: ил өчен башларын салдылар. Уйлап карасаң, шулмы инде бәхет? Җитмеш ел буе рәхәт, гадәти тормыш күрмә, имеш... Үзара әйткәндә... Гел «давай! давай!» дигән боерыкка буйсынып яшәдек инде...

К л а р а. Син боларын сөйләмәссең инде, апа.

Ш ә м с и я. Сөйлимме соң... Авызың тулы кара кан булса да, дошманың алдында авызыңны ачма, диләр. Үзебезнең абруйны төшерәмме соң? Ни кушсалар, шуны сөйләп өйрәнгән инде без, кызым...

К л а р а. Мин сиңа ышанам, Шәмсия апа.

Ш ә м с и я. Без инде шул, гадәтләнгәнчә, язылганны ятлап килербез.

К л а р а. Киләсе якшәмбегә, сәгать бишкә көтәбез!

Ш ә м с и я. Аңладым, кызым. Хуш-исән булыйк! *(Чыга.)*

И в а н о в керә.

И в а н о в. Чакырган җиргә керергә ярыйдыр?

К л а р а. Керегез!

И в а н о в. Иванов.

К л а р а. Клара Измайлова. Баш редактор. Зәңгәр экранда Сан-Франциско белән Казанны очраштыручы.

И в а н о в. Мине көрәшергә чакыргансыздыр инде? Американнар белән рәхәтләнеп бил алышам. Сөлгене дә алып килдем. Ну, брат!

К л а р а. Физик мәгънәдә түгел, идея көрәше!

И в а н о в. Минем өчен аермасы юк. Безнең бөтен нәселебез — көрәшчеләр. Бөтен тормышыбыз — сугыш та көрәш...

К л а р а. Бу юлы дусларча көрәш. Америка татарлары белән.

И в а н о в. Керәшен абзагызда бөтен дөньяның татарлары белән көрәшерлек көч бар әле. Ну, брат!

К л а р а. Сезгә ничә яшь?

И в а н о в. Җитмеш?

К л а р а. Америка татарлары сезнең авыл сабантуена килделәрме?

И в а н о в. Ну?

К л а р а. Былтыргы сабантуебызның батыры кем?

И в а н о в. Иванов!

К л а р а. Кайсысы?

И в а н о в. Минем оныгым. Җә?

Клара. Сез ялгыш килгәнсез. Американнар яшь батыр белән очрашырга телиләр.

Иванов. Ул килми. «Тел тегермәне тартырга вакытым юк»,— ди.

Клара. Алайса, сезгә кайтып китәргә туры килер.

Иванов. Җә инде, илле ел бил бирмәгән Иванов шулкадәр җирдән килгәч, американнар белән сүз көрәштермичә ничек кайтып китсен? Теләсәләр, мин әле җырлый да беләм! *(Керәшенчә җырлап җибәрә.)*

Авылыбызда бер матур бар,
Әйдә салыйк шобага!

Клара. Ярый, калыгыз... Сценарийны бозып булмый инде. Иванов тек Иванов. Батыр тек батыр... Әмма, зинһар өчен, хәзерге кебек күп сөйләшмәгез. Менә бу тексттан чыкмагыз!

Иванов *(ала)*. Авызыма су каптым, җә! Бетте! Тагын берне генә җырлап җибәрим дә! *(Җырлый.)* Җә?

Клара. Минем өчен генә ярый... Якшәмбегә, сәгать бишкә!

Иванов *(честь биреп)*. Дошман алдында бил бирмәбез, брат, Алла бирсә!

Чыга. Телефон чылтырый.

Клара *(трубканы ала)*. Регина Хәбиб? Үткәрегез! *(Номер җыя.)*. Иптәш Байбулатов! Сценарийдагы Хәбиб турында... Кирәк булыр дип уйлыйсыз? Үлем сәбәпләренә кагылмаска? Яхшы, иптәш Байбулатов!

Регина керә.

Регина Хәбиб?

Регина. Әйе.

Клара. Утырыгыз.

Регина. Рәхмәт.

Клара. Регина дип кенә дәшәргә мөмкинме?

Регина. Мөмкин.

Клара. Регина, безне бер сорау кызыксындыра. Тарихта Галимҗан Хәбиб дигән күренекле бер шәхеснең булуы билгеле. Аның сезгә нindидер бәйләнеше бармы?

Регина. Мин андый кешене белмим.

Клара. Дөрес, ул дин әһеле, эшчәнлеге сезнең өлкәгә — сәнгатькә карамый...

Регина. Бигрәк тә...

Клара. Ә бездә аның сезнең туганыгыз булуы турында дәлилләр бар.

Регина. Нигә әле сез миннән сорау аласыз? Әйтик, ул минем туганым, ди?

Клара. Тонны дөрес алмавым өчен гафу итегез... Сез бер дә курыкмагыз. Ул безне тарихи шәхес буларак кызыксындыра.

Регина. Бөтен мирасны юк иткәннәр. Бер генә документ та сакланмаган.

Клара. Ул инде акланган...

Регина. Атып үтерелеп, алтмыш ел узгач...

Клара. Ни өчен гаепләнгәнен беләсезме?

Регина. Америкага барган өчен... «Шпион!»

Клара. Ул анда ни өчен барганын беләсезме?

Регина. Юк.

Клара. Казан мәчетенең мулласы Галимҗан Хәбиб, Идел буендагы халык ачлыктан кырыла башлагач, 1921 елны делегация составында Америкага бара. Аннан ашлык алып кайталар...

Регина. Сез моны каян белдегез?

Клара. Америкадагы коллегаларыбыз эзләп тапканнар.

Регина. Һәм... күпме халыкның тамагын туйдырып үлемнән коткарып калган каһарман үзе сөргендә ачтан үлә. Хәзер кабере дә юк. Пермь өлкәсендәге зират өстендә завод корганнар.

Клара. Сез инде тапшыруда анысын әйтеп тормассыз...

Регина. Төшенмим.

Клара. Сезне Сан-Франциско телевизион компаниясеннән милләттәшләребез чакыра. Галимҗан Хәбибнең берәр туганын табуны сорадылар. Менә сезнең сөйлисе текстыгыз... *(Бирә.)*

Регина. Текст? Мин шуны укырга тиешме?

Клара. Нәкъ шуны түгел инде... Нигездә...

Регина. Бу сезнең шартыгызмы?

Клара. Шарты дип... Сез андагы фикерләрне үз сүзләрегез белән әйтә аласыз. Сез бит — фәннәр кандидаты...

Регина. Минем ни әйтергә теләгәнне сез каян беләсез?

Клара. Дошманнарча провокацион сораулар бирелә калса, сак булыгыз, дип кенә әйтүем... Димәк, килештек, киләсез?

Регина. Киләм. Әмма үземнең башым белән!

Клара. Якшәмбе көнне сәгать бишкә көтәбез! Хушыгыз!

Регина чыга.

Телефон чылтырый.

Кадрия Мөбәрәкова килгән? Юк, хәзер безнең вакытыбыз юк! Үткәрмәгез! Сөйләшүне таләп итә? Клара Измайлова тыңлый. Хөрмәтле Кадрия ханым, бу юлы без сезне тапшыруда катнаштыра алмыйбыз. Ни өчен дигәндә, тапшыруга Сан-Франциско үзе чакырган иптәшләр генә киләчәк. Гафу үтенәбез. Хушыгыз! Башка беркемне дә минем янга кертмәгез! Сценарий расланган, бер сүзен дә үзгәртү мөмкин түгел!

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Телевизор экранында башта Казан, аннары Сан-Франциско ягыннан катнашучылар күренә.

Сафия Нурхан. Әссәләмәгаләйкем, Советлар берлегендә яшәп ятучы газиз милләттәшләребез, туташлар, ханымнар, әфәнделәр! Без, җиһанның төрле ягына чәчелеп, бүгенгесе көндә бер сөйләшүгә зар-интизар булып гомер кичерүчеләр, сезне кайнар сәламлибез! Америкал татар җәмгыятенең дә сәламен кабул итеп алыгыз! Таныш булыйк: мин — Сафия Нурхан, япон телевидениесенең комментаторы. Бүгенге күрешүне алып бару өчен мине Сан-Франциско телевидениесе махсус чакырды, чөнки әлегә аларның саф татар телендә чыгарлык дикторлары юк. Сүзне кадерле спонсорларыбыз фин татарларының Тукай җәмгыятенә вә Нью-Йорктагы американ татар җәмгыятенә рәхмәт әйтүдән башлыйк!

Клара. Исәнмесез, Сафия ханым, хәерле кич!

Сафия. О, Клара ханым Измайлова, бездә көн булса да, хәерле кич! Казанда чакта сездә үткәргән кадерле көннәрне вә кичләрне һич онытасым юк. Бабаларыбызның туган җиренә, теленә, җырына, гореф-гадәтләренә берничә көнгә генә кайту да җан яраларын дәвалады сыман.

Клара. Хәтерегездәме, без сезне Казан артындагы ике авылга сабантуйга алып бардык.

Сафия. Соклангыч күренешләр!

Клара. Ул вакытта безнең операторыбыз шуннан бер күренеш төшереп алган. Рәхим итеп карагыз!

Телевизион кадр.
Кызлар, сулы чиләк күтәреп, йөгерешәләр. Сафия Нурхан да алар белән бергә. Кызлар артыннан җитә алмыйча ул артта кала, егыла. Чиләктәге сулары түгелә.

Клара. Сафия ханым, кулыгызны бирегез!

Сафия. Адәм көлкесенә калдым... бөтен халык алдында...

Клара. Борчылмагыз, сезгә барыбер бүләк бирeләчәк!

Сафия. Юк, юк... Нигә кунак булган өчен генә... Кирәкми... *(Аңа чиккән ак сөлге бирәләр.)* Юк, юк, алмыйм!

Клара. Алмыйча ярамый. Бу — халкыбызның гореф-гадәте. Чабышта иң арттан килгән атның муенына да сөлге салалар.

Сафия. Кичерегез... аңладым... *(Кадр өзелә.)*

Сафия. Кабат хатирәләрне яңартуыгыз өчен рәхмәт, Клара ханым. Яшермим, сабантуйда алган иң зур тәэсирем дә шул...

Клара. Комментарий бирә алмыйсызмы?

Сафия. Артта калган, читкә кагылган, кимсетелгән, үзен рәнҗетелгән дип хис иткән бичарага илтифат күрсәтү — милләтебезнең асыл сыйфаты.

Клара. Килешәм. Сез үзегезне дә читкә кагылганнар рәтенә кертми торгансыздыр бит?

Сафия. Чынында, без барыбыз да — без дә, ә бәлки сез дә, читкә кагылганнар, рәнҗетелгәннәр. Халкыбызның күпчелек өлеше үз туфрагында яшәми. Алар сабантуйдагы чабыштан, хәлсезләнеп, егылып калган атлар кебек. Әгәр халкыбыз артта калган атларның муенына ак сөлге бәйләү хисен югалтса, милләт буларак яшәүдән туктаячак.

Клара. Дөресен әйткәндә, бу хакта мин үзем дә борчылам... Исегездәме, күрше авылдагы сабантуйда колгага... әйтергә дә оят инде...

Сафия. Колгага ак сөлге урынына хәмер бәйләгәннәр иде...

Иванов. Бездә — этәч!

Сафия. Авылның исемен әйтеп, дөнья алдында хурлыкка калдырмыйк инде. Шунда ук батырга бүләккә тәкә урынына дуңгыз бирделәр.

Шәмсия. Булуы мөмкин түгел! Чит ил матбугаты, бигрәк тә буржуаз газеталар безнең тормышны бозып күрсәтергә бик оста.

Клара. Менә сез ни әйтерсез... иптәш... үзегез белән таныштырсагыз иде?..

Иванов. Иванов Павел Николаевич. Керәшен. Сабантуйдагы дуңгыз мәсьәләсенә мин бик аек карыйм. Монда бернинди дә провокация күрмим. Бик табигый хәл. Эзлиләр батырга бүләк бирергә тәкә, ә фермада —

юк! Гореф-гадәтне югалтырга ярамый, салалар батырның җилкәсенә мыркылдап торган дуңгызны, батыр да тук, дуңгыз да юк!

К л а р а *(микрофонны тартып ала)*. Иптәш Иванов арттырып җибәрде. Без күргән әкәмәт сирәк очрый торган очраклылык кына...

С а ф и я. Батырның фамилиясе дә истә калган. Иванов. Без аны чакырган да идек...

И в а н о в. Мин — Иванов! Ягъни мәсәлән, шул батыр егетнең бабасы, бывший батыр Иванов! Ну, братлар, дөресен әйтеп сөйләшик, дөньяда булган хәлмени, җә? Татар сабан туеннан җилкәсенә дуңгыз салып кайткан... Керәшендә дә мондый хәлнең булганы юк! Күтәрдем дә киттем председательләренә. Салдым дуңгызларын өстәлләренә!

К л а р а. Колхоз рәисе кунаклардан гафу үтенә...

И в а н о в. Ә бездән... халыктан?

С а ф и я. Без моны бер көлке итеп кенә кабул иттек, Иванов әфәнде. Баксаң, телегезне онытмагансыз икән... Фамилиягезгә карап бездә шик туган иде...

И в а н о в. Онытабызмы соң! Телебез булмаса, безне карга күтәреп китә бит!

С а ф и я *(телефон трубкасын алып)*. Тыңлыйбыз! Нью-Йорктан Газиз Сафалының Иванов әфәндегә соравы бар. Татар көрәшенең асылы нидә?

И в а н о в. Татар керәшененең асылы? Динен югалтса да, денен, телен югалтмый саклауда.

К л а р а. Иванов иптәш, сорауны дөрес аңладыгызмы? Сүз керәшен турында түгел, көрәш турында бара.

И в а н о в. Аңладым. Татар көрәшенең асылымы? *(Җырлап бирә.)*

Башымда картуз булса да,
Сатып алдым чалмалык.
Безгә аяк чалсалар да,
Без үзебез чалмадык.

К л а р а. Павел Николаевичка өстәүчеләр бармы?

А р а д а н б е р ә ү. Минемчә, халкыбыз зәгыйфьләнүенең бер сәбәбе — көрәштә кулланган шул хасиятен югалта башлауда.

С а ф и я *(телефонда)*. Иванов әфәндегә тагын бер сөаль бирәләр. Ни өчен сезнең исемегез урысча?

И в а н о в. Без — милләтнең көчләп чукындырылган өлеше. Җисемебезне саклап калсак та, исемебезне саклап кала алмадык. Безне керәшен диләр. Татар да бит Болгар дигән исемен саклап кала алмаган.

С а ф и я. Иванов әфәнде, әйтегез әле, нигә сез шаян сүзләрне дә кайгылы көйгә салып җырлыйсыз?

И в а н о в. Җырыбызга борынгы хәлебезне сагыну сеңгән. Шаян сүз әйтергә генә торганда, адәмнең башына кайгы килеп төшә дә җан сөенергә өлгерми кала.

К л а р а. Чыннан да, ни өчен соң халкыбызның җырлары үзәк өзгеч кайгылы, сагышлы?

С а ф и я. Аерылышу, озату, сагыну, бәхилләшү, бәхет эзләү...

К л а р а. Бәлки халкыбызның бөтен язмышы, тарихы шулдыр... Арабызда хөрмәтле Шәмсия апа утыра. Сез ничек уйлыйсыз?

Ш ә м с и я. Үз илләрен ташлап, бәхет эзләп читкә китүчеләрдән мин сорар идем: нигә киттегез? Бәхетне читтә түгел, үз җиреңдә эзләү, табу мөмкин ич. Китүчеләр үзләре гаепле! Читтә солтан булганчы, үз илеңдә олтан булу мең артык!

С а ф и я *(телефонда)*. Калифорния штатыннан Сәйфетдин Иманлы сезгә каршы төшә: «Үз илеңдә олтан булып яшәү егетлек түгел!» Аңа хәләл җефете Зөләйха ханым кушыла: «Без үз җиребездән үз ихтыярыбыз белән китмәдек, ачлык куды...»

Ш ә м с и я. Читтә тук булганчы, үз илеңдә ач яшәү өстенрәк! Үз тамагыңны гына кайгыртып, илдәшләреңне авыр хәлдә ташлап читкә качу — җинаять!

К л а р а. Шуны да әйтеп китик, Шәмсия апаның атасы Фәтхетдин Ишмуллин революциягә кадәр Кембридж университетында белем алган.

Ш ә м с и я. Бай яшәү мөмкинлекләреннән баш тартып, үз иленә кайтып халкына хезмәт иткән.

К л а р а. Гыйбрәтле бер фактны исегезгә төшерәсем килә, аны эзләп табулары өчен Сан-Францискодагы коллегаларыбызга зур рәхмәт. 1921 елгы ачлык чорында Галимҗан Хәбиб, Америкага барып, Идел буена ашлык төяп кайткан.

С а н - Ф р а н ц и с к о я г ы н н а н б е р ә ү. Галимҗан әфәнде Хәбибне, үз иленә кайткач, шпионажда гаепләп, юк иттеләр. Америкада калса, ул исән булыр иде...

Ш ә м с и я. Үз иленә кайтып җан бирүне артыграк күргән! Горурланам шундый затлар белән!

К л а р а. Тапшыруда Галимҗан Хәбибнең кыз туганы Регина Хәбиб катнаша. Регина иптәш, бәлки, сез дә берәр сүз әйтерсез?

Р е г и н а. Мин бер сүз дә әйтә алмыйм... Моннан артык ни әйтәсең... Бабамны онытмавыгыз өчен зур рәхмәт...

Клара. Регина — бүгенге көндә бабасының матур дәвамы...

Акчурин. Талантлы яшь галимебез. Сәнгать фәннәре кандидаты.

Клара. Хәзер сезне халкыбызның мәшһүр рәссамы белән таныштырырга рөхсәт итегез. Хөрмәтлебез Исмай Саттарович Акчурин!

Майк Стерн. Сафия, микрофонны бирегезче! *(Микрофонга.)* Исмай! Акчурин!

Акчурин. Гафу итегез!..

Майк. Ә мин сине, яшьтәш, озак еллар үтсә дә, фамилияңне әйтү белән таныдым. Татарлар белән очрашырга дигәч, сөенеп ризалык бирдем.

Акчурин. Әле һаман истә...

Майк. Их, яшьтәш... Ул чактагы очрашуны, истәлеккә дип, егетләр киногa төшергәннәр иде. Мин аны хөрмәтле алып баручыга тапшырдым. Мисс Сафия?

Сафия *(микрофонга)*. Беренче сандагы язманы күрсәтүегезне үтенәм.

Экранда документаль кино, кадрдан өзек.
26 апрель, 1945 ел. Майк Стерн — Америка, Исмай Акчурин — совет солдаты формасында. Алар кочаклашалар.

Исмай. Сәлам, Америка!

Майк. Ура! Җиңү!

Исмай. Мин — Исмай...

Майк. О, Исмай... Герой! Рус!..

Исмай. Мин Россиядән, но...

Майк. Но?

Исмай. Татар.

Майк. О, татар! Беренче тапкыр күрәм. Татарлар ярты дөньяны яулап алганнар. Чыңгыз хан?

Исмай. Юк... юк... Чыңгыз хан түгел. Казан татары.

Майк. Чыңгыз хан — үз чорының бөек полководецы. Аннан баш тартасың?

Исмай. Бу юлы без дөньяны фашист явыннан коткарырга килдек.

Майк. Гитлер капут! Ура! *(Виски йотып.)* Союзниклар исәнлегенә! *(Исмайга бирә.)* Исмай исәнлегенә!

Исмай *(йотып)*. Союзниклар өчен! Исемегезне әйтмәдегез...

Майк. Син — Исмай, мин — Майк Стерн. Майк... Исмайк!.. Ха-ха-ха!

Исмай. Исмайк — Дуслык! Махорка?

Майк. Сигара? *(Бер-берсен сыйлыйлар. Исмай ма-*

*хорка төреп бирә, үзе сигара кабыза. Икесе дә көләләр.)* О, көчле!

Исмай. О, каты!

Майк. Безнең дуслык та шулай булсын! Сугыштан соң нишләргә уйлыйсың?

Исмай. Өйләнергә, балалар бәхетен күрергә...

Майк. Алла бирсә, мин дә өйләнәм. Бәхетле балалар тудырыйк, Исмай. Алар да дус яшәсеннәр, сугышмасыннар иде!

Исмай. Без шундый киләчәкне үзебез сугышып алдык, Майк!

Майк. Амин! Әйдә, балаларыбыз өчен тост күтәрик!

Исмай. Ура, Майк!

Кадр өзелә.

Исмай. Майк! Стерн! 1945 елның 26 апреле! Эльба!

Майк. Күпме еллар узган... Картайдык, яшьтәш... Шулай да таныдың.

Исмай. Картайдык, яшьтәш.

Майк. Яшьләр картайта. Менә без балаларыбызның бәхете өчен дип сугышып йөрдек, хыялыңа ирештеңме, Исмай?

Исмай. Ничек дип әйтергә... синең балаларың бармы?

Майк. Хатын белән икебезгә бер малай үстердек. Дөнья артыннан куып, ычкындырдык. Наркоманга әйләнеп харап булды... Синең балалар ничек, Исмай?

Исмай. Сорама...

Клара. Хөрмәтле Майк әфәнде һәм Акчурин иптәш, без сезнең очрашуга бик шатбыз. Сезгә әле тагын вакыт бирербез. Диалогны дәвам итәбез. Исмай Саттарович, минем сезгә бер соравым бар. Үзегез яшәгән сәнгать өлкәсендә сезне ниләр борчый?

Акчурин. Без, өлкәннәр, әкренләп бу дөньядан китеп барабыз. Яшьләрдән кемнәр алыштырыр да безне, кемнәр дәвам итәр. Мин әллә ни өмет күрмим. Эчкечелек, җинаятьчелек канат җәя...

Сафия. Хөрмәтле Исмай ага, артык куертмыйсызмы? Сез әйткән ямьсезлекләр әлегә татар яшьләре арасына ул кадәре үк үтеп кермәгән.

Шәмсия. Исмай иптәш белән килешмим! Безнең яшьләребез андый түгел. Сафия ханым, ул мәсьәләдә сездә ничек?

Сафия. Безнең якта эшләр ничегрәк дип уйлыйсыз?

Тайфур *(арттагы рәтләрдән)*. Бозыклыкка

килгәндә, ике як та бер-берсеннән калышмый. Аллага шөкер, анда да, монда да мисаллар җитәрлек...

Сафия. Үзебезнең татарлар турында сүз алып барабыз. Дилбегәне ычкындырмыйк.

Тайфур. Татарлар дөнья күләмендә дилбегәне кулдан ычкындырдылар. Елмаеп үләләр татарлар, башлары өстендә гильотина, ә алар берни булмагандай гамьсез елмаялар...

Жак *(көтмәгәндә сикереп тора)*. Нәрсә беләсең соң син?!

Сафия. Кичерегез, газиз тамашачылар. Безнең бәхәсне тыңлап арыгансыздыр инде. Бераз ял итеп алыгыз. Игътибарыгызга Хельсинки татарларының «Тургай» исемле хор ансамблен тәкъдим итәбез.

Хор. Ай, әле бик еракта идек без,
Җитмеш чакрым җирдән килдек без.
Ак калфакның табылган чагы,
Туганнарның сагынган чагы.

Сафия. Гөлнур туташ, бу җырны каян өйрәндегез?

Гөлнур. Казаннан алып кайттык.

Сафия. Казан яшьләре сезгә ошадымы?

Гөлнур. Ошады. Әмма без, туган телебезне онытмаган туристлар, гаҗәпкә калдык. Милли башкалабызның күпчелек яшьләре үз телләрен онытканнар.

Сафия. Ак калфак сезгә бик килешә, Гөлнур туташ. Казаннар ак калфак кияләрме?

Гөлнур. Ансамбль артистлары гына кия. Җырда гына калган.

Тайфур. Ак калфакның каралган чагы,
Туганнарның таралган чагы...

Гөлнур. Без, Фин илендә адашып калганнар, туган телебез башкаласыннан еракта яшәсәк тә, телебезне, динебезне, гореф-гадәт вә йолаларыбызны онытмыйбыз. Киләчәктә без үз балаларыбызны татар итеп үстерергә телибез.

Тайфур. Бәхетсез татар балаларының санын күпме генә арттырырга тырышсак та, халкыбызның сыйфаты үзгәргән шул инде... Сез генә саклап кала алмассыз...

Арадан берәү. Протест белдерәм! Кайчандыр бөтен җиһанны калтыратып торган милләтебезгә яла ягу!

Тайфур. Элекке данлыбыз белән мактана-мактана телсез калдык инде. Хәзер ул «милләтче» дип әйтмәгәйләре дип калтырап тора.

Гөлнур. Мин сезнең белән килешмим!

Тавышлар. Килешмибез!

Т а й ф у р. Тарих юлларында үз урыны,
Әле түбән, әле биектә.
Бер карасаң, ул бик
кечкенә дә,
Бер карасаң, ул —
бик бөек тә!

Хәзер татарның яртысыннан артыгы үз телен белми. Җир шарының теләсә кайсы ягына чыксаң да аңлашып була торган ундүрт телнең берсе дип танылган бүгенге татар теле белән кая барырга мөмкин? Римгәме? Вашингтонгамы? Парижгамы? Әйтегез әле, Ратмир әфәнде, дөньяның атаклы биючесе булып танылырга сезгә безнең милләтебезнең теле кирәктеме?

С а ф и я. Безнең диалогта мәшһүр биючебез, Сан-Францискога гастрольгә килгән бөек артистыбыз, дөнья балетының йолдызы Ратмир әфәнде Зәкиевский катнаша.

Р а т м и р. Туташлар, ханымнар, әфәнделәр, хәерле кич! Мин бер генә минутка, тамаша башланыр алдыннан гына күренеп китәргә кердем. Сәлам, ватандашлар! Татар теленең тоткан урынына килгәндә, әфәнделәр, шәхсән, үз мисалымда... мине татар теленә өйрәтүне Рәсәйдә кирәк дип тапмаганнар, күрәсең. Һәм, дөресен әйтим, ул телне белмәвем белән мин бернинди дә кыенлык кичермәдем. Кыскасы, мин милләтче түгел, ә бәлки космополит!

Т а й ф у р. Кызганыч, ләкин факт!

Р а т м и р. Шунысы кызык: минем бабам 1812 елгы сугышта Парижны ат менеп, корал белән яулаган. Мин башка юл белән киттем, корал белән түгел, Парижны, җиһанны биюем белән яуладым.

Т а й ф у р. Фамилиягез генә безнеке булса да, горурланырлык кеше сез! Тик шуны да онытмасагыз иде, Ратмир әфәнде, сез яулаган тамашачыларның күбесен сезнең чыгышыгыз, нәселегез тарта.

Р а т м и р. Ихтимал, әмма бу минем өчен әһәмиятле түгел.

Г ө л н у р. Туктагыз, сез — безнекеме соң? Нишләп без сезне белмибез? Нишләп сез татарча бер генә бию дә башкармыйсыз?

Р а т м и р. Кадерлем, кызганычка каршы, татарыбызның югары сәнгатьне аңлау дәрәҗәсе әлегә чикле. Мин гаепле түгел. Ихтирам белән... Рәхим итеп концертыма килегез. Кыска вакытлы визитым өчен түбәнчелек белән гафу үтенәм. Игътибарыгыз өчен рәхмәт. Хушыгыз! *(Чыга.)*

Г ө л н у р. Ни өчен соң бездә мондый даһи биючеләр юк? Ни өчен талантлы кешеләребез дөнья сәхнәсенә күтәрелә алмый.

Т а й ф у р. Ә нигә, кемгә кирәк ул күтәрелү? Талантың күренеп, әз генә аерылдыңмы,— көт тә тор, булдыксызлар, көнчеләр, сәләтсезләр аяк чалалар, үзләре түбәнлеккә төшсәләр төшәләр, менгән биеклектән тартып төшерү өчен барысын да эшлиләр.

А к ч у р и н. Сез яшьләр, гел инкарь итүне генә беләсез, ә безнең иң даһи татарыбыз Тукай бар бит әле!

Т а й ф у р. Иң гыйбрәтле мисал — Тукай. Аны үз милләте биеклеккә күтәрде, үз милләте үк егерме җиде яшендә үтерде. Бүгенгесе көндә без Тукайларны тудырырлык хәлдә түгел. Чөнки үз телебезне югалту алдында торабыз. Туса да, алар әнә үз кендегеннән өзелгән Ратмир әфәнде хәлендә...

А к ч у р и н. Нигә мескенләнәсең син, егет?

Т а й ф у р. Безнең мондый хәлгә төшүебезгә сез дә гаепле, Исмай Саттарович!

А к ч у р и н. Менә бу җөмләгезне әйтү белән, мин сезне таныдым, иптәш...

Т а й ф у р. Әфәнде!

А к ч у р и н. Тайфур Сәлимович...

Т а й ф у р. Тайфур әфәнде!

А к ч у р и н. Ярый, сезнеңчә булсын...

Т а й ф у р. Сез һәрвакыт үзегезчә булыр дип көттегез шул...

А к ч у р и н. Без әле бу фикердән кире кайтырга уйламыйбыз.

С а ф и я. Мин сезне бүләргә батырчылык итәм. Сез танышлармыни?

К л а р а. Бу — минем өчен дә көтелмәгән хәл, Исмай Саттарович. Сез аны беләсезмени?

А к ч у р и н. Әйе, без танышлар.

К л а р а. Ягъни мәсәлән?

А к ч у р и н. Ул — яшь рәссам. Мин аны Казанда сәнгать училищесында укыттым.

К л а р а. Тайфур әфәнде, сез аны үзегезнең остазыгыз итеп хәтерлисезме?

Т а й ф у р. Хәтерлим.

К л а р а. Һәм... танyйсызмы?

Т а й ф у р. Таный идем.

К л а р а. Ә хәзер?

Т а й ф у р. Хәзер танымыйм.

К л а р а. Нигә дип сорамаска рөхсәт итегез...

Т а й ф у р . Сорамасагыз да әйтәм. Без — ике кыйбла кешеләре булып аерылыштык.

А к ч у р и н. Тайфур, хәлең ничек?

Т а й ф у р. Соңга калып булса да минем хәлем белән

кызыксынуыгыз өчен рәхмәт. Монда минем хәлем әйбәт! Тамак — тук, өс — бөтен, реклама агентствосында эшлим, шәп түлиләр, фатирым, машинам бар. Байлыгым Акчуриннар нәселен көнләштерерлек түгел түгелен. Исмай Саттарович, мин монда, сәяхәттә йөргәндә, затлы токымыгызның бер вәкилен очраттым. Фамилиягезгә тап төшермәгән, горур, зыялы, акыллы, талантлы...

Акчурин. Ялгышасыз, чит илләрдә минем туганнарым юк. Мин алардан баш тарттым. Алар — минем идея дошманнарым.

Тайфур. Нигәдер алар бер дә дошманга охшамаганнар.

Акчурин. Фабрикант, морза, акгвардияче Акчуриннарның иске династиясе җимерелде. Мин яңа чор Акчурины. Минем чит илләрдәге эмигрантлар белән бернинди бәйләнешем юк!

Тайфур. Яшь вакытта, укырга керү өчен, сезне үз атагыздан баш тарткан, дип сөйлиләр иде. Ул чакта ышанмаган идем. Хәзер ышандым.

Акчурин. Бик табигый хәл ул дәвер өчен... Сыйнфый көрәш. Кулакларны төбе-тамыры белән юк итү кампаниясе... Әлбәттә, бүгенге көннән чыгып караганда, яшьләргә сәер тоеладыр...

Шәмсия. Туктатыгыз бу йомшаклыкны, иптәш Акчурин! Нигә әле сез шушы тәти егетләрнең тамагы тук булсын өчен сыйнфый дошманнар белән көрәшкән, фашистларга каршы сугышкан мәшһүр рәссам — иманын арзанлы чит ил чүпрәгенә алыштырган элемент алдында әдәп саклап торасыз?

Регина *(арттагы рәтләрдән)*. Тайфур!

Тайфур. Регина?..

Регина. Тайфур!.. Очрашырбыз дип кем уйлаган...

Тайфур. Кызганыч, безнең очрашу бөтен дөнья алдында...

Сафия. Тайфур әфәнде, һич тә уңайсызланмагыз, танышыгыз белән сөйләшегез. Без сезгә берничә минут вакыт бирәбез. Клара ханым, сез ризамы?

Клара. Рәхим итегез... сценарийда каралмаса да... әңгәмәгез ике якка да кызык булыр диеп уйлыйбыз...

Регина. Нигә син киттең, Тайфур, барысын да ташлап?

Тайфур. Китәсем килеп китмәдем, туган илдән кем туйган? Анда минем беркемем дә юк иде: әтием дә, әнием дә... Минем анда синнән дә якын кешем булмаган икән... Кил якынрак... Үзеңә генә әйтәсе сүзләрем бар.

Регина. Син үзеңнең кайда икәнеңне оныттың, ахры?

Т а й ф у р. Бүген минем барысын да онытасым, дөньяның икегә бүленгәнен истән чыгарып, синең белән генә каласым килә. Әле дә ярый, Регина, син килгәнсең. Миллион чакрымнар аркылы мин синең килүеңне тойдым. Шуңа да мин бу очрашуга ышандым, Регина. Хәтереңдәме, тал-тирәкләр янында, тыныч күл буенда, айлы төндә күзгә-күз карашып торган мизгелләр? Мин ул манзараны рәсемгә дә төшердем.

Р е г и н а. Хәтердә.

Т а й ф у р. Хәтерлә...

Хәтерләү.

Т а й ф у р. Бәхил бул, Регина. Мин хәл иттем, китеп югалам.

Р е г и н а. Кая югаласың?

Т а й ф у р. Дөньяның билгесез ягына.

Р е г и н а. Китмәскә мөмкин түгелмени, Тайфур?

Т а й ф у р. Мөмкин.

Р е г и н а. Шулай булгач?..

Т а й ф у р. Әгәр дә мин үз карашларымнан баш тартып, гаебемне танысам, мине гафу итәчәкләр...

Р е г и н а. Тайфур, зинһар өчен, баш тарт, тәүбә ит!

Т а й ф у р. Минем бернинди дә гаебем юк. Ике төрле була алмыйм.

Р е г и н а. Алар сиңа нәрсә тәкъдим иттеләр?

Т а й ф у р. Минем алда ике юл бар: үзебезнең тилеләр йортына яки төрмәгә керү... Мин чит илгә сөргенгә китүне, мөһаҗир булуны сайладым.

Р е г и н а. Әле соң түгел, Тайфур, үзеңне харап итмә! Минем бабамны да чит илгә барган өчен атканнар...

Т а й ф у р. Моңайма, кош, моңайма, кош,
Моңайсаң да аталар.
Безгә моңайсак та ярый,
Чит илгә озаталар.

Курыкма, Регина, сиңа берни дә булмас, безнең аралар мәңгегә өзелә...

Р е г и н а. Тайфур, китмә, җаным... Кичә минем янга Акчурин килде. «Әйт, талантын кызгансын, чит илгә китмәсен» ди.

Т а й ф у р. Ә нигә ул мине яклап бер генә сүз әйтми? Минем хаклы икәнне белә бит. Юк, мин Акчурин кебек бүген бер, башка көнне икенче төрле була алмыйм.

Р е г и н а. Ул дөрес әйтә: бу... бу... хыянәт...

Т а й ф у р. Мин үземә, талантыма тугры калам. Кайчан булса да бер акларлар. Илне ташлап китми чара юк.

Р е г и н а. Сорыйм, үтенәм, ялварам... Тайфур!

Т а й ф у р. Исәр җилләр, чыгар кояш, бездән сәлам шул булыр...

Р е г и н а. Шушы зәңгәр күлне, безне очраштырган тал-тирәкләрне сагынмам дисеңме әллә?

Т а й ф у р. Минем йөрәгем сагынуның ни икәнен әлегә аңларлык хәлдә түгел. Ул суынды, ташка әйләнде.

Р е г и н а. Юк, ышанмыйм! Синең йөрәгең андый түгел.

Т а й ф у р. Мин ул салкын йөрәгемә салып бер генә нәрсә дә — сине дә, күлне дә, тал-тирәкләрне дә алып китмим. Калыгыз туган илегездә, дулкынланып, таң җилләренә назланып, рәхәтләнеп...

С а ф и я. Сезнең тагын бер минут вакытыгыз калды!

К л а р а. Сафия ханым, регламент!

Р е г и н а. Тайфур, зинһар, тагын бер генә сүз әйт, югалма!

Т а й ф у р. Кил, якынрак кил, Регина!

Р е г и н а. Онытылма, Тайфур, бик теләсәм дә, мин сиңа якыная алмыйм. Без — шәүләләр... Арабызда күпер дә юк. Сират күпере булса да, хәзер мин курыкмыйча сиңа китәр идем, Тайфур!

Т а й ф у р. Регина, ачуланма, «мәңгегә сагынмам» дип, мин үз-үземне алдаганмын...

Р е г и н а. Нигәләр алай дип әйттең соң?

Т а й ф у р. Минем өчен син газап чигәргә тиеш түгел идең...

Р е г и н а. Түзәр идем барысына да. Нигә дип синең белән китмәдем, үкенәм. Мин синең уңышларың өчен бик шат, Тайфур. Максатыңа ирештең, димәк?

Т а й ф у р. Матди яктан минем хәлләр ярыйсы...

Р е г и н а. Ирекләме соң син хәзер?

Т а й ф у р. Мин ирекле. Ни телим — шуны эшлим. Әмма иң кадерле нәрсәне югалту бәрабәренә алынган ирек мине бәхетле итмәде. Басып торган үз туфрагым, җирем, суым, шунда тамырланган тал-тирәкләрем, телем-моңым җитми миңа. Һәрбер көнем-төнем иксез-чиксез газапка әйләнде. Мин моны сиңа әйтмәс тә идем. Бәлки, соңгы тапкыр күрүемдер...

Р е г и н а. Юлларын өйрәт, мин сиңа барам!

Т а й ф у р. Мин килгән бай илдә Тайфурның аяныч язмышы да бик җиткән. Нигә сине дә бәхетсез итәргә?

Р е г и н а. Синнән башка мин монда, үз илемдә бәхетсез...

К л а р а. Регина иптәш!..

Р е г и н а. Тайфур, әйтеп кал!

Т а й ф у р. Бәхил бул, Регинам, минем өчен иң кадерле җан. Сине газапларга тартуым өчен гафу ит. Мин хәзер синең мәхәббәтеңә лаек түгел. Мин инде бозылдым, гөнаһларга баттым. Хәтта син кичерсәң дә, мин үз-үземне гафу итә алмыйм. Минем алда хәзер бер генә юл...

К л а р а. Сафия ханым, без сценарийдан тайпылдык!

С а ф и я. Мин сезне аңладым, Клара ханым. Хәзер, түземле тамашачыларыбыз, игътибарыгызга «Менә шулай, Майкл...» дигән Америка җырын тәкъдим итәбез. Башкара яшь җырчыларыбыздан Зөбәйдә Прайс! *(Башта Шәмсия җырны татар телендә укый, аннан соң ул инглизчә башкарыла.)*

Менә шулай. Майкл, менә шулай:
Дөнья безне куа, без — дөньяны...
Куып җитсәм, койрыгыннан
Тотар идем аны.
Менә шулай, Майкл, менә шулай,
Әйтче, әллә этме соң без бәйдә?
Бәндә булсак, тик беразга гына
Онытылыйк, әйдә!

Р е г и н а. Туктагыз! *(Үз ягында кул чабып, биеп торучыларга карап.)* Сез берни дә аңламадыгызмени?! Тайфур! Тайфур! Мине ишетәсеңме?! *(Аңа игътибар итмиләр, бию, җыр, рок-музыка дәвам итә.)* Ул юк! Ул — юк, ул киткән... Туктатыгыз аны! Сафия ханым, әле соң түгел, әйтегез, аның артыннан барсыннар! Коткарыгыз аны!

С а ф и я. Кичерегез, туташ, сезнең шәхси мөнәсәбәтләрегез безнең очрашуда каралмаган.

Р е г и н а. Арагызда бер генә дә рәхимле җан юкмыни соң? Ичмасам, киңәш бирегез: нишләргә? Ничек аны коткарырга? Бәлки, сез ярдәм итәрсез... Исмай Саттарович? *(Акчурин, мин нишли алам, дигәнне аңлатып, кулларын җәя.)*

К л а р а. Без сценарийдан бөтенләй читкә киттек. Иптәшләр, тынычландырыгыз туташны!

Р е г и н а. Дөньяда бер генә шәфкатьле кеше дә юкмыни соң?! *(Аны ике ягыннан тотып алып чыгалар.)* Тайфур! Тайфур!

Музыкаль антракт.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Клара *(телефонисткалар өстәле янында)*. Тыңлыйм, шеф! Расланган сценарийдан тайпылган өчен җавап бирерсең, дисезме? Мин берни дә эшли алмыйм! Дөньяның агышын туктата алмыйм! Теләсә нишләтегез! *(Трубканы куя. Үз өстәле янына утыра. Экранда — шулар ук.)* Музыкаль антракт тәмам. Сафия ханым, сез дәвам итәргә әзерме?

Сафия. Әзербез, башлагыз!

Клара (*Акчуринның күтәрелгән кулын күреп)*. Исмай Саттарович, сез Майк Стерн әфәнде белән әңгәмәгезне дәвам итәргә телисез, ахры?

Акчурин. Әйе, әйе... Майк, мине ишетәсеңме?

Майк. Ишетәм, Исмай.

Акчурин. Менә шулай, Майк...

Майк. Мин сине аңлыйм, яшьтәш. Яшьләр безне, без яшьләрне аңламыйбыз. Алар бәхетле булырга тиешләр иде бит...

Акчурин. Әллә алар үзләре гаеплеме?

Майк. Әллә безме?

Акчурин. Яшь чакта безнең идеалыбыз бар иде: фашист дигән дошманны юк итү өчен сугыштык.

Майк. Югыйсә безнең балаларның дошманнары да юк шикелле инде.

Акчурин. Булмаса, дошманны үзебез уйлап табабыз, Майк.

Майк. Синең балаларың бармы?

Акчурин. Бер малай.

Майк. Ул ни хәлдә?

Акчурин. Сорама, Майк...

Майк. Теләмәсәң, әйтмә...

Акчурин. Хәзер яшермәсәк тә ярый. Әфганстаннан сугышып кайтты. Танымадым: йомшак күңелле бер бала иде...

Майк. Адәмнәр, бер-берсен үтереп, ерткычка әйләнәләр, Исмай. Теге сугышта, фашистларны үтергәндә, башта мин үз-үземнән җирәнә идем, соңыннан кеше үтерү гадәти хәлгә әйләнде.

Зөбәйдә Прайсның җыры аларның диалогын бүлә. Түгәрәк өстәл янында Сафия Нурхан, Зөбәйдә Прайс.

Сафия. Зөбәйдә ханым, сезнең белән нинди телдә сөйләшергә?

З ө б ә й д ә. Бары тик инглиз телендә.

С а ф и я. Клара ханым, сезнең якта татарчага тәрҗемә кылучы тылмачлар бармы?

К л а р а. Әлбәттә. Шәмсия апа, сезнең ярдәмгә мохтаҗбыз.

Ш ә м с и я. И, заманалар, татарга да тылмач кирәк хәзер... Тәрҗемәләп карыйк... *(Башта диалог инглиз һәм татар телләрендә бара.)*

С а ф и я *(Зөбәйдәгә)*. Татар телен оныттыгызмени?

З ө б ә й д ә. Татар? Юк! Юк!

С а ф и я. Милләтегез?

З ө б ә й д ә. Американка.

С а ф и я. Әниегез кем?

З ө б ә й д ә. Әни? Татарка.

С а ф и я. Әтиегез?

З ө б ә й д ә. Рейнольд Прайс. Йөз процент американ.

С а ф и я. Әниегез каян?

З ө б ә й д ә. Россиядән.

С а ф и я. Америкага ул нигә килгән?

З ө б ә й д ә. Язмыш.

С а ф и я. Төгәлрәк әйткәндә?

З ө б ә й д ә. Сугыш вакытында аны немецлар Донбасстан, кол итеп, Германиягә алып киткәннәр. Мин моны хәтта әйтергә дә оялам. Әмма үземнең язмышыма рәхмәт кенә әйтә алам. Мин азат ил — Америкада тудым. Кайчандыр кол булган татардан...

Шәмсия тәрҗемә итә.

С а ф и я. Шәмсия ханым, дөрес тәрҗемә кылуыгызны үтенәм...

Ш ә м с и я. Ә мин милләтебезгә яла якмауларын таләп итәм!

К л а р а. Шәмсия апа, тылмач икәнегезне онытмасагыз иде...

С а ф и я. Әгәр Россиядә туган булсагыз?

З ө б ә й д ә. Кол хәлендә калыр идем. Әнинең җырлаганын тыңлаганым бар. Сары кайгы, өзелгән өмет... яки менә мондый... *(Көйли.)*

Яшьләремне түгеп еласам да,
Һичбер кеше миңа карамый
Әйләнеп,
Чит илләрдә калдым бәйләнеп.
Кайта алмыйм, туган илем, сиңа,
Дөнья өзгән безнең араны.
Беткән юл,
Туган-үскән илем, исән бул...

Ш ә м с и я. Кыланчык! Татарча беләсең ич!

З ө б ә й д ә. Мин җырлый гына беләм...

С а ф и я. Зөбәйдә ханым, сез әниегезнең, әби-бабаларыгызның җирен сагынасызмы?

З ө б ә й д ә. Сагыну? Нәрсә ул сагыну? Ни өчен әле мин әниемә бәхетсезлек китергән җирне сагынырга тиеш? Миңа беркем дә андый ят хисне көчләп тага алмый. Мин азат илдә яшим.

Ш ә м с и я. Мин артык тәрҗемә итә алмыйм. Баш тартам!

С а ф и я. Борчылмагыз, Шәмсия ханым, үзем тәрҗемә кылырмын. *(Зөбәйдәгә.)* Туган җир тойгысы бармы сездә?

З ө б ә й д ә. Туган җирем минем — Америка, шуңа күрә ул минем өчен барысыннан да өстен! Безгә, гомумән, Сафия ханым, эмоция, хис дигән нәрсәләр ят. Без — бизнес кешеләре, шуңа күрә дә без прогресс, цивилизация юлыннан киттек.

С а ф и я. Мин сезне бүләм, татар халкы да ялкаулардан түгел, ул да үзәкләре өзелгәнче эшләгән. Тукаебыз язган:

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез...

З ө б ә й д ә. Дөрес әйткән Тукаегыз: гомер буе сугышкан халык, тынычта үзәкләре өзелгәнче эшләсә дә, алга китә алмый, ул йә юлбарыс, йә ат хәлендә генә кала, цивилизациягә ирешә алмый.

С а ф и я. Киләчәгебезне юрап карагыз.

З ө б ә й д ә. Кешеләр кыргый, вәхши сыйфатларын онытып, Аллаһе Тәгалә җан биреп иңдергән Адәм тормышы белән яши башламасалар, бер-берсен бетерәчәкләр. Юлбарыслар — атларны, акулалар ваграк балыкларны йотачаклар.

С а ф и я. Үз уйларыгызны ихлас әйтүегез өчен рәхмәт, Зөбәйдә ханым Прайс! Казан, Клара ханым, дилбегәнең очын сезгә бирәм...

К л а р а. Без сезне игътибар белән тыңлыйбыз, Сафия ханым... Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә «Ватан» җәмгыятенең игъланын җиткерәбез.

«Егерменче елларда Казанга Америкадан бер татар кешесе килеп, бик арзан бәягә Фатих Халидиләр нәселенең бай китапханәсен төяп киткән. Анда тарихи әһәмияткә ия булган бик күп документлар, әйтик, Алтын Урда ханнарының ярлыклары саклануы билгеле. Шул хәзинәне табып кире кайтаруда ярдәм итүегезне сорыйбыз».

С а ф и я. Кулдан килгән кадәр ярдәм итәрбез, Клара ханым.

Өстәлгә язу куялар.

Игътибар! Әле генә бизнесмен Таминдар әфәнде шылтыраткан. Ул балачагы узган Каенлык авылындагы җимерек мәчетне яңарту өчен үз өлешен кертергә уйлаган. Әмма авыл советы баш тарткан, киңәш сорый.

К л а р а. «Ватан» җәмгыяте аша аның белән бәйләнешкә кереп, уңай хәл итәрбез дип уйлыйм.

А к ч у р и н. Клара ханым...

К л а р а. Микрофонны сезгә бирәм, Исмай Саттарович...

А к ч у р и н. Майк, мине тыңла әле...

М а й к. Тыңлыйм, Исмай.

А к ч у р и н. Синең белән төне буе серләшеп үткән бер төн искә төште. Менә хәзер дә кем беләндер ачылып сөйләшәсе килә. Дөресен әйтим, үз өемдә, үз илемдә йөрәкне бушатырлык фикердәшләрем юк икәнне белү — үзе бер фаҗига.

М а й к. Ни борчый сине, Исмай?

А к ч у р и н. Яшь чакта үз авылымдагы мәчетне мин дә җимерүдә катнаштым. Әйе... әйе... Моны әйтү бик авыр... Шулай да... дөньядан китеп барганчы... ялгышларны төзәтергә вакыт бар әле. Мәчетнең аен мин алып ташладым, мин аны куярга да тиеш!

М а й к. Яшьлектәге хаталар минем җанны да телгәли, Исмай...

А к ч у р и н. Әйдә, алтмышынчы елны Казандагы очрашуны да искә төшерик...

М а й к. Бик рәхәтләнеп!

А к ч у р и н. Миндә дә җавап сюрпризы. Клара ханым, мин биргән тасманы күрсәтсәгез иде.

К л а р а. Исмай Саттарович язмасын сорыйм!

Кинокадр:

Казанда Татар ашлары йорты. Өстәл артында Акчурин һәм Майк.

А к ч у р и н. Майк, әйдә минем күргәзмәне карап килик.

М а й к. Кызганыч, мин Мәскәүдән, сине күрергә дип, бер генә сәгатькә килдем.

А к ч у р и н. Әйдә алайса, вакытны әрәм итмик, монда гына сөйләшеп утырыйк... *(Бокалларга шәраб сала.)* Хәлләрең ничек, Майк?

М а й к. Менә балалар хирургларының симпозиумына

килдем. Тукта, татар ресторанында нигә чит музыка гына? Ә нигә бармен татарча белми? Официантлар да? Сәер, бик сәер бу, Исмай.

Акчурин. Без инде моңа күнеккән, исебез дә китми.

Майк. Син мине татарча өйрәтергә маташкан идең, һаман онытмадым: әни, әти, балам...

Акчурин. Әйдә, Майк, башка нәрсәләр турында сөйләшик...

Кадр өзелә.

Майк. Гаҗәп! Кем төшерде безне ул вакытта?

Акчурин. Хәзер яшермәсәк тә ярый. Һәркемгә «шпион», «дошман» дип шикләнеп караган иптәшләр төшергән. Хәзер алар үзгәрделәр шикелле. Менә истәлеккә үземә бүләк иттеләр.

Майк. Үпкәләмәсәң, бер соравым бар, Исмай.

Акчурин. Үпкәләмим.

Майк. Казандагы шул очрашу вакытында мин синең тарафтан элеккеге ихласлык, җылылык тоймадым сыман. Син Эльбада күрешкән Исмай түгел идең...

Акчурин. Ул чакта синнән генә түгел, миннән дә шикләнделәр. Янәсе, без милләтчеләр.

Майк. Мин... татар милләтчесе? *(Көлә.)* Мин бик шатмын! Менә ни өчен безнең аралар салкынайган икән... Аннан соң бер-беребезне оныттырдылар, арабызга кара пәрдә кордылар. Эльбада салынган күпер сүтелде...

Акчурин. Менә шулай, Майк.

Клара. Сан-Франциско, дәвам итегез!

Сафия. Хәзер реклама вә чит илләрдә яшәп ятучы милләттәшләребез тормышыннан бер манзара-видеотасма карагыз!

Катрин тавышы. Әгәр дә сез адәмчә бер рәхәтләнеп ял итәргә, телегезне йотарлык тәмле француз һәм татар ризыкларыннан авыз итәргә теләсәгез, «Ак калфак» дип аталган барга, аның сөйкемле хуҗалары Жак әфәнде һәм Катрин Люсиль ханымга рәхим итегез! Кайгы-хәсрәтләрдән, аерылышуның моңсу хатирәләреннән, сары сагыш зәхмәтләреннән, үзәк өзгеч сагыну хисләреннән онытылып тору — бары бездә генә!

Татар һәм француз музыкасы яңгырый. Барда, прилавка артында, Катрин.

Сафия оператор һәм яктыртучы белән бергә керә.

Сафия. Хәерле кич, мисс Катрин!

К а т р и н. Хәерле кич! Түргә узыгыз, кадерле кунаклар!

С а ф и я. Телевидение комментаторы Сафия Нурхан. Сан-Франциско һәм Казан телевидениесе экранда очрашу турында килешү төзеделәр. Мин әле генә сезнең ирегез Жак әфәнде белән сөйләштем. Без, әнә шул максаттан чыгып, татарлар тормышыннан бер күренеш төшерергә уйладык һәм объект итеп сезнең барны сайладык. Жак әфәнде фатихасын бирде. Сез каршы түгелме, мисс Катрин?

К а т р и н. Жакның сүзе җиткән, рәхим итегез...

С а ф и я. Сез бик ягымлысыз. Хәзер ирегез дә кайтып җитәр. Егетләр, төшерә башлагыз! *(Микрофонга.)* Сез биредә Дебюси, Равель музыкасы белән бергә Сәйдәш, Яруллин көйләрен дә ишетерсез. Нәкъ татарча милли ризыклар белән сыйланырсыз.

К а т р и н *(тәрәзәгә карап)*. Кичерегез, безгә кунак килә.

С а ф и я. Безгә игътибар итмәгез.

Т а й ф у р *(керә)*. Хуҗалар өйдәме?

К а т р и н. Рәхим итегез, әфәндем! Җаныгыз ни тели?

Т а й ф у р. Минем җаным сез рекламада вәгъдә иткән моңсу тынычлык тели.

К а т р и н. Сез аны алырсыз, әфәндем.

Т а й ф у р. Болар кемнәр?

К а т р и н. Телевидение. Казан өчен. Ризасызмы?

Т а й ф у р. Миңа барыбер. Сез татармы әллә?

К а т р и н. Юк, француз.

Т а й ф у р. Мине әллә кайлардан татар музыкасы тартты.

К а т р и н. Минем ирем татар.

Т а й ф у р. Күңелем дөрес тойган.

К а т р и н. Виски, лимон?

Т а й ф у р. Нәрсә булса да ярый.

К а т р и н. Пәрәмәч?

Т а й ф у р. Кызык, биш ел авыз иткән юк.

К а т р и н *(китерә)*. Бары бездә генә! Жак үзе пешерә. Әнисеннән өйрәнгән.

Т а й ф у р. Үзе кайда?

К а т р и н. Американ татар җәмгыятенә китте.

Т а й ф у р. Миңа аны ничек тә күрергә кирәк.

К а т р и н. Борчылмагыз, әфәндем. Төнлә юлга чыгарга уйламасагыз, отель дә үзебездә.

Т а й ф у р. Юл кешесенең юлда булуы хәерле. Берни дә булмас.

К а т р и н. Алла бирсә...

Т а й ф у р. Сез татарча да беләсез?
К а т р и н. Әз-мәз.
Т а й ф у р. Хуҗа белән язмыш ничек очраштырды?
К а т р и н. Сез эчегез, ашагыз.
Т а й ф у р. Сезнең исәнлеккә... кем...
К а т р и н. Катрин Люсиль.
Т а й ф у р. Тайфур.
К а т р и н. Сез татармы?
Т а й ф у р. Казан татары.
К а т р и н. Жак сөенер инде. Ак калфагын күрсәтер.
Т а й ф у р. Ак калфак? Нинди ул калфак?
К а т р и н. Талисман. Ул аны сугышта үлемнән саклаган.
Т а й ф у р. Катрин ханым, ак калфак хөрмәтенә...
К а т р и н. Миңа ярамый, ирем көнләшер...
Т а й ф у р. Танышу хөрмәтенә!
К а т р и н. Шулай дисәгез генә инде. *(Эчәләр.)* Сезгә минем Жак белән танышу кызыкмы? Без кара урманда очраштык. Мин — татар килене. Каенанамны күрү бәхетенә генә ирешмәдем. Каенаналарны бик усал диләр, дөресме, Тайфур әфәнде?
Т а й ф у р. Татар каенаналарымы? Башкалар белән чагыштырганда — алар фәрештә!
К а т р и н. Арттырасыз, каенана кайда да каенана инде ул...
Т а й ф у р. Каен ана... Каен кебек ак күңелле ана...
К а т р и н. Их, күрәсе иде шундый ананы! Жакны әйткән дә юк. Хыялында гел әнисе белән яши, өчпочмак пешергәндә аның белән сөйләшә, киңәшә...
Т а й ф у р. Әнисе кайда?
К а т р и н. Татар илендә, һаман исән, ди. Ул Жакны үлгән дип саный.
Т а й ф у р. Жак нигә хәбәр бирми?
К а т р и н. Мин дә шулай дим. «Әйдә, бергәләп кайтыйк, мәйтәм, күрик әнине», юк! Үзе «Әни!» дип өзгәләнә, тилмерә, үзе исәнлеген белдерергә теләми.
Т а й ф у р. Кара урман кебек серле... Шундый кешеләр хөрмәтенә!
К а т р и н *(бокал күтәреп)*. Сез бәйрәм алып килдегез, әфәндем. Аңа да, миңа да! Юллардан күзләрен алмый көтә инде үз татарын. Мин аның өчен сөенәм. Бәйрәмдә бииләр түгелме соң сездә дә? *(Җырлап-биеп китә.)*

Бас, кызым, Әпипә,
Син басмасаң — мин басам.
Кече кызымның туенда
Биеп калыйм, ичмасам!

Т а й ф у р. Браво, Катрин! Кече кызыгыз бармы соң, чыннан да?

К а т р и н. Ах, булсачы бер кыз... Тотар идем дә сиңа кияүгә бирер идем. Жак сөенер иде татар дип. Аллаһе Тәгалә балалардан мәхрүм итте. Шулай да бәхетсез түгел мин Жак белән. Ул үзе сабый кебек... Көнләшә дә, үпкәли дә, шундук оныта да... *(Тәрәзәгә карап.)* Әнә, үзе дә кайтып килә кадерлем! Жак, бездә кунаклар бар! Татар!

Ж а к *(керә)*. Хәерле кич, Сафия ханым!

С а ф и я. Игътибар итмәгез! Сөйләшкәнчә...

К а т р и н. Тагын бер кунак, Жак!

Т а й ф у р. Исәнмесез, Жак әфәнде! *(Кулын бирә.)* Тайфур Кормаш. Үз иленнән сөрелгән, бүгенге көндә дөнья юлларында адашып йөрүче мөһаҗир, ирекле рәссам.

Ж а к. Саумысыз?.. Без барыбыз да адашканнар, энекәш...

Т а й ф у р. Әфәнде диегез. Шулай дәшсәләр, мин үземне шәхес итеп тоям.

Ж а к. Нинди җилләр ташлады бу якларга, Тайфур энем?

Т а й ф у р. Нинди җилләрме? Милләтебезнең асыл затларын, Гаяз Исхакый кебекләрне үз иленнән сөргән сәмум җилләре.

Ж а к. Утыр әле, энем, сайрашыйк әле бер үзебезчә, җаннар рәхәтләнгәнче. Катрин!

К а т р и н *(йөгереп килә, бокалларга шәраб сала)*. Эч, җаным!

Ж а к. Кара аны, «җаным» дип, сөйгән ярга гына әйтәләр! Ярый, җаным, эшеңдә бул! Тукта! Мин эзләгәнне таптым. Сафия ханымнан язып алдым. Мәле, куеп җибәр!

Катрин китә. Магнитофоннан Илһам Шакиров башкаруында «Бик еракта идек» җыры яңгырый. Жак сейфтан саклык белән генә ак калфакны ала, аны күкрәгенә кыса.

Җ ы р. Ак калфагым төшердем кулдан,
Безнең дус-иш белән ил тулган...

Жак калфакны урынына кире куя.

Т а й ф у р. Әйе, ак калфакны төшердек кулдан... Бердәмлек юк бездә... Әнә яһүдләр һәм әрмәннәр ничек дөньяда бер-берсенә тотынып, үзләрен югалтмый саклыйлар. Болай да кискәләнгән, бүлгәләнгән милләт җирнең төрле якларына чәчелгән, алар арасындагы күперләр яндырылган. Кем генә җимермәгән ул күперне... Иван Грозныйдан алып Сталинга кадәр... Күпме татар дәүләтләре, үзара сугышып, бер-берсенең көчен бетергәннәр. Аннан соң урыслар белән... Әнә шулай яшәвен дәвам итсә, бетә татар...

Жак. Мин, бетмәбез дип уйлыйм, Тайфур энем.

Тайфур. Үз талантларына мөнәсәбәттә милләтнең бер сыйфаты чагыла.

Тәгәрәп уйнап,
Буй үскән
Туган илем, исән бул!
Чәч тузгытып,
Җай искән
Таңгы җилем, исән бул!
Йөгереп-йөгереп туктаган...
Яулык болгап сыктаган
Нәзкәй билем, исән бул! —

дип, аерылышу, саубуллашу турында җан шигыре язган Дәрдемәнд, Рәсәйне алтынга күмгән миллионер Дәрдемәнд, революциядән соң газапта үлә. Әле «Азатлык» радиосыннан ишеттем: Дәрдемәнднең рухи алтыны — бәләкәй генә китабы Казан кибетләрендә тузан эчендә, сатылмыйча ята икән. Әйдә, эчик әле, Жак әфәнде, кол хәлендә яшәүче мескен халкыбыз өчен әрнеп, гаҗиз булып...

Жак. Мин, энекәш, бу сүзләрең өчен тост күтәрмәс идем. Татарның мокытлары, саламторханнары җиде миллион арасында күптер, әмма халык мескен түгел, түгел!

Тайфур. Аның иң бөек чагы — 1905 елда, шул чорда ул Тукаен тудырды. Кызганыч! Факт! Милләтебез хәзер милләт дигән горур исемен, асылын югалтты. Үз хәле турында сөйләшүдән куркып яши.

Жак. Син мине дә шулар рәтенә кертәсеңме? Үзеңне дә?

Тайфур. Әйе, Жак әфәнде.

Жак *(сикереп тора)*. Минме куркак! Минме мескен!

Катрин *(йөгереп килә)*. Жак, тынычлан, утыр...

Жак. Син кит моннан, Катрин!

Катрин. Тайфур әфәнде, авырткан җиренә кагылмагыз...

Жак. Фашист лагерьларында тиреслектә казынганда да баш имәгән, офицерның битенә төкергәне өчен аякларыннан асып куелган — минме куркак?!

Тайфур. Кичерегез, Жак әфәнде!..

Катрин *(«Ак калфак»ны көчәйтә)*. Тыңла, Жак... *(Кочаклап аны утырта.)*

Тайфур. Жак абый, нигә син сугыштан соң илгә кайтмадың?

Жак. Әсирләрне, бигрәк тә безне — татар легионында хезмәт итүчеләрне илебез дошман, хыянәтче итеп игълан итте. Менә монысында син хаклыдыр, мин курык-

тым — илемә кайтсам, хөкем итәрләр дип курыктым. Һәм дөрес эшләгәнмен — дошманда мең газап чигеп кайткан әсирләрнең күбесен, кайтып керү белән, Себергә озаттылар. Әле дә ярый, халкыбыз бәхетеннән, Муса Җәлил илгә исән кайтып кермәде...

Т а й ф у р. Их, татар, татар... Һәрбер талантың — үзе бер фаҗига... *(Кинәт.)* Сагынасызмы?

Ж а к. Сагынасыңмы дип сорыйлар,
Сагынмаган кая ул...

Т а й ф у р. Туган илгә кайта алмаганга үкенмисезме?

Ж а к. Кычкыра торган кәккүкне
Очырмас идем күрсәм дә.
Туган-үскән җирне бер күрсәм,
Үкенмәс идем үлсәм дә...

Минем анда, туган җиремдә, өмет баглап, бишек тирбәткән әнкәем калмаган дисеңме әллә,минем анда, тар басмада кер чайкаучы нечкә билем калмаган дисеңме әллә, чит җирнең озын төннәрендә җанны әрнетеп, төшкә кереп үз урманымның кошлары сайрамыйлар дисеңме әллә?

Т а й ф у р. Ник кайтмыйсың, Жак абзый?

Ж а к. Мин — алар өчен һаман да дошман. Менә син яңа заман кешесе, япь-яшь кеше, син нигә илеңне ташладың?

Т а й ф у р. Алар мине дә дошман ясадылар. Үзләре кебек уйламаган өчен, алар кушканча иҗат итмәгән өчен...

Ж а к. Рәсемнәреңне күрәсе иде бер...

Т а й ф у р. Кайберләре — үзем белән. Бер минут! Хәзер, Жак әфәнде! *(Чыга.)*

Катрин килә. Жакның алдына утырып, кочаклый.

К а т р и н. Сак бул, Жак, шпион булып чыкмасын...

Ж а к. Юк, моның күзләрендә иман нуры бар.

К а т р и н. Нәрсә ул иман нуры?

Ж а к. Ул шундый нур, кадерлем... аны бер телгә дә тәрҗемә итеп булмый.

Т а й ф у р *(берничә картинасын алып керә, элеп куя)*. Карагыз, Казанда боларны кабул итмәделәр. Сезгә ошар дип уйлыйм. Катрин ханым, сез дә бәяләгез.

К а т р и н *(күңеле булсын өчен генә)*. Грандиоз! Искиткеч! Браво!

Т а й ф у р. Жак әфәнде, миңа дөрес сүз кыйммәт...

Ж а к. Бу нәрсә соң? Ә монысы? Гаҗәп... Ә нигә болай? Юк, мин сезнең картиналарыгызны аңламыйм, Тайфур энем... Дөресен әйтәм, аңлашылмый...

Катрин. Жак... Кунакның хәтерен калдырырсың...

Тайфур *(рәсемнәрне кискен хәрәкәтләр белән җыеп ала)*. Сез, гомумән, сәнгатьнең ни икәнен беләсезме соң?

Жак. Мин белгеч түгел, минем үз фикерем.

Тайфур *(бер читкә китеп)*. Соңгы өметем дә сүнде. *(Күзләрен бер ноктага текәп.)* Бер аңларлар, ләкин мин булмам...

Жак. Ни дидең?

Тайфур. Мин... китәм!

Жак. Кайларга таба юл тотасың, кайнар егет?

Тайфур. Белмим. Мин генәмени карурманда адашканнар?

Жак. Безгә кайчан да булса бер керерсеңме?

Тайфур. Якшәмбе көнне Сан-Франциско Казанны очрашуга чакыра. Бәлки, катнашырсың?

Тайфур. Белмим... Рәхмәт бу йортка... *(Акча калдыра.)*

Жак *(акчаны Тайфурның кесәсенә кире салып)*. Син безнең кунак.

Тайфур. Күпсенмәгез, күп тормабыз,
Без җирдә кунак кына...
Бәхил булыгыз!

Жак. Сау бул, энекәш...

Катрин. Гаепләп китмәгез.

Җыр көчәя.

Тайфур. Шулай да мин рәсемнәремне сездә калдырам. Бәлки, кем булса да ошатып, сатып алыр...

Жак. Калдыр... Тукта, бер сүзем калган.

Тайфур. Әйтеп калыгыз.

Жак. Халыкка үпкәләмә, энем. Елап йөреп халыкны бөек ясап булмый... Онытма, карурман серле, чиксез... күпме генә кырсалар да... *(Көйли.)*

Әй тал үсә, тал үсә,
Башын киссәң, тагы да үсә!

Чыгалар. Җыр бер көчәя, бер тына.
Кадрда — телевизион күпердә катнашучылар.

Сафия. Мөхтәрәм тамашачыларыбыз, сез чит илләрдәге милләттәшләребез тормышыннан бер сәхифә карадыгыз. *(Өстәленә кәгазь куялар.)* Америка сенсациясез яши алмый. Гадәттән тыш хәбәр әйтү өчен студиябезгә полиция вәкиле Клиффорд Стреттон әфәнде килеп кергән.

Рәхим итегез, Клиффорд әфәнде! Безне нинди яңалык белән куркыта аласыз?

Клиффорд. Бездә сөенерлек хәбәрләр булмый инде, Сафия Нурхан.

Сафия. Шулай да?

Клиффорд. Моннан нәкъ унбиш минут элек, телестудиядән ерак түгел кварталда туктап калган машинага игътибар иттек. Шикләнүебез юкка түгел икән — ишеген ачып карасак — хәрәкәтсез гәүдә!

Сафия. Ул безгә таныш кешеме?

Клиффорд. Безне дә әнә шул сорау кызыксындыра. Аны әле генә сезнең тапшыруда күргәннәр. Документларына караганда, ул — Америка гражданины Тайфур Кормаш! Ул үз-үзен үтергән булырга охшый.

Сафия. Фактларыгыз бармы?

Клиффорд. Машинасында язу калдырган.

Сафия. Укып бирсәгез иде.

Клиффорд. Аңа кадәр миндә бер сорау бар. Арагызда мәрхүм Тайфур Кормашны белүчеләр бармы?

Тынлык.

Сафия. Казан, безне ишетәсезме?

Клара. Ишетәбез, Сафия ханым. Америка гражданины, яшь рәссам Тайфур Кормашның вакытсыз үлеме мөнәсәбәтеннән кайгыбызны белдерәбез.

Шәмсия. Клара иптәш, нигә әле сез барыбыз исеменнән дә сөйлисез? Мин, мәсәлән, бу фикергә кушылмыйм. Менә хөрмәтле Исмай Саттаровичтан да сорагыз!

Клара. Исмай Саттарович?

Акчурин. Минем фикеремме?.. Мин... шулайрак уйлыйм... Бу — минем өчен бөтенләй көтелмәгән хәл. Мин... бераз уйларга тиеш. Дөнья — куласа...

Клара. Ярый, Исмай Саттарович, уйлагыз.

Акчурин. Мин инде уйладым... Мин кайгы белдерүгә кушылам. Ләкин... мәрхүмнең дөньяга карашы белән килешмәгән хәлдә...

Сафия. Клара ханым, мәрхүмне якыннан белүчеләр бармы, дигән рәсми сорауга сезнекеләр җавап бирмәделәр?

Клара. Якыннан белүчеләр бармы, иптәшләр?

Шәмсия. Минем аны күргәнем дә юк. Күрергә дә теләмәс идем! Менә Исмай Саттаровичтан сорагыз!

Клара. Исмай Саттарович, мистер Клиффордка җавап бирерсез, бәлки. Сез Тайфур Кормашны якыннан белә идегезме?

Акчурин. Мин аны укыттым.

Ш ә м с и я. Сезнең тәрбия?

А к ч у р и н. Минем аның белән мөнәсәбәтләр фикер каршылыкларыннан гыйбарәт. Юк, мин аны якыннан белмим. Регинадан башка, гомумән, аны якын күрүчеләр юк иде. Ул да, ялгышмасам, акылына килеп, аңардан суынды. Дөнья — гел үзгәреп тора...

С а ф и я. Мәгълүматларыгыз өчен рәхмәт, Казан! Мистер Клиффорд, сезне тагын нәрсә кызыксындыра?

К л и ф ф о р д. Хәзер мин сезгә мәрхүмнең васыятен укыйм. Рөхсәтме?

С а ф и я. Безнең сценарийда бу аяныч вакыйга булмаса да, без ризалашырга мәҗбүрбез. Рәхим итегез!

К л и ф ф о р д. Тыңлагыз!

Т а й ф у р т а в ы ш ы.

1. Мин бу шәфкатьсез дөньядан үз теләгем белән китәм. Минем үлемемдә беркемне дә гаепләмәгез.

2. Жак әфәнде, әгәр дә минем иҗатым белән кызыксынып, картиналарымны сатып алсалар (монысына мин өметне өзмим), алардан килгән табышны чит илләрдә газап чигеп үлгән бөек әдибебез Гаяз Исхакыйның исемен мәңгеләштерү өчен тапшыруыгызны үтенәм.

К л и ф ф о р д. Имзам: Тайфур Кормаш. Конвертның тышына Жак әфәнденең адресы язылган. Мин белергә тиеш, сезнең арагызда васыятьтә күрсәтелгән шәхес, ягъни Жак әфәнде бармы?

Ж а к *(алга чыгып)*. Мин — Жак — Америка гражданины!

К л и ф ф о р д. Мистер Жак, сез Тайфур Кормаш белән кайчан таныштыгыз?

Ж а к. Күптән түгел.

К л и ф ф о р д. Мин төгәл җавап көтәм.

К а т р и н. Бер атна элек.

К л и ф ф о р д. Сез кем?

Ж а к. Ул минем хатыным. Катрин Люсиль. «Ак калфак» барының хуҗасы.

К л и ф ф о р д. О' кей! Элек сез Тайфурны белми идегезме?

К а т р и н. Юк! Юк! Алла сакласын!

Ж а к. Белми идек.

К л и ф ф о р д. Мистер Жак, мисс Катрин, әйтегезче, Тайфур Кормаш сезнең белән очрашуда үзен ничек тотты?

Ж а к. Ничек дияргә? Аның шундый адымга барасын кем белгән...

К л и ф ф о р д. Мәрхүм үзенең дошманнары барлыгына ишарә ясамадымы?

Ж а к. Минем белүемчә, аның дошманнары юк иде.

К л и ф ф о р д. Сәер.

Ж а к. Аны дошман итеп күрергә теләүчеләр бар иде.

К л и ф ф о р д. Кемнәр алар? Фамилияләре?

Ж а к *(югалып кала)*. Атап әйтү мөмкин түгел... Ул конкрет әйтмәде.

К л и ф ф о р д. Тайфур үзенең васыятендә сездә картиналарын калдыруы турында да яза. Бу факт дөресме?

Ж а к. Дөрес. Мин аларны алып калдым.

К л и ф ф о р д. Ни өчен ул картиналарын сездә калдырды?

Ж а к. Ул газаплана иде. Иҗади кризис дигән сүзләре хәтердә. Монда күчеп килгәч, бер генә картина да ясый алмаган. Ул үзе, исән булса, дөресрәк аңлатыр иде. Башта ул үзенең илендә әсәрләренең кире кагылуын әйтте. Аннан соң безгә дә күрсәтте. Рәсемнәрне, дөресен әйтим, мин дә аңламадым. Шуннан соң ул... китте...

К л и ф ф о р д. Ул ялгызы гына чыгып киттеме?

Ж а к. Ялгызы. Машинасында.

К л и ф ф о р д. Аннан картиналарны нишләттегез?

Ж а к. Керүчеләр күрсен дип, барга элеп куйдык.

К л и ф ф о р д. Алар хәзер кайда?

Ж а к. Ядкарь өчен генә булса да берсе дә калмады. Узучылар, туристлар «ах!»та «вах!» килеп сокланып карадылар. «Гениально!» дип мактадылар, сатып алдылар. Бер атна эчендә! Мин аптырап калдым. Сәнгатькә карата мондый кызыксынуны күргәнем юк иде. Мәрхүмнең васыятен, әлбәттә, җиренә җиткереп үтәрбез.

К л и ф ф о р д. Минем әлегә сорауларым тәмам. Лэди һәм джентльменнар, туташлар һәм әфәнделәр, тапшыруыгызга көтмәгәндә бәреп кергән өчен гаепләмәссез дип уйлыйм! Нишлисең, эшем шундый... Ә сезнең белән, мистер Жак, мисс Катрин, саубуллашмыйм. Кайбер ачыкланып бетмәгән, томанлы мәсьәләләр турында сөйләшәсе бар. Тапшыру тәмамлануга, сезне каршы алырлар. Тикшерү дәвам итә... Тагын бер мәсьәлә! Мәрхүмне күмәргә аның туган иленнән килүчеләр булачакмы? Хәбәр итәрсез! *(Чыга.)*

С а ф и я. Мистер Стерн, күреп торам, сезнең әйтәсе сүзләрегез калган?..

М а й к. Рәхмәт, Исмай, шундый да талантлы шәхесегезнең һәлакәте мөнәсәбәте белән... кайгыгызны... кайгыбызны уртаклашам.

А к ч у р и н. Бу минем өчен бигрәк тә авыр, Майк... Кызганыч. Без аны аңларга тырышмаганбыз. Бәлки, әле аны коткару да мөмкин булгандыр...

М а й к. Юк, Исмай, мөмкин түгел. Доктор буларак

әйтәм, ул инде бу адымга барасын килгәнче үк хәл иткән. Ә мин, Исмай, аның бер картинасын сатып алдым бит. «Ах калфак» кафесында. «Айда очрашыр күзебез». Гаҗәеп!

Сафия өстәленә телефонистка кәгазь куя.

Сафия. Минем өстәлемә игълан китереп куйдылар. Сезне дә таныштырырга рөхсәт итегез.

«Американ татар җәмгыяте хәбәр итә:

Милләтебезнең күренекле бизнесмены Зәйни Акчура Сан-Франциско каласында вафат булды. Мәрхүмнең бай мирасын беркетү өчен нәсел-ыруын, кардәшләрен эзлибез. Ул калдырган васыятьтә Исмай Саттар улы Акчурин да бар».

Исмай әфәнде, мәрхүмнең якыннары хәзер үк сездән ачык җавап көтәләр... Исмай әфәнде?

Клара. Сез бу уңай белән кайгы белдерәсездер бит?

Шәмсия. Шулай инде, миллионер үлү — безнең өчен бик зур кайгы... Йә, нигә дәшмисез?

Акчурин. Мин... мин... кинәт кенә җавап бирә алмыйм...

Шәмсия. Димәк, сез...

Акчурин. Безнең мөнәсәбәтләр өзелгән иде...

Шәмсия *(усал)*. Соң... яңартыгыз мөнәсәбәтегезне...

Акчурин. Юк... юк... булмый... Дөнья үзгәреп тора.

Клара. Исмай Саттарович, нәрсә булмый?

Акчурин. Мин... ул мирастан... баш тартам...

Клара. Сафия ханым, ишеткәнсездер? *(Телефонистка аның өстәленә язу китереп куя.)* Исмай Саттарович, рәхим итеп телефонга барыгыз!

Акчурин *(телефонга барып трубканы ала)*. Тыңлыйм!

Акчурин хатыны. Акылың бармы синең, юкмы?! Көтмәгәндә ишелеп төшкән байлыктан баш тартасың. Хәзер үк ризалыгыңны бир!

Акчурин. Ярамый... үзең дә беләсең... Дөнья... үз...

Акчурин хатыны. Доллар үзгәрми! Ул синең туганың, бетте-китте! Ишетәсеңме?

Акчурин. Туктале, алай ярамый бит... мин...

Хатыны. Имзаңны гына куй, акчасын безгә бирерсең. Әфган сугышыннан имгәнеп кайткан малаеңны дәваларга чит илгә җибәрермен. Менә үзе, трубканы йолкый.

Малае. Әткәй, каршы килмә! Юкса хәзер үзем барам! Мин дә — Акчурин! *(Акчурин, трубканы куеп, үз урынына килә.)*

Сафия. Исмай әфәнде ни дип җавап бирә?

К л а р а. Исмай Саттарович?

А к ч у р и н. Мин әле... хәл итеп бетермәдем... Бераз уйлангач...

С а ф и я. Ару белмәс тамашачыларыбызга, көн саен, минут саен ишелеп торган авыр хәлләрдән арыну өчен, Истамбулдагы төрек татарлары башкаруында җыр тәкъдим итәбез.

Җ ы р. Ике кеше ике ярда
торып кала,
Сөйләшергә, аңлашырга күпер юкмы?
Беркем җавап тапмый торган авыр сорау:
Кем гаепле?
Кем гаепле?
Кем гаепле?
Кемдер йөзеп чыгып җитәр
теге ярга,
Кем кабызыр өмет дигән
сүнмәс утны?
Нигә безнең араларда
күперләр юк?
Кем гаепле?
Кем гаепле?
Кем гаепле?

К а т р и н. Юк! Жак гаепле түгел!

Ж а к. Тынычлан, Катрин...

К а т р и н. Полиция сиңа шик белдерде. Сине гаепләүләре ихтимал.

Ж а к. Без аны соңгы тапкыр күрүчеләр. Бу эшкә шаһитлар сыйфатында катнашабыз.

К а т р и н. Ә гаепләсәләр? Сине моннан чыгуга көтеп торачаклар.

С а ф и я. Мин барыгызны да тынычланырга чакырам. Тайфур әфәнденең үлемендә гаепле адәм юк.

К а т р и н. Юк! Юк!

С а ф и я. Сез ничек уйлыйсыз, әфәнделәр, ханымнар? Гөлнур туташ?

Г ө л н у р. Нинди дә кыйммәтле адәмебезне югалтканбыз. Туганнарының хәсрәтен уртаклашабыз. Соңгы юлга озатырга килүчеләр булса, юл чыгымнарын үзебез түлибез.

С а ф и я. Без дә Тайфур әфәнде туганнарының кайгысын уртаклашырга телибез. Бәлки, аны соңгы юлга озатырга килүчеләр табылыр?

К л а р а. Ничек уйлыйсыз, иптәшләр? Мәрхүмнең туганнары бармы? Аны соңгы юлга озатырга кем килер?

Рәтләрдә «Юк!», «Юк!» дигән тавышлар ишетелә.

Р е г и н а *(атылып керә)*. Бар! Бар! Бар!

К л а р а *(каушап)*. Регина иптәш... Утырыгыз... ярамый...

Р е г и н а. Сценарийда каралмаган, димәкче буласызмы? Җитте! Без болай да, сценарийда расланганча гына, куркып яшәдек. Әти-әнисе булмаса да, Тайфурның Казанда туганнары бар. Әмма Тайфур «дошман»га әйләнгәч, алар, куркып, аның белән араны өзделәр. Тайфурның бердәнбер якын кешесе мин идем! Әмма мин аның мәхәббәтенә лаек булалмадым. Һәм мин аның үлеменә дә гаеплемен! *(Шау-шу.)* Ни өченме? Куркак мин! Куркак! Ни генә булса да миңа аның белән китәргә кирәк булган. Соңгы тапкыр аның сүнгән күзләренә карап: «Кичер, Тайфур!» — дип әйтергә, аны чит ил туфрагына тапшырырга ярдәм итегез... ярдәм итегез... Ишетегез, мин Тайфурны яратам!..

Ш ә м с и я. Нигә сез аны туктатмыйсыз? Ул ни сөйләгәнен дә белми.

Ж а к. Ни өчен аны туктатырга? Сез аның сүзләре белән килешмисезмени?

Ш ә м с и я. Килешмим!

Ж а к. Ни өчен?

Ш ә м с и я. Тайфур Кормашны күмәргә бару рәсми төс алачак. Ни өчен әле без үз илен ташлап киткән, үз халкына яла яккан, иҗатын халык аңламаган, безгә чит элементны хөрмәтләп соңгы юлга озатырга тиешбез?

Ж а к. Нигә сез шулкадәр кистереп әйтәсез... кем...

К л а р а. Шәмсия әби.

Ж а к. Шәмсия әби... Күз алдына китерегез, сезнең балагыз шундый фаҗигале хәлдә калды ди...

Ш ә м с и я. Горурланып әйтә алам: минем ирем дә, балам да Ватан сугышында батырларча һәлак булдылар. Мәңгелек дан аларга! Үзләренең кадерле илләрен сатмадылар...

Ж а к. Димәк, мин сатлыкҗан?

К а т р и н. Жак, кузгалма, утыр... Мисс Шәмсия, аңа андый сүзләр әйтү ярамый...

Ш ә м с и я. Әгәр инде адәм, иленнән ваз кичеп, теге якка чыккан икән, аның исеме дә, җисеме дә — д о ш м а н!

Ж а к. Моңа кадәр минем тәнемне фашистлар телгәләделәр, йолдыз яндырып, күкрәгемә бастылар, автомат, итекләр белән изделәр! *(Күлмәген аерып төшерә.)* Менә аларның автографлары!

И в а н о в *(сикереп тора)*. Габделхак!

Жак сискәнеп китә, әмма дәшми, исемен ишетеп, урынына бөгелеп төшә.

Габделхак Ишмуллин!

Шәмсия дә куркып башын күтәрә.

Мин сине таныдым! Нихәл, маки? Син исәнмени? Мине таныйсыңмы? Керәшен Ивановны! Кил, кочаклыйм үзеңне, җә!

Ж а к. Сез ялгышасыз. Мин — Жак.

И в а н о в. Юк, син Жак түгел, син — Габделхак! Тән яраларыңнан таныдым. Хәтереңдәме татар легионы? Җырчылар ансамбле? Сабантуй ясадык. Синең белән көрәштем дә әле...

Яфрак ла төшә җирләргә
Көзге дә каты җилләрдә.
Сагынамын да, әнкәй, саргаямын,
Ябыгамын ят ук илләрдә.

Син минем җырлаганны тыңларга ярата идең. Ә аннан соң — француз партизаннары отрядында. «Маки Лимузин». Ну, хәтереңне эшләт, җә?! Роан шәһәрен азат итеп, үзебезнең кулда тоттык, ә? Җә? Монысын кара урманда, разведкага барганда, әкрен генә җырладым:

Су буйларында элмәлек,
Элмәлектә йөрмәдек.
Туган илдә рәхәт икән,
Кадерләрен белмәдек...

Их! Мин исән калдым. Легионда булган өчен утырдым утыруын, Себер урманнарында агач аудардым. Ходай кушкандыр, баш исән калды. Габделхак, әле һаман керәшенне танымыйсың, ә? Туктале, син алай нитмә әле, картайсам да, минем хәтерем ярыйсы. Ну, исеңә төшерим тагын теге тимер юл күперен шартлаткан чакны... Өчәү бардык. Керәшен, татар, хохол дип көлештек. Соңыннан кочаклашып, үкереп еладык. Без шартлаткан эшелонның бер вагонында үзебезнекеләр икәнне белдек. Их, брат, ну үкендек! Син бигрәк тә нык кичердең... Ну, төштеме исеңә? Габделхак!

Ш ә м с и я. Юк! Юк! Ул Габделхак түгел!..

Ж а к. Жак!!! Кем белән бутыйсың мине? Әмма шуны әйтәм: без... сез... һаман да... аңлапмы, ялгышыпмы... үз кешеләребезне юк итүне дәвам итәсез!

И в а н о в. Габделхак! Нигә яшерәсең? Син гаепле түгел бит, брат!

Ш ә м с и я. Провокация! Аның Габделхак Ишмуллин булуы мөмкин түгел!

Ж а к *(катып калган хәлдә Шәмсиягә текәлеп карап тора. «Ак калфак» җыры ишетелеп куя.)* Әйе... Мин Габделхак Ишмуллин... түгел... Кичерегез... Катрин, мин сине анда көтәрмен... *(Чыга.)*

И в а н о в. Габделхак! Ишмуллин! Тукта! Китмә! *(Катринга карап.)* Миңа бит исән партизаннардан имза кирәк. Минем француз партизаннарында сугышып йөргәнгә ышанмыйлар. Зинһар өчен, расла! Габделхак! Китте... Нишләгән ул? Үзгәргән. Шундый саф күңелле егет...

Ш ә м с и я. Димәк, үзегез дә икеләнәсез?

И в а н о в. Шундый саф күңелле егет... Әнисенең ак калфагын иң авыр чакларда югалтмый саклаган җан...

Ш ә м с и я. Ак калфак? *(Хәлсезләнеп утыра.)* Габделхак... Улым...

А к ч у р и н. Шәмсия апа, ни булды сезгә?

К л а р а. Тотыгыз аны... ярдәм итегез... *(Шәмсияне ике ягыннан тотып алалар.)*

Ш ә м с и я. Балам... Габделхак...

И в а н о в *(аның янына килеп)*. Әйттем бит, Габделхак дип...

Ш ә м с и я. Кем уйлаган... Күпме еллар көттем. Үлем хәбәрен алгач та өметне өзмәдем. Кире китерегез аны! Күреп калыйм... Чәчләреннән сыйпыйм, күзләренә карап калыйм. Чакырыгыз Габделхагымны...

С а ф и я *(телефонга барып номер җыя)*. Мистер Клиффорд! Жак әфәндене, ягъни Габделхак Ишмуллинны әнисе Шәмсия Ишмуллина чакыра. Ә? Ничек? Мин бернинди Габделхакны да белмим, ди?

К а т р и н. Әни... Каенана... Бу мин... сезнең киленегез Катрин Люсиль...

Ш ә м с и я. Минем киленем бармыни?

К а т р и н. Исәнмесез, әни? Мин сезне күрергә күптән хыялландым. Жак риза булмады. Ул үзе гел сезнең хакта сөйли, төшләрендә күрә.

Ш ә м с и я. Ә нигә әнисен күрергә теләми?

К а т р и н. Ул әйтә: «Әгәр анда минем исәнлекне белсәләр, әнигә дә, нәсел-нәсәпкә дә көн күрсәтмәсләр»,— ди. Шунлыктан үзенең исемен дә, фамилиясен дә алыштырды. «Габделхак Ишмуллин дөньяда юк, сугыш кырында ятып калды»,— ди. Кемнәрдер өчен бар, кемнәрдер өчен — юк...

Ш ә м с и я. Нигә соң без шулкадәр шәфкатьсезләр?! Улым... балам... Габделхагым...

Казан ягы җыр башлый. Сан-Франциско күтәреп ала.

Казаннардан мамык шәл алдым,
Алтын тәңкә бирдем җәлләми.
        Ак калфагым төшердем кулдан,
        Безнең дус-иш белән ил тулган.
        Безнең дус-иш белән ил тулган,
Алтын тәңкә бик зур мал түгел.
Бер дә күрешүләр әллә ни.
        Ак калфагым төшердем кулдан...
        Ак калфагым төшердем кулдан...

П ә р д ә.

*1990*

# Гашыйклар тавы

*Мәхәббәт кыйссасы*

**Катнашалар**

Мөнирә Идрисова
Сәет Зилаиров
Ләлә
Өмет Зилаиров
Мирсәет Зилаиров
Алсу
Сафа
Яшьләр

1940—1980 елларда булган хәлләр

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәетнең төше. Картайган, ямьсезләнгән Сәет һәм япь-яшь Мөнирә.

Сәет. Исәнме-саумы, Гашыйклар тавы! Бу мин — дошманны бик тиз генә җиңеп кайтырга киткән Сәет Зилаиров. Сугышның башыннан алып ахырына кадәр ут эчендә йөреп, әллә ничә үлеп, әллә ничә терелеп, мин сиңа әйләнеп кайттым! Әллә инде танымыйсың? Исәнме-саумы, яшьлек серләремне сыйдырган, хисләремне үз иткән, сөю шатлыкларын-газапларын юллаган Таллыкүл урманы! Мөнирә, җиләгем, син, мөгаен, без очрашкан урында мине көтәсеңдер... Мөнирә-әү! Ау-у! Син кайда?!

Мөнирә тавышы. Ау-уу! Син кем?

Сәет. Бу мин... Сәет!

Мөнирә. Ой! Сез кем?

Сәет. Мөнирәм! Җиләгем! Син бөтенләй үзгәрмәгәнсең... Кил, кочыйм...

Мөнирә. Кит... Кагылма!

Сәет. Танымыйсыңмыни, Мөнирә? Әллә оныттыңмы яшьли сөйгән ярыңны?

Мөнирә. Минем яшьли сөйгән ярым Сәет... Син... Сәет түгел!

Сәет. Мин чын Сәет...

Мөнирә. Мин синнән куркам. Син качкын!

Сәет. Мөнирә, исеңдәме... без синең белән шушы болында очраштык...

Мөнирә. Минем Сәетем бөтенләй башка...

Сәет. Нинди иде соң ул?

Мөнирә. Ул яшь иде. Башы горур, күтәренке иде. Чәчләре куе, чем-кара иде. Аның битләре алсуланып, ут кебек янып торыр иде. Мондый ямьсез эзләр, килбәтсез кыяфәт...

Сәет. Мөнирә!

Мөнирә. Ой! Якын килмә! Син — качкын!

Сәет. Әйе, мин тегендә немец әсирлегеннән качтым. Әмма үзебезгә качтым, аннан соң да әле сугыштым, яраландым. Мине ядрәләр җәрәхәтләде, ярчыклары битләремне умырды, фашист итекләре, аларның этләре тәнемдә җуелмас эзен калдырды. Мине кистеләр, турадылар, ялгадылар. Шулай да мин, Мөнирә, исән... ышан, мин синең Сәетең.

Мөнирә. Ышанмыйм. Сәетнең нәфис бармаклары гармун уйнау өчен генә яратылган иде.

Сәет. Гармунның үзен биеткән моңлы бармакларымны изделәр, таптадылар, Мөнирә. Мин Сәет... кил әле кочаклыйм үзеңне, элеккечә кочагыңда югалыйм... Онытыйм бөтен күргән газапларымны...

Мөнирә. Якын килмә! Син Сәет түгел! Хәзер кычкырам! Килгән юлыңнан кире кит!

Сәет. Кычкырма... зинһар... Күзләремне тутырып бер карыйм да... китәм... мәңгегә, кайтмаска китәм...

Мөнирә. Кит! Кит! Югал!

Сәет уяна.

Сәет. Мөнирә... Мөнирә! *(Акылына килеп.)* Ләлә...

Ләлә кайтып керә.

Ләлә. Ни булды, Сәет?

Сәет. Болай гына... Саташтыра...

Ләлә. Инсульттан соң ялгыз калдырырга ярамый шул сине, ярамый.

Сәет. Сул кул кыймылдаганда әле яшәргә була. Концерт ошадымы? «Сагыну» ансамбле миннән башка җырлый аламы?

Ләлә. Синең рухың анда, синең җырың...

Сәет. «Яралы кош»ны җырладылармы?

Л ә л ә. Аңардан башка концерт узамы соң инде.

С ә е т. Мине искә алалармы?

Л ә л ә. Очраган берсе сине сорый. Бүген нинди төшләр күрдең?

С ә е т. Күрәсе төшләремне күреп бетердем инде, ахрысы...

Л ә л ә. Алай димә, Сәет...

С ә е т. Сизеп торам, лампам эчендә май кими.

Л ә л ә. Кимүен кимеми... Әмма мин башка бер нәрсә тоям, Сәет, миңа әйтергә ярамый торган ниндидер бер сер газаплый кебек сине. Төннәр буе йоклый алмыйсың, йоклап китсәң, саташасың. Ачыл, Сәет, үзеңә җиңел булып китәр. Минем алдымда гаебең булса да, яшермә, кичерермен...

С ә е т. Син изге кеше, Ләлә!

Л ә л ә. Кем ул Мөнирә? Мөнирә кем ул?

Сәет дәшми.

С ә е т. Мөнирә? Нинди Мөнирә?

Л ә л ә. Бу сорауны мин сиңа бирәм. Ачуланмыйм, үпкәләмим, әйт, Сәет, кем ул Мөнирә?

С ә е т. Син каян беләсең?

Л ә л ә. Димәк, Мөнирә чынлап та бар...

С ә е т. Син... син... мин...

Л ә л ә. Саташасың, аны чакырасың. Аның урынына мин киләм.

С ә е т. Ләлә, су бир... Утыр... Мин бу сүзне үзем башларга кыймый идем. Озак еллар буе газаплаган серне чишәргә вакыт җитте. Мин аны үзем белән алып китә алмыйм. Хәзер инде сөйли дә алмам кебек... Хәтерем әллә ни түгел. *(Дәфтәр чыгара.)* Барысы да шунда...

Л ә л ә *(дәфтәрнең беренче битен ача)*. Ядкарь дәфтәре. Онытма мине! Онытмам сине! Мөнирәме ул?..

С ә е т. Мөнирә...

С ә е т т а в ы ш ы. Безнең Таллыкүл авылы Гашыйклар тавына терәлеп тора. Их, Таллыкүл урманнары! Беренче тапкыр мин Мөнирәне кара урманда күрдем...

Манзара үзгәрә. Урман-тауларның һәм геройларның яшь чагы.

Урманчы әтием үлгәч, мине, унтугыз яшьлек егетне, Таллыкүл участогына куйдылар.

К ы з л а р урманга җиләк җыярга килгәннәр.

М ө н и р ә. Кызлар, әйдәгез, ял итәбез!

Кызлар. Ял итәбез, ял итәбез!

Утырышалар.

Беренче кыз. Җиләк җыйдым чиләккә.
Икенче кыз. Берсен аттым...
Өченче кыз. Берсен каптым...
Мөнирә. Яна торган йөрәккә! Их, кызлар, йөрәк чынлап та яна икән ул! Әллә ни булды, акылдан язам!
Беренче кыз. Акылсыз кызны бер егет тә яратмас.
Икенче кыз. Әй, акыл егетләргә генә кирәк ул!
Өченче кыз. Ни сөйлисез, без бит әле укучылар гына...
Мөнирә. Теләсә ни әйтегез, мин — гашыйк булдым!

Сикереп торалар.

Кызлар. Гашыйк булдың?
Мөнирә. Гашыйк булдым!
Беренче кыз. Кемгә?
Икенче кыз. Хыялда?
Өченче кыз. Кинода?
Беренче кыз. Вахитка?
Икенче кыз. Заһитка?
Өченче кыз. Шәһиткә?
Мөнирә. Юк!
Кызлар. Әйт инде, яшермә, Мөнирә!
Мөнирә. Сер булып калсын!
Беренче кыз. Ул үзе беләме?
Мөнирә. Белми шул, кызлар, белми!
Икенче кыз. Онытырсың әле, бала!
Өченче кыз. Канатлана башлаган яшьлекнең җилкенүе!
Мөнирә. Кызлар, бу — шаяру түгел, мәхәббәтнең үзе!
Беренче кыз. Минем дә гашыйк буласым килә! Мөнирә...
Икенче кыз. Әйт әле, ничек гашыйк булырга?
Өченче кыз. Ни ул мәхәббәт?
Мөнирә. Ни ул мәхәббәт? Үзем дә белмим.
Һичбер сәбәпсез шатланам, көләм.
Сабый баладай дөньяга туам.
Хыялга очам, сагыштан үләм.
Гел үзем генә каласым килә.
Дуслардан качам. Тилерәм, шашам.
Әллә мин җырлыйм, әллә мин елыйм.
Хис урманына кереп адашам.

Белмим үзем дә, йөрәгем аша
Агамы утлар, агамы бозлар?
Түзә алмыйча ачтым серемне,
Әйтегез миңа, нишләргә, кызлар?

Беренче кыз. Әтиең — Сафа абзый сизсә... үтерә бит!

Икенче кыз. Үтерде ди... Аның да яшьлеге булган ич...

Өченче кыз. Мондый җилкенү бала йөрәктән
Килер дә китәр, сызлар да китәр,
Утлар да сүнәр, бозлар да китәр,
Исең китмәсен, узар да китәр!

*(Авызына бармагын куеп сызгыра.)* Әйдәгез, малайлар булып биибез!

Бииләр. Мөнирәне дә биетергә тырышалар.

Мөнирә. Юк, кызлар, көчләмәгез, булмый!

Кызлар. Алайса җырла!

Мөнирә. Малайкайларым, зинһар, дип сорыйм, мине урманда үземне генә калдырыгыз. Бәлки, җырлармын да...

Беренче кыз. Адашсаң, Сафа абзый үтерә бит үзеңне!

Икенче кыз. Калсын, әйдә, бик адашасы килсә, адашсын, әйдә!

Өченче кыз. Кара аны, адашсаң-нитсәң, кайтып керәсе булса!

Чыгалар.

Мөнирә. Каравылчы килеп чыксын өчен, нишләргә икән? Әһә! Япь-яшь ак каенны кисеп киткәннәр... Әһей! Каравылчы! Каеныңны кискәннәр! Юк, ишетмәде. Ул монда. Урман эченә кереп киткәнен күреп калдым. Кычкырганны ишетмәде... Җырлап җибәрсәм? Аны җыр ярата диләр...

Елмайдым — карамадың,
Юл бирдем — аңламадың,
Кул бирдем — аңламадың,
Син мине санламадың,
Син мине санламадың... *(Капланып елый.)*

Сәет *(мылтыгын асып керә)*. Ни булды?

Мөнирә. Берни булмады.

Сәет. Нигә елыйсың?

Мөнирә. Күрмисеңмени, адаштым ич.

Сәет. Әкияттәге үги кызмы әллә син? Кем адаштырды?

Мөнирә. Үзем адаштым ла мин...

Сәет. Курыкмыйча берүзең урманга килергә ничек батырчылык иттең?

Мөнирә. Җиләккә килгән ием лә...

Сәет *(кәрзинне карап)*. Шулай икән шул. Иптәшләрең ташлап киттеме? Әле генә тавышларын ишеттем.

Мөнирә. Үзем калдым ла мин...

Сәет. Тор, сеңлем, курыкма. Күрсәт әле йөзеңне...

Мөнирә. Әй, оялам ла мин... *(Йөзен ача.)*

Сәет. Сөбханалла, сөбханалла! Буй җиткән кыз икәнсең... *(Текәлеп карап тора.)* Исемеңне дә белик инде?

Мөнирә. Бәй, танымыйсыңмыни, Сәет абый?

Сәет. Исемеңне әйтсәң, бәлки, танырмын...

Мөнирә. Мөнирә ич мин.

Сәет. Кайсы Мөнирә? Нишләп мин белмим сине?

Мөнирә. Түбән оч Мөнирә.

Сәет. Сафа абзый кызымы әллә?

Мөнирә *(сөенеп)*. Әйе! Тугызынчы класс укучысы Мөнирә Идрисова!

Сәет. Тугызынчы класс? Укучы? Бала гына икәнсең шул әле.

Мөнирә. Мин балалыктан киттем инде.

Сәет. Аны каян беләсең?

Мөнирә. Әй... оялтмагыз инде...

Сәет. Әле син җырладыңмы?

Мөнирә. Ишеттегезмени? Мин бит әкрен генә. Кеше ишетмәсен дип кенә...

Сәет. Минем колак сизгер. Кош сайравын да биш чакрымнан ишетәм. Димәк, син җырладың?

Мөнирә. Мин җырламадым... еладым...

Сәет. Бик тә матур, бик тә моңлы елыйсың икән. Сер булмаса, әйт әле, сеңлем, кара урман эчләренә кереп кызлар нигә елыйлар?

Мөнирә. Балачак белән аерылышу бер елата, бер җырлата.

Сәет. Хәзер мин синнән сынау алам. Ризасыңмы?

Мөнирә. Риза.

Сәет. Мөнирә Идрисова, менә бу агач төбен кара әле.

Мөнирә. Карадым.

Сәет. Аны төнлә кисеп киткәннәр. Ул нинди агач? Аңа ничә яшь?

Мөнирә. Каен. Аңа унбиш яшь булган.

Сәет. Дөрес. Каян белдең?

Мөнирә. Каенның сырларын санадым.

Сәет. Утыр, Идрисова! Бишле! Шушы каен хәлендә

каласың килмәсә, ялгызың урманга чыгасы булма! Аңладыңмы?

Мөнирә. Юк, аңламадым.

Сәет. Курыкмыйсыңмы?

Мөнирә. Әй, курыктым, ди... Каравылчы бар ич...

Сәет. Әнә япь-яшь каенны харап иткәннәр. Сезнең кебек тыңлаусыз кызчыкларның һәрберсенә бер каравылчы кирәк. Аңладыңмы?

Мөнирә. Аңладым ла...

Сәет. Мә кәрзинеңне. Әйдә, юлга чыгарып куям. *(Кулларына кагыла.)*

Мөнирә *(куркып читкә ыргыла)*. Тотмагыз! Үзем дә кайталам...

Сәет *(ягымлы, назлы)*. Мөнирә... Шулай да әйт әле, нигә килдең урманга?

Мөнирә. Әйтимме?

Сәет. Әйт, Мөнирә.

Мөнирә *(оялып, башын иеп)*. Мин... сезне... яратам, Сәет абый! *(Йөзен куллары белән каплап, чыгып йөгерә.)*

Сәет. Мөнирә... тукта... *(Китә.)*

Кызлар кире әйләнеп керәләр.

Беренче кыз. Күрдегезме Мөнирәне?
Икенче кыз. Чынлап та гашыйк булган!
Өченче кыз. Нигә аның бәхетенә
Карт егет насыйп булган?
Беренче кыз. Кагылмагыз хисләренә.
Икенче кыз. Бу — бары кызык юктан!
Өченче кыз. Яман юлга кереп бара,
Коткарыйк бозыклыктан!
Беренче кыз. Ул үзе «сөям!» дип әйтте...
Икенче кыз. Ышанмагыз! Шаяра...
Өченче кыз. Чыннан да, язган акылдан!
Коткарыйк, табыйк чара!
Бала бер егеткә гашыйк!
Беренче кыз. Бер дә шаккатмасана!
Икенче кыз. Мәхәббәтен үзе әйтте...
Өченче кыз. Мондый хәл юк дөньяда!
Беренче кыз. Мәхәббәттә өченчеләр
Комачаулап йөрмәсен!
Икенче кыз. Кызык! Күзәтик артыннан!
Өченче кыз. Ул-бу була күрмәсен!

Чыгалар.

Мөнирә тавышы.

Нигә генә әйттем «Сөям!» диеп,
Йөрим бер суынып, бер янып,
Кешеләрдән генә түгел, хәтта
Үз хисемнән качып, оялып...

Л ә л ә  т а в ы ш ы *(Мөнирә ядкарен укый)*. Күзләреңә чалынудан куркып, син узган сукмаклардан, юллардан йөрим, ә хыялым, тагын бер мәртәбә күрергә ашкынып, без очрашкан зәңгәр болынга тартып китерә. Үзем, алларыма килеп чыксаң, поши баласы кебек, качарга әзермен. Әмма очрашудан качып кына котылу мөмкин түгел инде. Язмыш озак көттермәде, тагын кавыштырды. Исеңдәме, Сәет абый, без мәктәптә бәйрәмгә концерт әзерләгән идек. Мине җырлатыр өчен гармунчыны читтән чакырдылар.

Мәктәп сәхнәсе. Залда, алдагы рәттә — Мөнирә, кызлар, уртадарак — Сафа абзый.

К ы з л а р. Мөнирә җырласын, Мөнирә! Сорыйбыз! *(Кул чабалар.)*

М ө н и р ә. Әй лә... Мин гармунсыз җырлый алмыйм ич...

К ы з л а р. Бар гармунчы! Таптык!

С а ф а. Әйдә, кызым, ялындырма. Өйдәге кебек җырла!

Б е р  к ы з. Концертыбызны дәвам итәбез. Таллыкүл яшьләренең яраткан җыры: «Җиләккә бармам инде!» Җырлый үзебезнең Мөнирә! Гармунда уйнарга Сәет абыйны чакырдык. Әйдәгез, Сәет абый!

С ә е т *(залдан Мөнирә янына килеп)*. Мөнирә?

М ө н и р ә *(читкә тартылып)*. Сәет абый?.. Мин бит белмәдем. Кызлар эше бу. Мин куркам. Әти дә килгән...

С ә е т. Курыкма. Үзеңне ялгызың урманга барган кебек хис ит.

М ө н и р ә. Тавышым чыкса ярый ла...

С ә е т. Мин сиңа ярдәм итәрмен, Мөнирә. Башладык!

М ө н и р ә. Җиләккә дип барган идем,
Юри генә адаштым.
Сине күргәч, телсез калдым,
Адаштым дип алдаштым... Әй, булмый ла... *(Китмәкче була.)*

С ә е т. Синең йөргән юлларыңда
Җиләкләрем түгелде.
Салкын каравыңны белгәч,
Күңелләрем сүрелде.

Мөнирә. Җиләклеккә бармам инде,
Бармам инде, адашмам.
Карурманда адаштым дип,
Инде бүтән алдашмам...

Икесе ике якка ташланалар.

Мөнирә тавышы. Сәхнәдән ничек атылып төшкәнемне, кая таба йөгергәнемне дә белмим. Һушыма килгәндә, мин өйгә таба түгел, кап-кара төнне япа-ялгызым кап-кара урманга кереп барам икән. Исеңдәме, Сәет абый? Минем исемдә. Син дә шунда... басмада, күлдә йөзеп йөргән кыр үрдәкләренең тавышын тыңлап, моңаеп утыра идең...

Сәет, гармунын баш астына куеп, күккә карап ята.

Сәет тавышы.
Күзләрең шомырттай кара ич,
Йөрәкне яндырып ала ич,
Утларга, бозларга сала ич, —
Син әле бала ич, бала ич.
Карашың озата бара ич,
Күңелдә төзәлмәс яра ич,
Юк, килмә, бик ерак ара ич, —
Син әле бала ич, бала ич.
Карурман эчләре кара ич,
Җиләкләр тезелеп кала ич,
Үзәкләр өзелеп кала ич, —
Син әле, бала ич, бала ич.
Сәет *(тора, урманны тыңлый)*.
Өлгергән ич димәгез,
Җиләкләргә тимәгез.
Миндәй дивана булырсыз,
Яшь кызларны сөймәгез!

Мөнирә керә.

Мөнирә. Сәет абый...
Сәет. Мөнирә...
Мөнирә. Тс... с... Кеше ишетә күрмәсен...
Сәет. Ничек килдең?
Мөнирә. Төне буе йокламадым.
Сәет. Мин дә... сине уйладым.
Мөнирә. Мине? Чынлапмы?
Сәет. Әйе, Мөнирә. Ярый әле килгәнсең...
Мөнирә. Мин бик азга гына. Әти усал минем. Ул

иртә таңнан эшкә, мин монда йөгердем. Ой, үрдәк бәбкәләре...

Сәет. Кыр үрдәкләре алар.

Мөнирә. Кара, нигә алар курыкмыйлар?

Сәет. Мин аларны кулга ияләштерәм. Мөнирә, курыкма, кил әле монда... *(Гармун телләренә кагыла.)*

Мөнирә. Ой, уйный күрмәгез!

Сәет. Мин уйнарга уйламыйм, Мөнирә. Әнә күрәсеңме, миңа үрдәкләр дә ышаналар. Бир кулыңны. Кер басмага...

Мөнирә. Кермим, Сәет абый.

Сәет. Нигә?

Мөнирә. Сез мине барыбер яратмыйсыз. Бала дип уйлыйсыз. Мин сезне соңгы мәртәбә күрергә дип килдем. Башка күренмим... *(Басмага керә.)* Әй, егылам!

Сәет *(кочагына алып)*. Мөнирәм...

Мөнирә. Сәет абыкаем, зинһар, кагылмагыз...

Сәет. Сулышларым белән тартып алырдай булам. Мөнирәм, җиләгем, сине яратмый мөмкин түгел.

Мөнирә. Сәет абый, кирәкми...

Сәет. Мин нинди бәхетле, Мөнирәм...

Мөнирә. Яктыра... Мин кайтам...

Сәет. Килерсеңме, тагын килерсеңме?

Мөнирә. Килермен...

Сәет кочагыннан ычкынырга тырыша. Сәет үбә.
Сафа керә. Кулында чыбыркы.

Менә син кайда нишләп йөрисең икән, башсыз кыз! Ә син... ә син... карт башың белән балигъ булмаган кызны аздырып йөрисеңме?! Икенче бергә күрсәмме! *(Чыбыркысын шартлата.)* Ычкын моннан, урман карачкысы!

Сәет чыга.

Утыр! *(Мөнирә агач төбенә утыра.)*

Мин сиңа ни дип әйттем әле? Күпме тукыдым, син җүләр башка, сәгать җидедән соң өйдән аяк атлыйсы булма дип!

Мөнирә. Мин кич чыкмадым... таң атканда чыктым...

Сафа. Әле теләңә салынып утырасыңмы? Таң тишеренннән егетләр эзләп чапкан, оятсыз! Мин әйткәннәрне оныттыңмы?

Мөнирә. Онытмадым.

Сафа. Егетләр белән күрсәм, нишләтәм дидем?

Мөнирә. Үтерәм дидең.

Сафа. Әйттемме?
Мөнирә. Әйттең.
Сафа. Ә син нишләдең? Тыңладыңмы?
Мөнирә. Юк.
Сафа. Кем янына килдең?
Мөнирә. Үзең күрдең ич.
Сафа. Мин синнән сорыйм, ни эзләп шул зимагур янына чаптың? Шул... шүрәле янына!
Мөнирә. Ул шүрәле түгел.
Сафа. Әле яклап маташасыңмы?! Сиңа ничә яшь әле?
Мөнирә. Уналты.
Сафа. Ул карачкыга ничә яшь?
Мөнирә. Белмим.
Сафа. Болай булгач, син әле аның исемен дә белмисеңдер?
Мөнирә. Сәет.
Сафа. Әле, оялмыйча, авыз тутырып, шуның исемен әйтеп торасыңмы! Үзеңнең укучы бала гына икәнеңне оныттыңмы?! Ир-егетләр алар синдәй ачыгавызларны төп башына утыртырга, кәкре каенга терәтергә генә торалар! Әллә инде харап итеп тә ташладымы үзеңне? Хәзер үтерәм мин аны!
Мөнирә. Юк... ул андый түгел...
Сафа. Әйт соңгы сүзеңне!
Мөнирә. Мин аны яратам.
Сафа. Ә?! Йа Ходам, ни ишетәм... Ана карыныннан төшүеңә кайчан... Кабатла әле, ни дидең?
Мөнирә. Мин аны яратам.
Сафа *(чыбыркы күрсәтеп)*. Менә моны күрәсеңме? Мин моның белән, тыңламаса, җирән кашканы да туры юлга кертәм. Әгәренки шул сүзләреңне тагын бер кабатласаң — ярам! Мин аны яратмыйм, бүтән аның янына бармыйм, диген! Йә?! *(Ярсып Мөнирә өстенә бара.)*
Мөнирә. Мин аны яратам!
Сафа. Ах, син әле шулаймы? Атаңа буйсынмыйсыңмы? Киребеткән нәмәстә! *(Арка тирәсенә йомшак кына итеп суга.)* Яратасыңмы?
Мөнирә. Барыбер яратам!

Чыбыркы шартлавы һәм Мөнирәнең «Яратам! Яратам!» дигән тавышы ишетелеп тора.

Мөнирә тавышы. Исеңдәме, Сәет абый, сине балигъ булмаган кызны ялгыш юлга юнәлтүдә гаепләп, районга чакырып, эт итеп сүктеләр, тагын кабатланса, эштән куу белән янадылар. Әмма бернинди катгый чара

да безне аерырлык түгел иде инде. Без сирәк кенә, яшеренеп кенә, урманда очрашуны дәвам иттек.

Басмада Сәет Мөнирәне күтә. Караңгы.

Мөнирә *(кергә)*. Кыйгак-кыйгак!
Сәет. Бак-бак-бак-бак!
Мөнирә. Мине эзләп тап-тап-тап! *(Кача.)*
Сәет. Мин сине бәйле күзләрем белән дә эзләп табам, Мөнирәм...

Мөнирә кача, Сәет эзли. Ниһаять, Мөнирә — аның кочагында. Үбешәләр. Сәет шаярып кына егылган була, Мөнирә аны шаярып кына күтәреп торгызган була. Музыка.

Мөнирә. Әллә кем ни генә әйтсә дә,
Кабатлыйм кадерле исемне,
Кояшым чыкса да, батса да,
Барыбер яратам мин сине!
Сәет. Арада гайбәтләр йөрсә дә,
Кавышу чарасы табылыр,
Ямансу хәбәрләр килсә дә,
Яратам мин сине барыбер!
Мөнирә. Язмышым, аерма бәхеттән,
Табигать безне тиң яраткан,
Башканы теләмим яшьлектән,
Барыбер мин сине яратам!

Гашыйклар тавына күтәрелергә баралар. Шулвакыт җыр өзелә. Алар тау итәгендә туктап калалар.

Ләлә *(ядкарь дәфтәрен дәвам итә)*. Сугыш башланган елны миңа унсигез яшь тулды. Яуга киту хәбәре сиңа көз көне килде. Йа Хода, кавышып та өлгермәдек, аерылышабыз да... Язмышларыбызны бәйләп өлгердек, авыл советына барып язылыштык. Әткәйне урман кисәргә озаткан идек. Исеңдәме, Сәет абый, аерылышу көнебез...
Сәет. Безнең сәгать сукты, Мөнирә...
Мөнирә. Исән йөреп, сау кайта күр инде, Сәет абый...
Сәет. Әй, безгә ни булсын, бер ай да узмас, дошманны үз җирендә, көлен күккә очырып, кайтып җитәрмен.
Мөнирә. Шулай гына була күрсен.
Сәет. Кешеләр генә түгел, киек кошлар да әйләнеп кайталар әле.
Мөнирә. Карале, бу кыр үрдәкләре нигә китмиләр, вакыт ич инде?
Сәет. Алар, киткәч, нигәдер кире кайттылар.

Мөнирә. Әллә юлларын сугыш бүлдеме? Нигә алар якын килмиләр, алар сиңа ияләшкәннәр иде бит?

Сәет. Кичә мин бер үрдәккә аткан идем, әллә шуңа микән?

Мөнирә. Аттың? Сәет абый, нишләдең? Нигә? Ни өчен?

Сәет. Мин бит урманчы гына түгел, сунарчы да. Аерылу төнендә учак ягып, кыр үрдәге белән сыйланып, Гашыйклар тавында икәү генә утыру иде ниятем.

Мөнирә. Хараплар иткәнсең, Сәет абыкаем... Үтердеңме?

Сәет. Үлмәде бугай. Күлгә килеп төшкәч, эзләгән идем, табалмадым. Мөгаен, яралангандыр. Ана үрдәк булды, ахрысы, балалары...

Мөнирә. Риваятьне оныттыңмы әллә, Сәет абый?

Сәет. Нинди риваять?

Ләлә тавышы. Элекке дәверләрдә Гашыйклар тавында түгәрәк тирән күл булган. Туган җирләрен сагынып, тезелешеп язларын киек кошлар кайтканнар. Көннәрдән бер көнне шул якның сунарчысы, нәни балалары белән күлдә йөзеп йөргән кыр үрдәген аткан да пешереп ашарга ниятләп, ут өстендәге казанга салган. Бер көн кайнаган үрдәк, ике көн, өч көн... Һаман пешми икән. Җиденче көн дигәндә, Серле үрдәк казаннан күтәрелеп зәңгәр һавага очкан... Шул көннән соң Гашыйклар тавының матурлыгы күзгә күренеп сулган, күле корыган... Бик озак еллар дәвамында гына тауның гүзәллеген кире кайтара алганнар...

Мөнирә. Оныттыңмы әллә, Сәет абый?

Сәет. Әй, ышанма иске йолаларга, берни булмас!

Мөнирә. Хәерлегә юрыйк... Менә алар нигә кире кайтканнар... Яралы кошны эзлиләр, таба алмыйлар. Нигә дип аттың, Сәет абый?

Сәет. Юкка борчылма, җиләгем, бер үрдәген югалтканнан Таллыкүл корымас. Без язмыштан өстен яңа чор кешеләре! Кара әле минем күзләремә... Онытмассыңмы мине, әйт, Таллыкүл буйлары ишетелерлек итеп!

Мөнирә. Менә ядкарь дәфтәре... Сакла... Онытма мине!

Сәет. Онытмам сине!

Җырлыйлар.

Сакла мәңгегә истәлегемне,
Исә юл җиле, аерылу җиле.
Сау бул, саф гөлем,
Зәңгәр яшьлегем,

Онытма мине!
Онытмам сине!
Калыр еракта Гашыйклар иле,
Кагылыр килеп яшьлегем җиле.
Кайтыр моң булып,
Әйтер мин булып:
Онытма мине!
Онытмам сине!
Тормыш юлында, гомерең соңында
Яшьлек дәфтәрен актарсаң иде...
Күңелең үсәр,
Исеңә төшәр:
Онытма мине!
Онытмам сине!

Мөнирә. Әйдә, Гашыйклар тавына күтәрелеп ант бирик!

Сәет. Әби-бабайлар әкиятенә ышанасыңмы? Син яшь бала шул әле...

Мөнирә. Борынгыдан калган гадәт, исеңә төшерәм, Сәет абый.

Ләлә тавышы. Шул тау башына менеп, гашыйклар бер-берсен ташламаска, гомер буе тугры булырга, шул урында кабат очрашырга вәгъдә биргәннәр. Кем дә кем антын бозса,— нинди дә булса бәла килә. Ул адәм йә авырый, йә үлә, йә бәхетсез язмышка дучар була...

Мөнирә. Киттек, Сәет абый!

Сәет. Әйдә, күңелең булсын...

Гашыйклар тавына мenәләр.

Мөнирә. Без икәү — Гашыйклар тавында,
Төн таңны озаткан чагында.
Сәет. Күзләрне тутырып карыйм бер
Сагышлы аерылу таңында.
Мөнирә. Аста — күл, үрдәкләр тирбәлә.
Китәргә юллары бүленгән.
Сәет. Мин барлык көчләрне җиңәрмен,
Мин өстен калырмын үлемнән!
Мөнирә. Онытма бу төнне, бу таңны,
Сәет. Ә мине? Киткәч тә онытырсың...
Мөнирә. Бөгелә-сыгыла гармун уйный,
Ул ничек онытылсын!
Сәет. Сагынганда нихәл итәрмен?
Көтәрсеңме мине?
Мөнирә. Көтәрмен!
Сәет. Вәгъдәме?

М ө н и р ә. Вәгъдә!
С ә е т. Очрашу таңнарын без көтик!
М ө н и р ә. Көтәрмен. Вәгъдәмне җил алмас.
Сүзләрне җыр белән беркетик!
С ә е т. Гашыйклар тавында,
М ө н и р ә. Гашыйклар җанында
Б е р г ә. Вәгъдәм дә, ядкарь дә югалмас!
В ә г ъ д ә җ ы р ы.

Ниндидер моңнар бар,
Ниндидер шомнар бар
Каеннар, имәннәр шавында,
Онытыйк шомнарны,
Каршылыйк таңнарны
Бергәләп Гашыйклар тавында.
Без — тауның башында,
Мәңгелек каршында —
Гашыйклар кавышкан урында.
Җанда — Ай нурлары,
Хисләр саф, югары:
Биектә — Киек Каз Юлында.
Син әле янымда,
Хушлашу таңында
Сүз бирик изге Җир алдында:
Аерылган көннәрдә,
Булыйк гел үрләрдә,
Булыйк гел Гашыйклар тавында!

Ләлә ядкарь укуны тәмамлап.

Аерылган көннәрдә
Булыйк гел үрләрдә,
Булыйк гел Гашыйклар тавында...

Ядкарь шунда өзелә...

С ә е т. Шул көнне мин фронтка киттем. Аннан соңмы: Окоп, үлеш, кырылыш... Соңыннан гына белдем, бер һөҗүмнән соң өйгә «үлде» дигән хәбәр җибәргәннәр. Дошман тылында йөрдем, үле гәүдәләр өстеннән шуыштым, чәнечтем, үтердем. Гашыйклар тавы яшьлекнең хыялый бер мизгеле булып кына калды. Өстеңә сызгырып бомбалар яуганда, һәр адымда үлем сагалаганда, яшьлек хатирәләре сүнә икән. Камалышта калып, күпме газап чиктем, яраландым, әсирлеккә эләктем, качтым, үзебезнең якка чыктым. Өйдәгеләр өчен мин — һәлак булган кеше... Аннан соң госпитальдә сине очраттым...

Л ә л ә. Шуннан соң без икебез монда — Себергә — минем туган җиргә киттек. Нигә син минем белән киттең, Сәет? Нигә Гашыйклар тавына, Мөнирәгә кайтмадың?

С ә е т. Белмим. Әллә әсир дигән хурлыклы тамга белән кайтып күренәсе килмәде... әллә... үзем дә аңлата алмыйм хәзер.

Л ә л ә. Нигәләр генә сөйләттем...

С ә е т. Мин сине алдамадым, Ләлә. Мин сине бик тә ихтирам итәм... Син булмасаң...

Л ә л ә. Ихтирам гына иткәнсең шул...

С ә е т. Еллар узды, җилләр исте үзебезнең Таллыкүлне искә төшереп, сулар акты тирбәлеп, атылган үрдәкне, юллары бүленгән киек кошларны хәтерләтеп... Тауга менгәндә тын кысыла башлады... без йөгереп менгән Гашыйклар тавын сагындырып... Саф җанлы табигать баласы Мөнирәгә: «Кайтырмын, көт!» — дигән егет мин түгелме соң? Гомеремнең соңгы еллары — тоташ газап... Ник кайтмадым Таллыкүлгә, Гашыйклар тавына, мин бит вәгъдәләр бирдем Мөнирәгә. Гөнаһсыз пакь күңелле яшүсмер, бәлки, мине көткәндер тилмереп... Әллә ничә тапкыр кайтырга, бу фани дөньядан киткәнче Мөнирәдән бәхиллек сорарга ниятләп карадым. Дүрт ел үлем белән көрәшкән һәм шул үлемне җиңеп чыккан солдатның шуңа батырлыгы җитмәде. Хәзер, бик теләсәм дә, кайта алмыйм... Вәгъдәгә хыянәт... Әллә, мин әйтәм, язмыш шуның өчен үземне каһәрлиме? Ярты гәүдәм хәрәкәтсез...

Л ә л ә. Сәет, тынычлан.

С ә е т. Хәзер... бөтен өмет синдә, Ләлә... Әгәр мин... әманәт тапшырсам... син... анда... бара алырсыңмы?

Л ә л ә. Кая?

С ә е т. Гашыйклар тавына. Мөнирәгә.

Л ә л ә. Гашыйклар тавына? Мөнирәгә? Мин?

С ә е т. Әйе. Син.

Л ә л ә. Мине... үзеңнең хатыныңны... аның янына? Юк! Юк!

С ә е т. Ләлә, бу... минем әманәтем. Мин... дөньядан аның бәхиллеген алмыйча китә алмыйм.

Л ә л ә. Мин сине шундый хәлдә ташлап китимме? Юк, Сәет!

С ә е т. Минем өчен борчылма...

Л ә л ә. Юк, Сәет, булмый. Кузгатма иске яраларыңны. Врач буларак әйтәм.

С ә е т. Бу... минем соңгы үтенечем...

Л ә л ә. Мин нишләргә тиеш?

С ә е т. Таллыкүл... Мөнирә Идрисовага шушы тасмадагы җырны тапшыр... *(Кассета бирә.)*

Л ә л ә. Ярый, Сәет, мин барам.

С ә е т. Мин сиңа ышанам, Ләлә... Сәлам барысына да... Таллыкүл камышларына, Гашыйклар тавына. Зәңгәр яшьлегемә... Хәерле юл!

«Яралы кош» җыры ишетелә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Җәй ахыры. Якында — шәрә тау. Суы бик аз гына калган, сазлыкка әверелгән күл. Басма. Анда, аякларын салындырып, М и р с ә е т белән А л с у утыралар.

М и р с ә е т. Их, җаныем, суларда...

А л с у. Су чәчрәтеп уйнарга!

М и р с ә е т. Чәчрәтерлек суы да юк...

А л с у. Камышлары бар ич. Мирсәет, күлгә керергә курыкмыйсыңмы?

М и р с ә е т. Медаль аласың киләмени?

А л с у. Нинди медаль?

М и р с ә е т. Суга батучыны коткарган өчен!

А л с у. Аласым килә! Килә!

М и р с ә е т *(балакларын сызганып)*. Бәхил бул, киттем! *(Төшә.)*

А л с у. Кара аны, батсаң-нитсәң, кайтып керәсе булма, җаныңны алырмын!

М и р с ә е т. Минем җаным юк, Алсу!

А л с у. Кайда?

М и р с ә е т. Саклык кассасына салдым.

А л с у. Нигә?

М и р с ә е т. Васыять калдырам, кайтмый калсам, барып алырсың.

А л с у. Үзең булмагач, синең җаның белән нишлим мин?

М и р с ә е т. Ярар, алайса, үзем белән алып китәм... Коткарыгыз, батам!

А л с у. Әллә чынлапмы?

М и р с ә е т. Валлаһи, батам! Алсу, бир кулыңны!

А л с у. Мине дә үзең белән күл төбенә алып китмәкче буласыңмы? Юк инде... Кара, мин сине шаярасың дип торам... Мә, тот!

Таяк сузуга, Мирсәет аны үзенә тартып төшерә. Аның кычкырган, бераздан тынган тавышы гына ишетелә. Алар күтәреләләр. Алсу — Мирсәетнең кочагында...

Алсу. Әрсез! Мәхәббәтсез! Чәчләрне туздырып бетерден...

Мирсәет. Иртәгә китеп югалачак сөйгән ярыңны коткарган өчен! *(Камыш җикәне суза.)* Төсем итеп сакла!

Алсу *(ала)*. Сине сагынып мин дә шулай саргаерга сүз бирәм. Әбәү, кыяфәтсез, ю тәпиләреңне!

Мирсәет *(аякларын юып)*. Әллә иясе бар инде бу күлнең? Аяктан тартты...

Алсу. Аяк юарлык суы да булмаган күлгә кем ия булсын...

Мирсәет. Алсу!

Алсу. Әү!

Мирсәет. Әгәр мине бик сагынсаң, аягыңны суга тык!

Алсу. Ярар. Аягымны гына түгел, башымны да тыгармын, яме?

Мирсәет. Ярар. Бу күлнең чыннан да иясе булган, ди...

Алсу. Әкият! Безнең оныклар нинди әкият сөйләгән булырлар икән?

Мирсәет. «Борын-борын заманда Таллыкүлдә бакалар бакылдаган, имеш...»

Алсу. Янәсе! Әй, безгә тавы ни дә күле ни... Барыбер китеп югаласы. Син — иртәгә...

Мирсәет. Син — бер елдан. Әле шушы кипкән бака күлен дә сагынган булырбыз... Мин бүген шушында узган балачагым белән саубуллашам.

Алсу. Кит аннан, котсыз, минем белән саубуллашырга килгән дисәм... *(Үпкәләп басмадан китә.)*

Мирсәет. Тукта инде, үпкәләмә. Аерылышу кичендә булса да, күзләремә караган бул. Яратам ич мин сине.

Алсу. Һи, сез тасма телләргә ышансаң... Китәсез дә онытасыз!

Мирсәет. Ә сез, кызлар — җилбәзәк күбәләкләр. Без китү белән...

Алсу. Ә сез, егетләр, берәр чибәр кыз күрсәгез...

Мирсәет. Ә сез — кызлар...

Алсу. Ә сез... егетләр... барыгыз да вәгъдәсезләр!

Мирсәет. Кем? Безме вәгъдәсезләр?

Алсу. Менә борынгылар ярата да, көтә дә белгәннәр...

Дуэт.

Барсы да узганнар,
Барсы да үткәннәр,
Элек тә кочканнар,
Кочкан-үпкәннәр.
Таһирлар киткәннәр,
Зөһрәләр көткәннәр,

Барсы да узганнар,
Барсы үткәннәр.
    Өзелеп көткәннәр,
    Түземнәр, сабырлар
    Гашыйклар тавында
    Мәңгегә калырлар.
Барсы да узганнар,
Барсы да үткәннәр,
Гашыйклар ярларын
Сагынып көткәннәр.
Егетләр киткәннәр,
Яшь кызлар көткәннәр,
Барсы да узганнар,
Барсы үткәннәр.
    Өзелеп көткәннәр,
    Түземнәр, сабырлар
    Гашыйклар тавында
    Мәңгегә калырлар.
Ә безнең мәхәббәт
Узмаган, алдадыр,
Гашыйклар тавында
Кавышыр таңдадыр.
Җил булып исәрмен,
Су булып агармын,
Мин сине югалтмам,
Эзләп табармын.
    Өзелеп көткәннәр,
    Түземнәр, сабырлар
    Гашыйклар тавында
    Мәңгегә калырлар!

Алсу. Мирсәет, куып тот мине! *(Аяк астыннан алып иске бер дәфтәрне аңа ата.)*

Мирсәет. Алсу, тукта!

Каршыларына Ләлә килеп керә.

Ләлә. Исәнмесез, матурларым?

Мирсәет. Исән булмасак, әллә син доктормы?

Алсу. Әссәлам-вәссәлам!

Ләлә. Әйе, мин чыннан да доктор. Әйтегез әле, Гашыйклар тавы кайда?

Мирсәет. Алдыгызда бит... әнә!

Ләлә. Шушымы?

Мирсәет. Ышанмасаң — анысы синең эш.

Ләлә. Ә Таллыкүл?

Алсу. Әллә сез Каф тау артыннанмы?

Л ә л ә. Себердән. Таллыкүл, чыннан да, шулмы?

М и р с ә е т. Шул димен ич инде!

Л ә л ә. Талы да, күле дә юк икән...

М и р с ә е т. Кирәге дә юк!

Л ә л ә. Мин... Мөнирә Идрисованы эзлим. Аны каян табарга?

М и р с ә е т. Алсушка, аның Мөнирә Идрисова белән сөйләшәсе килә!

А л с у. Барсын, сөйләшсен, бик кирәк булгач! Шушы тирәдә Мөнирә Идрисова!

М и р с ә е т. Әнә! Алсушка, йөгер, тотам!

А л с у. Тоттырмыйм!

Чыгып йөгерәләр.

Л ә л ә. Әллә алдадылармы Гашыйклар тавы дип... Корыган күл, сулган урман... Тукта, нигә соң әле мин үз иремнең сөйгәненә килдем? Кире китәргәме әллә? Юк, мине монда Сәетнең әманәте китерде... Үзеңне ничек тә җиңәргә тырыш, Ләлә... Бу нинди чәчәкле-җырлы дәфтәр? *(Ала, укый.)*

Каршылыйк яшьлекнең таңын
Яратып, кочак җәеп...
Онытма мине, Мөнирә!
Онытма мине, Сәет!

Ядкарь дәфтәре... Ташлаганнар... Тынычлан, йөрәк... димәк, көндәшем Сәетне күңеленнән йолкып аткан.

Яңа салынган өй ягыннан Ө м е т чыга. Болдырга утырып тәмәке кабыза.

Л ә л ә. Исәнмесез! *(Өмет дәшми.)* Исәнмесез!

Ө м е т *(теләмичә)*. Исән әле.

Л ә л ә. Зилаировларның өе шушымы?

Ө м е т. Шушы булса, ни әйтерсез?

Л ә л ә. Әллә сез Зилаиров нәселеннәнме?

Ө м е т. Булуы да ихтимал. Зилаировның кайсысы кирәк?

Л ә л ә. Сәете.

Ө м е т. Аның исеме генә калды... мәрмәр ташта. Үлгәннәрнең кемгә кирәге бар?

Л ә л ә. Сиңа, миңа...

Ө м е т. Сиңа нигә ул?

Л ә л ә. Мин аны бераз белә идем.

Ө м е т. Белә идегез? Әллә очраштыгызмы?

Л ә л ә. Фронтта. Ул яраланган иде.

Ө м е т. Аннан соң... терелдеме?

Л ә л ә. Терелде. Тагын һөҗүмгә китте.
Ө м е т. Сез аны исән чагында, чыннан да, күрдегезме?
Л ә л ә. Чыннан да.
Ө м е т. Кайчан?
Л ә л ә. 1945 ел. Май башы. Германия.
Ө м е т. Шуннан соң... сигезенче майда һәлак булды дип, икенче тапкыр үлем хәбәре килде.
Л ә л ә. Кызганыч.
Ө м е т. Ниндирәк иде ул? Төсе, холкы, табигате? *(Аракы алып чыга, өстәлгә куя.)* Егылып әчүне ташласам да, бу уңайдан әзрәк ярый да торгандыр... Утырыгыз... *(Рюмкаларга сала.)* Искә алыйк. *(Эчә. Ләлә авыз тидерә.)* Элегрәк килсәгез, өстәлдә кыр үрдәкләре булыр иде...
Л ә л ә. Алар ташлап киттеләрме?
Ө м е т. Без, ягъни, нефтьчеләр, аларны кырып салдык. Музейга куярга да калмады.
Л ә л ә. Сездә монда да бик каты сугыш булып узган икән... Табигать белән...
Ө м е т. Әйе. Сугыштык. Без җиңдек! Күкрәк тулы орден-медаль! Капкалап утырыгыз...
Л ә л ә. Сез җырлыйсызмы?
Ө м е т. Без бер генә җыр беләбез: «Салып җибәр салганны, сорама каян алганны! Салып җибәрсәң салганны, баса йөрәк янганны!» Әти кеше җырлый идеме?
Л ә л ә. Аның тавышы бик тә ямансу, моңлы иде.
Ө м е т. Берәр җырын хәтерләмисезме?
Л ә л ә. Онытылган. Искә төшерермен.
Ө м е т. Ул ниндирәк иде?
Л ә л ә. Күзләрендә ниндидер тирән сагыш... синеке кебек... Чәчләре дә синеке кебек каты... кара иде... Сез әллә аның туганымы?
Ө м е т. Юк. Мин аның туганы түгел. Мин Сәет Зилаировның үзе киткәч туган малае. Ягъни мәсәлән, Өмет...
Л ә л ә. Сәет Зилаировның малае бармыни?! *(Сикереп тора, үзен җиңеп, кире утыра.)*
Ө м е т. Балалары барлыгын да белмичә теге дөньяда ятучылар өчен! *(Эчә.)* Аның малае гына түгел, оныгы да бар әле. Әнә үзе килә... ягъни мәсәлән, минем малаем...

М и р с ә е т күренә.

М и р с ә е т. Исәнме?
Ө м е т. Нихәл! Менә... бабаңны фронтта күргән кеше килгән.
Л ә л ә. Ә-ә... без таныш инде.
Ө м е т. Бабаңны соңгы тапкыр күргән...

Мирсәет. Соң, күрсә?! Кайдадыр бер гармун ята иде бугай. Бир әле!

Өмет. Иске өйдә. Кереп ал!

Мирсәет өйгә керә.

Ләлә. Нигә ул... әтисе белән шулай...

Өмет. Аралар салкын. Әнисе белән калада... аерым...

Мирсәет *(гармунда русча көй акыртып чыга)*. Җаны бар әле моның!

Өмет. Бабаңның җаны анда... Аны да, мине дә армиягә шул озатты. Хәзер сине...

Мирсәет. Хәзер Гашыйклар тавына менәбез.

Өмет. Әби-бабайларың антны таң алдыннан биргәннәр.

Мирсәет. Безгә барыбер! Озатырга киләсеңме? Килмәсәң дә ярый!

Өмет. Киләм.

Мирсәет. Бәхил бул! *(Гармун уйнап чыга. Өстәлдәге аракыны кесәсенә алып тыга.)*

Өмет. Безнең якты киләчәк...

Ләлә. Өмет, бу дәфтәр сезгә таныш түгелме?

Өмет *(дәфтәрне ала, актара)*. Бу бит әнинең ядкарь дәфтәре. Каян алдыгыз?

Ләлә. Җирдә... аяк астында ята иде.

Өмет. Әйе... әйе... искә төште. Димәк, мин аны яңа өйгә күчкәндә чыгарып атканмын... Дөресен әйткәндә, мин аны, югалткач, эзләп тә карадым... Аннары кул селтәдем... Кызык... Ниләр язды икән?

Ләлә ядкарь дәфтәрен укый.

Йөзләрдә хәсрәте күренер,
Күзләрдә тамчылар күренмәс,
Кошларның юллары бүленер,
Ярымның юллары бүленмәс.
Толымым билемә уралыр,
Өметем кайгыга уралмас,
Киек кош юлларда югалыр,
Сөйгәнем яуларда югалмас! *(Бер өлешен Өметкә бирә.)*

Өмет. Көйләмә син миңа, авылым,
Яуларда үлгәннәр бәетен,
Туктатып сугышлар давылын,
Барыбер кайтыр ул — Сәетем!

Ләлә. Баламны күкрәккә кысам мин,
Ул сиңа охшаган шулкадәр!
Әйтмәгез, тыңламыйм, ышанмыйм:
«Үлде!» дип килсә дә йөз хәбәр...

М ө н и р ә *(сабый баласын кулына тоткан)*. Өметем минем, асыл егетем, үчтеки, үчтеки! Әттәне сагындыңмыни, мин дә бик сагындым шул аны. Хәзер кайтыр, озак көттермәс...

С а ф а керә. Кулында чыбыркы.

С а ф а. Көтмә, кызым, кайтмас Сәетең.

М ө н и р ә *(сабый булып)*. Нигә алай дисең, дәү әттә?

С а ф а. Үлем хәбәре килдеме, килде — факт! Тагын бер факт кирәкме? Урман кискәндә берәүне очраттым. Ул Сәетне әсирлектә күргән. Аннан соң кара кәгазь килде.

М ө н и р ә. Ул... үле килеш күргәнме?

С а ф а. Тиресе белән сөяге генә калган иде, ди... Бичара...

М ө н и р ә. Сөйләмә, дәү әткәй, минем әттә бичара түгел!

С а ф а. И кызым, атаң сүзен тыңламый ялгыштың. Әйдә, киттек үзебезнең өйгә, атаң нигезенә. Саргайма япь-яшь килеш үлгән иреңне көтеп... Тәрәзәне кадаклыйбыз да...

М ө н и р ә. Ачуланма, дәү әттә, без кайтмыйбыз. Без әттәне көтәбез.

С а ф а. Тач үземә охшагансың, киребеткән нәмәстә, тагы чыбыркы көтәсеңме? *(Селтәнә.)*

М ө н и р ә. Ул кайта, ул монда кайта, без моннан китмибез.

С а ф а. Әй, бала, бала... Үзең дә һаман нарасый шул... Чыбыркы түгел, тел тидерергә дә җәл... Теге вакытта чынлап суктырасы калган. *(Чыгарга кузгала.)*

М ө н и р ә *(чыбыркыны ала)*. Әткәй!

С а ф а. Акылга килдеңме әллә?

М ө н и р ә. Онытып калдыргансың...

С а ф а. Балалы өйнең матчасында чыбыркы булсын! *(Чыга.)*

Ө м е т *(дәвам итә)*.

Синнән тик бер ядкарь-дәфтәрең...
Югалтмый кадерләп сакладым.
Төшемдә күрәм дә сагынам
Өметнең яшь бала чакларын.

М ө н и р ә. Өмет, балам, нишләдең?

Ө м е т. Берни дә эшләмәдем.

М ө н и р ә. Кил әле, кил. Күлмәгең ертылган, борының канаган. Сугыштыңмы әллә?

Ө м е т. Сугыштым ла...

М ө н и р ә. Кем белән?

Ө м е т. Түбән оч малайлары белән.

М ө н и р ә. Кем башлады? Алармы? Хәзер әниләренә барам.

Ө м е т. Үзем!

М ө н и р ә. Нигә?

Ө м е т. Мыскыл итмәсеннәр...

М ө н и р ә. Ни дип мыскылладылар?

Ө м е т. Мине үрдәк диләр...

М ө н и р ә. Шуңа ачуландыңмы?

Ө м е т. Тагын бер әйтеп карасыннар!

М ө н и р ә. Дөрес әйткәннәр, Өмет. Без, чынлап та, үрдәкләр...

Ө м е т. Син дә мыскыл итәсеңме?

М ө н и р ә. Туктале, тыңла мине. «Үрдәк» дигәнгә бер дә үпкәләмә. Нәселебезгә мәңге чәпәлгән кушамат ул. Шәҗәрәбездә җиденче бабабыз да, аннан элгәреләре дә — үрдәкләр. Иң әүвәлге Әнкәбез — Гашыйклар тавындагы Серле үрдәк. Аны явыз бәндәләр атып Җиргә төшергәннәр. Канатлары сынган яралы кош Җирдә тормыш итә башлаган. Барыбер гел-гел сагышланып зәңгәр күккә караган. Шуңадыр без — яралы, моңлы нәсел. Үрдәкләр без!

Ө м е т. Минем үрдәк буласым килми!

М ө н и р ә. Буласың киләме, килмиме, син дә үрдәк, балам. Табигать язган язмышны син генә үзгәртә алмыйсың.

Ө м е т. Бел — кеше маймылдан килеп чыккан!

М ө н и р ә. Каршы килмим. Кайбер адәмнәр, чыннан да, маймылдан яралгандыр. Без — Таллыкүллеләр — кошлар нәселеннән...

Ө м е т. Каян алып әйтәсең моны, әнкәй?

М ө н и р ә. Хыялда да, төштә дә гел кош булып очам. Маймылдан яралган булсам, агач башына үрмәләүдән узмас идем. Нигә соң мин биеккә, кошлар югарылыгына күтәреләм дә, уяна-уяна гына Җиргә төшәм?..

Ө м е т *(укый)*.

Нинди уй бу газиз башымда,
Берсе дә аңламый иделәр:
«Өметең унсигез яшендә,
Әллә син хыялый...» — диделәр.

Л ә л ә. Кыен ул йокысыз төннәрдә
Җилләр дә тәрәзә чиртмәсә...
Хәсрәтем сөйләргә кемнәргә?
Өметем-балам да читләшә?

Ө м е т. Өметем-баламның һәр сүзе
Ут булып йөрәккә уелган.
Кул тартмый бу хакта язарга...
Гашыйклар тавына ни булган?

Бульдозер гөрелтесенә халыкның шау-шуы кушыла.

Мөнирә. Тукта! Сүндер моторыңны!

Өмет тавышы. Ни кирәк сезгә?

Мөнирә. Гашыйклар тавын мәсхәрәләргә без рөхсәт итмибез!

Өмет. Рөхсәт итмисез?! Сез? Безгә? Монда бораулау эшләре башлана. Әмер!

Мөнирә. Без аны дөрес түгел дип табабыз!

Өмет. Китегез юлдан!

Мөнирә. Тапта! Үткәрмибез!

Өмет. Дәүләт планын өзгән өчен җавап бирерсез! *(Танып.)* Әнкәй?! Син?! *(Юлдан күтәреп ала.)*

Мөнирә. Йа Алла... Өмет?.. Син?! Өздең өметләремне... Ник шуңа ризалаштың?

Өмет. Мин кушканны үтим. Туктале, нишләп юкка тавыш куптарасың? Котыртып, халыкны күтәргәнсең...

Мөнирә. Беләсең ич Гашыйклар тавының изге икәнен. Ул — Таллыкүлнең иманы...

Өмет. Изге... иман... Муллалар сүзен сөйлисең.

Мөнирә. Мәңге искермәскә тиешле йолалар бар. Гашыйклар тавы...

Өмет. Җитте! Монда дини картлар корбан чалалар. Димәк, бу урын, начальник әйткәнчә, искелек калдыгы. Без аны тар-мар итеп шуның хәрабәләрендә яңа тормыш корабыз!

Мөнирә. Гашыйклар тавында нефть юк!

Өмет. Син беләсеңме, безме?

Мөнирә. Тау астында су агып ята...

Өмет. Нәрсәгә таянып әйтәсең?

Мөнирә. Риваятькә! Үрдәк киткәннән соң, аның күле тау астына качкан.

Өмет. Дин әкиятләре!

Мөнирә. Борынгылар хак әйткәндер: тавын ташлап киткән Үрдәк менә шуңа күрә кайтмый да инде...

Өмет. Хыялый! Гомерең буе кайтмаган иреңне көтеп картайдың. Җүләр син, әнкәй! Без — эш кешеләре! Эш! Эш! Йолага килгәндә, аңла: чор — башка, җыр — башка, яшьләр, машиналары булмаса, тауга күтәрелергә иренәләр. Кайда туры килә... шунда...

Мөнирә *(Өметнең яңагына суга)*. Оятсыз!

Өмет. Ах, шулаймы?! Барыбер безнеңчә булыр!

Ләлә *(укый)*.

Очалмый төшкәндер — яралы...
Таллыкүл суында киек кош.
Хәбәр бу — юллары ураулы, —
Көтәрмен унар җәй, унар кыш.

Ө м е т. Күзәтәм киек кош эзләрен,
Китәрдәй булам ла кушылып,
Уянып язларын, күзләрен
Күңелем җилпенә кош булып...

Л ә л ә. Карурманда юри адашулар
Калды, ахры, матур төш булып,
Үзең кайталмасаң, төшләремә
Кайтчы, зинһар, очар кош булып...

М ө н и р ә. Сә-е-т!

С ә е т. Әү-ү!

М ө н и р ә. Син кайда?

С ә е т. Әллә кайларда!

М ө н и р ә. Тавышың кайтты, үзең — юк!

С ә е т. Кичер, Мөнирә, мин әлегә кайталмыйм!

М ө н и р ә. Сине шундый күрәсем килә, Сәет!

С ә е т. Мөнирәм, көт!

М ө н и р ә. Исән генә бул, Сәетем, сабыр канатларым сынганчы күтәрмен.

С ә е т. Мин Серле үрдәк белән бергә кайтырмын!

М ө н и р ә. Син әле үзең киткәч туган улың Өметне дә күрмәдең. Ул инде ир-егет, үзеңә охшаган...

С ә е т. Улым? Өмет? Күзләре нинди? Чәче?

М ө н и р ә. Тач үзең инде.

С ә е т. Каян алдың шундый ягымлы исемне?

М ө н и р ә. Әллә... үзеннән-үзе... ихластан...

С ә е т. Әй, гармунымны сагындым, Мөнирә. Тузан кунып, аның телләре күгәреп беткәндер инде.

М ө н и р ә. Сайраплар тора. Оныгың уйный.

С ә е т. Минем оныгым да бармыни? Исеме ничек?

М ө н и р ә. Мирсәет.

С ә е т. Тагын бер Сәет?

М ө н и р ә. Мин аңа тугач ук шулай дип дәштем. Башка исем юк.

С ә е т. Их, Мөнирәм, гармунда уйнап, сине җырлатып, Таллыкүл урманнарында адашырга!

М ө н и р ә. Әйдә, адашыйк соң...

Яшьлектән, томан эченнән ап-ак күлмәк кигән к ы з л а р пәйда була.

Б е р е н ч е  к ы з. Мәхәббәтең кайда? Сәетең?

И к е н ч е  к ы з. Калды бары дәфтәр битендә...

Ө ч е н ч е  к ы з. Ялгыз саргаюлар читен лә...

Б е р е н ч е  к ы з. Яшьлегеңне зая үткәрдең...

Ө ч е н ч е  к ы з. Их, Мөнирә, бик тә ялгыштың...

М ө н и р ә. Араларны Өмет якынайта.
Әнә! Әнә! Сәет! Ул кайта! *(Җырлый.)*

Карурманга барган идем,
Юри генә адаштым,

Сәет. Мине күргәч, телсез калдың,
Адаштым дип алдаштың.

Мөнирә. Синең йөргән юлларыңда
Җиләкләрем түгелде.
Кырын каравыңны белгәч,
Күңелләрем сүрелде...

Сәет, элекке кебек җырла!

Сәет. Тырышам бит.

Мөнирә. Без элек тырышып җырламадык, үзеннән-үзе...

Сәет. Ничек җырлый идек соң без, онытылган.

Мөнирә. Дәртле, сөенечле, өметле иде җырыбыз. Хәзер авыр хәсрәт тавышында. Әйдә, элеккечә җырлыйк...

Сәет. Җиләклеккә барма инде,
Барма инде, адашма... *(Үзе дә, тавышы да югала.)*

Мөнирә. Сә-ет! А-у-у! Син кайда?! Ник дәшмисең?..

Өмет *(укый)*.
Өмет, балам, икәү генә белик,
Уйга калып, тауга менәрсең...
Язу авыр моны: бер укырсың,
Акылыңа килеп, миннән соң...

Мөнирә *(тәсбих тартып, мөнәҗәт әйтә)*.
Халык китәр уңга-сулга,
Изге гамәл һич кылмаслар,
Ләкин мал күп булыр кулда —
Менә шундый заман җитәр...

Өмет *(кызмача кайтып керә)*. Һо, абыстай! Абстайновка шундый диген, ә?

Мөнирә *(дәвам итә)*. Ил гыйлеменә уку бетәр...

Өмет *(бер төргәк акча чыгарып ыргыта)*. Ал!

Мөнирә. Мәктәпләрне вәйран итәр...

Өмет. Ал, дим! Премия!

Мөнирә. Галимнәрдән чалма китәр...

Өмет *(аракы чыгарып)*. Стакан!

Мөнирә. Менә шундый заман җитәр...

Өмет. Кабымлык!

Мөнирә. Хатыннардан оят китәр!..

Өмет. Нәрсә мыгырданасың?

Мөнирә. Balалардан шәфкать китәр...

Өмет. Өеңдә динне пропагандалаган өчен дип, эшеңнән кудылар. Мине, партия кешесен, хур итәсең! Акчаны азсынасыңмы?!

М ө н и р ә. Миңа харам акчалар кирәкми.

Ө м е т. Нәрсә, хәер акчалары китерәләрме әллә?

М ө н и р ә. Мин беләм, сез эшләнмәгән эш өчен, алдап, премия аласыз...

Ө м е т. Син аңла, Алла бәндәсе, алдамасаң, премия тоттырмыйлар. Дәүләт безне алдый, без — дәүләтне! Ике як та канәгать. Тормыш — ул бер-береңне алдау. Менә син мескенне дә алдаганнар... Ярар, булган хәл булган... Тик мине бу дөньяга алдап китергәнсез икән, нигә әле мин алдамаска тиеш?! Хәләл ни, харам ни — безгә барыбер! *(Чыга.)*

Л ә л ә *(укый)*. Авылдан шәһәргә күчәләр.

Өмет тә күченә. Мин калам.
Берсе дә аңламый ич алар —
Юлларга чыгам да тукталам.
Язмышым нигезен калдырып,
Юк, китә алмыйм мин авылдан,
Сәетем, югалтып, каңгырып,
Эзләсә Гашыйклар тавыннан?!
Өнемдә, эшемдә, төшемдә,
Аңымда, җанымда, хисемдә,
Яуларга озаткан кичемдә —
Әйтелгән вәгъдәләр исемдә.

Ө м е т *(укый)*.

Син уяткан яшьлегем дә монда,
Вәгъдәләшкән тавым шушында.
Еракларда тоям сулышыңны
Таллыкүлнең синсез кышында.

Ө м е т. Әнкәй, исәнме?

М ө н и р ә. Ничек килдең, балам, күз ачкысыз буранда?

Ө м е т. Сине кар күмеп китмәдемени әле? Әйдә, киттек! Машинамны Зиречкледә калдырдым.

М ө н и р ә. Зиреклегә кадәр юл йөрерлекме?

Ө м е т. Йөрерлек! Киттек!

М ө н и р ә. Рәхмәт төшкерләре, юлны ачкансыз икән.

Ө м е т. Биклә ишегеңне!

М ө н и р ә. Кыстама, балам, мин моннан китмим.

Ө м е т. Таллыкүлдә бер җан әсәре дә юк... синнән башка... Яңа калада яңа фатирда уты балкып, кайнар суы агып, газы янып тора... Йә, әнкәй...

М ө н и р ә. Үзегезгә ошый икән, рәхәтләнеп яшәгез.

Ө м е т. Киттек!

М ө н и р ә. Китмим. Бер йомышым гына бар-барын...

Ө м е т. Әйт.

М ө н и р ә. Атнага бер булса да, юлын ачып тора алмассыз микән?

Өмет. Монысы нигә тагын?

Мөнирә. Әткәң кайтканда юлда адашыр...

Өмет. Их, әнкәй, саташасың түгелме?

Мөнирә. Бер дә саташмыйм, балам, әткәң юлга чыгарга җыена.

Өмет. Каян синдә шундый уй?

Мөнирә. Бүген төшемдә Гашыйклар тавындагы күлне күрдем. Серле үрдәк, төшәргә ниятләп, күл өстендә әйләнә, имеш. Бер канаты каерылса да, кайткан, җанаш! Кайта болай булгач әткәң, әзерлән!

Өмет. Бичара. Төшкә ышанасың...

Мөнирә. Ул исән. Күңелем тоя, ул кайтырга әзерләнә...

Өмет. Әнкәй, уян!

Ләлә. Үрдәкләр төшмичә китәләр.
Таллыкүл чалт аяз, юк — томан.
Минутлар, сәгатьләр үтәләр
Кавышалмый, Сак белән Сок сыман.

Өмет. Бу ялгызлык ник картайта икән,
Аңлат миңа шуны, төшендер.
Ядкарь булып калсын оныкларга,
Бу төш, бәлки, соңгы төшемдер?!

Мөнирә. Сәет, зинһар, төшемдә булса да, биш минутка гына кайт. Соңгы тапкыр сорыйм...

Сәет. Исәнме, матурым?

Мөнирә. Әлегә исән. «Матурым» дидең... Сине көтә-көтә әллә картаям да инде. Матурлыгым, исәнлегем улыма, оныгыма күчте, ахры.

Сәет. Карт көнендә нигезеңдә ялгызың калгансың түгелме соң? Балаларыбыз — Өмет, Мирсәет кайдалар?

Мөнирә. Киттеләр. Барысы да киттеләр. Таллыкүлдә — берүзем.

Сәет. Әллә бөтенләй ташладылармы үзеңне?

Мөнирә. Өмет күпме ялварды — күчмәдем. Рәнҗемим. Хәлемне белеп тора.

Сәет. Хәлең ничек, Мөнирә?

Мөнирә. Минем хәлем ярыйсы ла. Тик Таллыкүл өчен җаным әрни. Яшьләр Таллыкүлне ташладылар, бабаларыбыз калдырган юлдан каерылдылар, риваятькә, изге Җиребезгә хыянәт иттеләр. Матурлыгын файдаландылар да, картайтып, ямьсезләтеп, алыр нәрсәсе калмагач, ташлап киттеләр. Ничек сызланмыйсың! Ничә гасырлар сыналган иң асыл гадәтләрне, мең еллар сабыйлар бишеген тирбәткән моңны-телне ташладылар...

Сәет. Чыннан да, Таллыкүлгә ни булган? Танырлык

та түгел. Кыр үрдәкләре кайткан вакыт... Берсе дә күренми... Әллә мин гаепләме соң? Теге вакытта...

Мөнирә. Без һәммәбез дә гаепле Әнкәбез — Табигать алдында!

Сәет. Нигә дип аттым? Ник аттым?

Мөнирә. Синең вөҗданың сау, димәк... газапланасың. Кайтып керсәң, җаннарың тетрәр... Шәфкатьле җаннар яудан кайтмадылар шул.

Сәет. Нинди хозур иде Таллыкүл буйлары!

Мөнирә. Их, Сәет... Табигать шәрәләнеп калгач, адәмнәрнең җаны ярлыланды, тупасланды, мәхәббәтләре сүрәнләнде, туган җирләреннән суынды.

Сәет. Мин суынмадым. Мин элеккечә яратам, Мөнирә!

Мөнирә. Мин китәм шул инде, Сәет. Нигә элегрәк кайтмадың? Шулай да мин өметне өзмим... Өметем кала, Мирсәетем кала... Сау бул, Сәет, мин китәм...

Сәет. Тукта! Китмә! *(Мылтыгын алып ата.)*

Мөнирә. Их, харап иттең... Нигә аттың?

Сәет. Мин үрдәккә аттым.

Мөнирә. Үрдәк мин бит инде, Сәет!

Сәет. Янымда гына җан бирергә яткан ялалы кош... синме, Мөнирә?

Мөнирә. Мин, Сәет. Барыбер мин бәхетле, сине күреп, кайнар кулларыңда, туган җиремдә җан бирәм...

Сәет. Мөнирә, кичермә мине, бәхилләмә, каргап кит! Юк, ташлама мине! Син мәңге көтәргә дип, Гашыйклар тавында вәгъдә бирдең...

Мөнирә. Мин вәгъдәмә тугры калам, Сәет, көттем, көтәрмен анда да! Сау булыгыз, исән булыгыз, ике Сәетем, исән бул, Өмет!

Яктыра.

Өмет. Мин... исән... Нигә мин исән?!

Ләлә. Ул... үзе кайда? Минем аның үзен күрәсем килә. Аңа гына тапшырасы әманәтем бар.

Өмет. Минем дә аның янына бик барасым килә. Башымны күкрәгенә куеп, аның кичерүен сорыйсым килә. Әмма...

Ләлә. Димәк?

Өмет. Әйе... Шул басмада керләр чайкаганда... Васыятен әйтеп өлгерде: «Гашыйклар тавының ташын куегыз... Шулай дип языгыз:

*«Сәет!*
*Кайтырсың, шушында табарсың...*
*Өзмимен өметне. Мин көтәм.*
*Мөнирә».*

Ник, нигә бер сүз дә дәшмисез?! Йә, сүгегез эт итеп... кыйнагыз, типкәләгез «нинди ананы югалткансың!» дип... Сез бит сүгәргә, акыл өйрәтергә оста! Миңа хәзер бер коточкыч, аяктан егарлык сүз кирәк, үзәккә үтәрлек бер сүз! Сез бит сүз осталары, табыгыз бер сүз! Миңа ул сүзне әйтергә атам булмады... Әнием нечкә күңелле, юаш иде... Яңакка сугуы да иркәләү кебек кенә иде. Үтергеч бер сүз әйтегез миңа!

Ләлә. Өмет...

Өмет. Ялгышкан әнкәй. Мин Өмет булалмадым.

Ләлә. Өмет, менә синең үзеңнән соң нинди ядкарь кала?

Өмет. Нинди ядкарьме? Миннәнме? *(Өйгә кереп чыга.)* Менә ниләр кала: күмгәндә, кайгырган булып, алдан күтәреп барырга орден, медальләр, күкрәк киереп президиумда тагып утырган тимер-томыр, значоклар, олау-олау мактау кәгазьләре! Премия бирү турында приказлар! Тагын ниләр каламы? Кала... Актарылган таулар, сазлыкка әверелгән тирән күлләр, сүнгән чишмәләр, тар-мар ителгән куе урманнар, таланган Таллыкүл, бала хәсрәтен күтәрә алмыйча егылган ана туфрагы... мәхәббәтсез гаилә... куылган хатын... башында җилләр уйнаган бала... һәм бердәнбер куаныч биргән шушы... хәмер... кала... кала... Иң авыры шул, Таллыкүлне мәсхәрәләүдә катнашкан бәндәләрнең берсе мин! Рекорд артыннан рекорд куып, табигатьнең иң нәфис, иң илаһи җиренә бәреп кергәнбез. Әнә шулай Таллыкүлне таркаттык. Нигезендә бер әнкәй торып калды. Уйладым-уйладым да, соң булса да, әнкәй нигезендә йорт кордым. Иске өйгә дә кагылмыйм, ул — аның ядкаре. Гашыйклар тавына чияләр утырттым. Басмага карасам, әнкәм һаман керләр чайкый кебек. Шул кыяфәттә төшләремә килеп керә... Әнкәй яраткан шушы басмага кер чайкарга төшкәнмен, имеш...

Мөнирә тавышы. Өмет балам, бир, керләреңне үзем чайкап бирим.

Өмет. Әнкәй, кайттыңмыни?

Мөнирә. Мин әле кайтмадым. Керләреңне чайкашырга бик азга гына килдем.

Өмет. Кайда соң син? Тавышың бар, үзең юк.

Мөнирә. Бәй, улым, танымыйсыңмыни, алдыңда торам ич...

Өмет. Алдымда... үрдәк... син — юк...

Мөнирә. Шул үрдәк мин булам бит инде, балам.

Өмет. Серле үрдәк... син?

Мөнирә. Нигә гаҗәпләндең? Керләреңне бир әле, балам, анда юма, пычратасың ич. Менә монда су чистарак...

Ө м е т. Рәхмәт, әнкәй, якынрак кил, башыңнан бер сыйпап алыйм инде. Исән чакта бер генә дә иркәли алмадым.

М ө н и р ә. Юк, килмим. Мин адәмнәрдән куркам...

Ө м е т. Нигә куркасың?

М ө н и р ә. Адәм балаларының риваятьтәге явыз аучыдан аермалары юк.

Ө м е т. Без сиңа тимәбез, Серле үрдәк — әнкәм... Кайчан кайтырсың соң?

М ө н и р ә. Гашыйклар тавындагы күлне үз урынында күрмичә, Таллыкүл урманнары шауламыйча, кешеләргә шәфкать иңмичә, кайта алмыйбыз! Кайта алмыйбыз!

Ө м е т *(төштән өнгә кайтып, сикереп тора)*. Үрдәк! Кыр үрдәге! Кайта! Кайта! Төшсә ярар иде! Тагын бер үрдәк... ике...

Л ә л ә. Әллә берсе яралы инде... бик авыр... газапланып оча...

Ө м е т. Төшәләр... Яралы кошның исән калган балалары... Алар аерылу алдыннан күлләре белән саубуллашырга килгәннәр... Их, әнкәй белән әткәй генә күрмәделәр шушы көнне!..

Шулвакыт Ләлә магнитофонда Сәетнең «Яралы кош» җырын җырлата башлый.

С ә е т җ ы р ы.

Кыр үрдәген аттым очкан чакта,
Җаным әрни көн-төн, ник аттым?
Хәзер үзем яралы кош сыман,
Кайтыр юлларымны югалттым.

Ө м е т. Кем җырлый?! Тавышы әллә нинди... таныш кебек...

Л ә л ә. Бу... әманәт...

Ө м е т. Әманәт? Нинди әманәт?

Л ә л ә. Тыңла.

С ә е т җ ы р ы.

Туган якларыңа кайт! Кайт!» диеп,
Киек кошлар тезелеп киткәндер.
Кайта диеп өзелеп көткәндер дә,
Көтә-көтә түземе беткәндер...

Ө м е т. Кем җырлый шулай үзәкне айкап? Кем ул?

Л ә л ә. Өмет, бу әманәт-җырны мин Мөниргә, бары тик Мөнирәгә тапшырырга тиеш идем. Ул — юк. Җырлаучы — Сәет Зилаиров...

Ө м е т. Сәет... Зилаиров? Әткәй? Ул исән?! Башта ук

мин нидер сизендем. Сез нидер яшерәсез. Әйтегез, ул исәнме? Кайчан җырлады ул? Фронттамы?

Л ә л ә. Юк.

Ө м е т. Соңгы һөҗүмгә керү алдыннанмы?

Л ә л ә. Юк. Сугыштан соң.

Ө м е т. Димәк, ул чыннан да исән?!

Л ә л ә. Әйе. Ул бүгенгесе көндә исән.

Ө м е т. Минем эткәм исән!.. *(Таута йөгереп менә.)* Һәй! Таллыкүл! Гашыйклар тавы! Ишетәсезме?! Минем этием Сәет Зилаиров исән! Әнкәй аны юкка гына көтмәгән!

Л ә л ә. Мин васыять-җыр тапшырырга килгән идем. Теләгеңне үти алмадым, Сәет... Яшьлегең, хисләрең давылланган Гашыйклар тавы белән очрашкач, синең миннән яшерелгән газапларыңны үз йөрәгемә алдым. Син миңа тагын да якынрак, кадерлерәк... Бәхиллә, Мөнирә, фани дөньяның язмыш урманнарында адашкан әрнүле бер җанын. Синнән соңгы язмышында аның тән һәм җан яраларын җиңеләйтергә тырышкан бәндәне — мине дә бәхиллә. Кичер, Мөнирә, хатын-кыз буларак, мине дә аңла, юлга чыгар алдыннан, мин сине килешә алмаслык көндәшем итеп тойдым. Яшермим, күкрәгем тулы шик, йөрәгем тулы авыр тойгы иде. Мин синең илаһи хис белән Сәетне көтүеңне белмәдем. Кичер, Мөнирә, Сәетнең тоткарлануында, бәлки, минем дә гаебем бардыр?! Язмыш безнең өчебезгә дә газаплы мәхәббәт юллаган.

Ө м е т. Кайда ул? Мин аны хәзер барып алам!

Л ә л ә. Ул еракта... Себердә...

Ө м е т. Әллә кайда, сөргендә булса да, алып кайтам. Минем аны эзләп табып, күзләренә туры карап, сорыйсым килә: «Эткәй, нигә син безгә исән булуыңны хәбәр итмәдең, кайтмыйча ничек түздең син?» Эткәй...

С ә е т җ ы р ы.

Яралы кош, бәлки, кайтып җитәр,
Мин язмыштан инде ычкынмам.
Танырсыңмы, юкмы, мин булырмын
Кош тавышы белән кычкырган...

Үзәк өзгеч тавыш белән кыр үрдәкләре кычкыра.

П ә р д ә

*1965—1993*

# Эзләдем, таптым, югалттым...

*Ике пәрдәле драма*

**Катнашалар**

Алмас Уразов — эшкуар, 40 яшьтә.
Таңзифа Уразова — анасы, 70 яшьтә.
Инсаф Уразов — улы, 18 яшьтә.
Чаңбаев Шәмси Корбанович — 72 яшьтә.
Халисә Сарманаева — эстрада артисткасы. Прологта — 18, вакыйга дәвамында — 40 яшьтә.
Айгөл — 18 яшьтә.
Сәләх — 40 яшьләр чамасы.
Мирхуҗа — тән сакчысы.

Вакыйга 90 нчы елларда бара.

## ПРОЛОГ

Халисә тавышы.

Без — кешеләр — дөнья көтүчеләр,
Гомер буе нидер көтәбез.
Тал-тирәктә җилдә бөгелсәк тә,
Егылмыйбыз, сабыр итәбез.
Озак-озак өзелеп көтүләрнең
Ни икәнен үзем беләм мин,
Тик ятларга берни сиздермимен,
Тыштан елмаям һәм көләм мин.
Озак көтеп мин картаям, ахры,
Еллар саргаймыйлар бит алар.
Хатирәләр синнән аерылган
Яшьлегемә алып китәләр.

Пәрдә күтәрелә. Еракта тал-тирәкләр, каеннар урап алган Казансу манзарасы. Сәхнәнең уң ягында — тал-тирәк. Уртада — Изгеләр чишмәсе. Ул матур итеп бизәлгән — мәрхүм Сөләйман ядкаре.

Унсигез яшьлек Х а л и с ә бизәкле көянтә-чиләкләрен күтәреп чишмәгә килә. Яшеренгән урыныннан унсигез яшьлек А л м а с чыга.

А л м а с *(әкрен генә)*. Халисә...

Х а л и с ә. Әбәү, кем бу?

А л м а с. Тс-с-с... Кычкырма.

Х а л и с ә. Алмас?! Син?

Алмас *(чиләкләрен тотып)*. Әйдә, читкәрәк...

Х а л и с ә. Ни булды?

А л м а с. Безне беркем дә күрмәсен...

Х а л и с ә. Берни аңламыйм.

А л м а с. Мин синең белән саубуллашырга килдем.

Х а л и с ә. Күзең башкага төштеме?

А л м а с. Кит әле, аның кайгысымы?

Х а л и с ә. Миннән суындыңмы әллә?

А л м а с. Әй, бәйләнмә әле...

Х а л и с ә. Мине калдырып кая китәсең? Укырга бергә китәргә уйладык ич! Мин — театр училищесына, син этиең юлыннан — тарих бүлегенә...

А л м а с. Төкерәм тарихка... Барсына кул селтәп, миңа китәргә туры килә.

Х а л и с ә. Кая китәргә?

А л м а с. Әлегә үзем дә белмим. Кой чиләгеңне башыма, янам. *(Чиләктәге суны башына коя.)* Белмим! Поезд кая алып китсә — шунда!

Х а л и с ә *(чиләкләрен җиргә куеп)*. Беркая да китмисең! Җибәрмим!

А л м а с. Мин җинаять эшләдем.

Х а л и с ә. Ышанмыйм! Булмас!

А л м а с. Качып котылмасам, мине төрмә көтә!

Х а л и с ә. Ни сөйлисең?! Алмас, ни эшләдең?

А л м а с. Мин Чаңбаевны кыйнадым. Әйе, әйе, дөмбәсләдем!

Х а л и с ә. Ах...

А л м а с. Башта аракы шешәләреннән төзи башлаган йортын җимердем. Аннары үзен... Гомер буе җыелган үчне алдым.

Х а л и с ә. Нигә? Ник?

А л м а с. Үзең дә беләсең. Әтинең газапланып үлүенә гаепле адәм — шул Чаңбаев! Әти үлгәч, әнине үзенә көчләп кияүгә алган — шул Чаңбаев! Анам да гаепле! Аны да кичермим...

Х а л и с ә. Алмас, тынычлан, үзеңне кулга ал.

А л м а с. Тагын бер минут торсам, мине кулга алачаклар. Сау бул!

Х а л и с ә. Бөтенләй ташлыйсыңмыни?

Алмас. Бөтенләйгә түгел, Халисә. Көтсәң, без бергә булырбыз. Көчең җитәрме көтәргә?

Халисә. Гомерем буе көтәрмен, Алмас. Исән генә була күр. Шуны гына әйт, кайчан кайтырсың?

Алмас. Кайчан да кайчан мине эзләүдән туктарлар, шунда кайтырмын. Дөнья бетереп эзләрләр-эзләрләр дә бервакыт онытырлар. Ул кайтыр, тик инде бу Алмас булмас. Ул баеп кайтыр!

Халисә. Ничек кенә булса да кайт!

Алмас. Минем атамны ярлы булганы өчен гомер буе кимсеттеләр, көн күрсәтмәделәр. Ул үзе дә гаепле инде. Мин аңладым, Халисә, безнең хәзер синең белән энәбез дә юк. Без бергә тормыш корсак та, син кайчан да булса, анам кебек, мине ташлап китәчәксең.

Халисә. Ни сөйлисең, Алмас, юк, юк!

Алмас. Анам да яшь чагында ташламаска вәгъдә биргән... Тормыш — анасын ормыш! Мине эзлиләр, озак торырга ярамый. *(Кузгала.)*

Халисә. Тукта, тагын бер генә сүз...

Алмас. Тотма, мин киттем... Миннән озак кына бер хәбәр дә килмәс, барыбер көт! Әллә нинди гайбәтләр килер — көт! Өйләнгән дисәләр дә ышанма! Көтеп арысаң тот та бер картка кияүгә чык!

Халисә. Ахмак!

Алмас. Тагын бер әйт шул сүзеңне!

Халисә. Ахмак!

Алмас. Үлсәм генә көтмә. Хуш, исән бул! *(Кочаклап үбә дә югала.)*

Халисә. Алмас, бер генә сүз...

Сәхнә караңгылана.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Унсигез елдан соң...
Шул ук урын. Уң якта — ауган тал-тирәк. Сулда — буш шешәләрдән корылган йорт. Җәй көне.
Шәмси сәхнә кора. Сәләх керә.

Сәләх *(тирләп-пешеп)*. Уф, яндым, харап булдым, беттем!

Шәмси. Ни булды?

Сәләх. Хәзер егылам да үләм!

Шәмси. Өең яндымы?

Сәләх. Юк шул.

Шәмси. Таладылармы?

Сәләх. Юк ла...
Шәмси. Хатының куып чыгардымы?
Сәләх. Әйбәтрәк булыр ие...
Шәмси. Милициягә эләктеңме?
Сәләх. Юк! Ычкынды!
Шәмси. Чуртанмы?
Сәләх. Чуртыма кирәкме ул! Пычаксыз суйды! Үзен суясы калган!
Шәмси. Исерекме?
Сәләх. Исеректән дә болайрак! Качты, кабахәт!
Шәмси. Милиция чакырт!
Сәләх. Чөеп кенә ыргыта ул милицияңне! Качты дим ич!
Шәмси. Кем качты?
Сәләх. Мирхуҗа!
Шәмси. Кем соң ул?
Сәләх. Күрмәдегезме?
Шәмси. Бернинди Мирхуҗаны да белмим.
Сәләх. Таныттыра торган билгеләре: кәкре торба шикелле, анаңны сатыйм дип акырып торган ике мөгез...
Шәмси. Әллә үзең исерек инде...
Сәләх. Мирхуҗа айнытты... качып киткәч... Уф, арыдым... *(Ауган тирәккә утыра.)* Тагын бер билгесе: кып-кызыл койрыгы елан кебек муеныңа уралырга тора! Төшеңә килеп керсә, куркып качарсың!
Шәмси. Мирхуҗа булмады бу алайса, җен булды!
Сәләх. Син ни сөйлисең? Нинди җен? Үгез качты! Үгез! Их, бәйләп саласы калган!
Шәмси. Ә... ә... үгез... Мирхуҗа да Мирхуҗа дисең...
Сәләх. Авылның Мирхуҗа исемле үгезе. Күрмәдегезме? *(Тирен сөртә.)*
Шәмси. Нишләп Мирхуҗа?
Сәләх. Безнең Кәкре Елгада Мирхуҗа исемле тагын бер мир үгезе бар. Мал-туарлы җиде тол хатынга йортка керде. Малын ашап бетерә дә икенчесенә күчә, хөрәсән. Әй хәрәмләште дә инде көрәшкәндә... Соңгы тәкәне аяк чалып, сугышып алды, паразит! Егерме тәкә, унике үгез ашадым дип мактана, саламторхан! Җиде тол хатын моны тотып... печәргә булгач, читкә китеп олакты. Теге Мирхуҗа белән дошманнар ие. Күрмәдеңме Мирхуҗаны?
Шәмси. Кайсысын?
Сәләх. Икесен дә! Берсен дәүләткә тапшырасы! Икенчесе — аяк чалып мине аста калдырды соңгы сабантуйда. Очратсам, чын көрәшкә чакырам! Иң башта мөгезлесен табарга! Качты бит, качты!
Шәмси. Каян качты?

Сәләх. Ит комбинатына барабыз шулай. Без ветврач Гатуф белән кәефләнеп кенә кабинада утырган булабыз, бераз төшергән иек, билгеле. Тамак тагы да сорап кыткылдый бит. Ни өчен дигәндә, менә шушы сумкамдагы бер яртым этәч булып кычкыра, суккин сын. Туктаттык та шоферны, чөмерәбез Гатуф белән шешәнең богазыннан. Бераз баргач, шофер машинаны туктатты да, әйтә бит безгә: «Карагыз малны!» — ди. Карасак, тфү, беләгеңне чеметим, үгездән җилләр искән. Сикереп төшкән дә сызган, нәкъ шушы тирәдә, без салып утырган урында. Күрмәдеңме Мирхуҗаны?

Шәмси. Әллә кызыл иеме?

Сәләх. Ие, нәкъ! Үзе! Алкаш бите кебек кып-кызыл!

Шәмси. Маңгаенда агы бар идеме әллә?

Сәләх. Әйе! Әйе! Бар ие!

Шәмси. Юк, күрмәдем шул.

Сәләх. Әй, сине тыңлап торган мин җүләр...

Шәмси. Үгезең койрыгын тоттырыр дип уйлыйсыңмы?

Сәләх. Тота торган җегет басып тора алдыңда! Тотмаган нәстә калмады. Тирә-юньдә сабантуй батыры дип дан алган, беркемгә дә бил бирмәгән Сәләх булыр бу, бик белеп тор, абзыкай! Мир үгезен озатырга теләсә нинди селәгәй малайны җибәрми персидәтел. *(Кесәсеннән аракы шешәсен чыгара.)* Бераз калган әле монда. Кил, әзерәк тамызасыңмы? *(Үзе эчеп куя.)* Әгәренки шушы иблис котыртмаса, Мирхуҗага бирешер иеме Сәләх! Их, шушы булмаса, иң кимендә замминистр буладырыем мин! Ну көчле, каһәр, мине дә җиңә! Кил, сал!

Шәмси. Мин салдым инде саласын. Әнә кара, шешәләрдән йорт салып куйдым.

Сәләх *(карый)*. Ну, малай, салгансың? Берүзең салдыңмы?

Шәмси. Йортны берүзем салдым. Төзү материалын үзебезнең татар эчкечеләреннән генә җыйдым. Нигездә, шушы авылдан. Борынгы Болгарда булганың бармы?

Сәләх. Аның кайгысымы бездә...

Шәмси. Бабайлар калдырган манараларны күргәнең юкмы?

Сәләх. Рәсемдә күргән бар инде, анысы.

Шәмси. Милли казанышыбыз саналырлык бу корылманы мин киләчәккә калдырам. Оныклар, бәлки, чит кавемгә ияргән татарның ни өчен күтәрелә алмавын, егылуын аңлар. Профессор Чаңбаев!

Сәләх. Профессор?! Киләчәккә минем дә өлеш кер-

сен. Минем дә тарихта каласым килә. *(Буш шешәсен бирә.)*

Ш ә м с и. Мин инде эшне төгәлләдем. Бер шешә белән эләгерсең микән, ай-һай... *(Ала.)* Патша җәяү йөри торган корылмага булса да файдаланырмын.

С ә л ә х. Ну, малай, мондый әкәмәтне күргән юк ие *(аркасыннан кагып)*. Маладис, профессор!

Ш ә м с и *(ошатмыйча)*. Кулыгызны алыгыз... иптәш...

С ә л ә х. Сә...ләх! Әлегә мин ләх түгел. Ыслушай, профессор, мин сине кайдадыр күрдем бугай. Карале, син нәрсә маташтырасың?

Ш ә м с и. Сәхнә. Бүген биредә шушы якларда туып-үскән артистка Халисә Сарманаева концерты булачак.

С ә л ә х. Сәхнә дисеңме... Яшь чакта Шәмси абзагыз да җырчы булган. *(Чишмәдән су эчә.)* Коточкыч шәп ие аның тавышы. *(Җырлап.)*

Җидегән чишмәләрдә...

Ш ә м с и. Хәзер буш шешә кебек шылтырый.

С ә л ә х. Шул мәлгунь харап итмәсә, атказанган әртис буладырыем... Чишмәгә авызны тидергәч, әллә нишләп җырлыйсы килеп китте. Менгез әле мине сәхнәгә. Эт әле арттан.

Ш ә м с и ярдәм итә.

Арттан этүче булмады шул, арттан этүче булмады, без дә бит төшеп калганнардан түгел иек. Без дә җырлый торган иек сөю җырларын! Менә болай кулны күкрәккә куеп, күзне йомып...

Җырларга тырыша.

Яшьлегем чәчәк атканда
Сине сөйдем, гүзәлем.

...Юк, чыкмый. Фермада дуңгыз мыркылдавын тыңлап, үгез артыннан куып узды гомер... Җыр җырланган, маңгай сырланган. *(Сәхнәдән төшә-төшә.)* Иптәш пырафессор, үгезне табалмасам, мине персидәтел нишләтер икән?

Ш ә м с и. Үзеңне көтүгә үгез итеп куяр.

С ә л ә х. Анысы булмас. Болай да хатын «бозау» дип тирги. Әйт, нишләтә?

Ш ә м с и. Кисә.

С ә л ә х. Анысы да булмас. Ярты ел инде акча биргәннәре юк.

Ш ә м с и. Үтермәс әле.

С ә л ә х. Үтерүен үтермәс, үземне дәүләткә тапшырмасын, чукынгыры!

Ш ә м с и. Дәүләтнең төрмәләре шыгрым тулы — урын юк.

С ә л ә х. Вак-төяк белән эләккәннәргә урын таба алар. Ыслушай, пырафессор, фамилияң ничек әле синең? Мин сиңа тагын сугылырмын.

Ш ә м с и. Чаңбаев.

С ә л ә х. Иптәш Чаңбаев! Искә төште! Кайда күрдем дисәм, без синең белән яттык...

Ш ә м с и. Айныткычтамы?

С ә л ә х. Юк. Спецклиникада...

Ш ә м с и. Син анда ничек эләктең?

С ә л ә х. Блат наркомнан да өстен. Шунда санитар булып эшләүче апам салды. Син дә, мин дә яшь ул чакта. Син аерым бүлмәдә берүзең яттың. Икебез дә кабырга белән. Көрәшченең авырткан җирен беләсеңдер: бил, кабырга... Синең кабырганы кемдер сыйпаган һәм дөрес эшләгән дигәннәр ие...

Ш ә м с и. Бар, үгезеңне эзлә!

С ә л ә х. Мирхуҗаны күрсәң, хәбәр ит, иптәш Чаңбаев! Кәкре Елга авылы, «туры юл» күмәк хуҗалыгы, Шәмси батыр... *(Чыга.)*

Ш ә м с и. Мирхуҗаларга сәлам. *(Эшен дәвам итә.)*

Таяк белән кармаланып, сукырайган Т а ң з и ф а керә.

Т а ң з и ф а. Авылдашлар, җаннарым, кем дә булса, мине ишетәсезме?

Шәмси дәшми. Таңзифа чишмә янына килә. Күккә текәлә.

Илаһым, зинһар, ишетә күр минем ялваруымны, кичерә күр кылган гөнаһларымны! Пәйгамбәрләр затыннан булган изге адәмне авыр хәлдә ташлаганым өчен биргән җәзаңны кабул кылдым: күзләрем сукырайды. Илаһым, соңгы гозеремне ишет, ят җирләрдә адашып йөргән Алмасымны кайтар. Шулай ук исәнлек-тәүфыйк бир баламның баласы, йөрәгем пәрәсе Инсафка. Караңгы төннәрдә барасы юлларына таң нурлары сибә күр. Илаһым, мин гаепле синең каршыңда...

Ш ә м с и *(якынрак барып)*. Синең гаебең юк, Таңзифа. Хатаң гына бар.

Т а ң з и ф а. Һай, кеше бар икән. Тавышың таныш кебек. Нидә хаталандым мин?

Ш ә м с и. Сөләйманга кияүгә чыгып ялгыштың.

Т а ң з и ф а. Ялгышымны әйт.

Ш ә м с и. Сөләйман яши белмәде.

Т а ң з и ф а. Аңа ничек яшәргә кирәк иде соң?

Ш ә м с и. Ул тормыш агымына каршы йөзде, яраклаша белмәде. Тормыш ул — сәхнә, кешеләр анда үзләрен түгел, бөтенләй башка кешене уйныйлар. Диваналар гына шәрран яра үзләрен ачалар. Сөләйман уйлаганнарны әллә мин уйламадыммы, әллә мин белмәдемме татар халкының бөек тарихлы икәнен? Нигә кирәк иде Сөләйманга безнең Болгардагы Кара пулатның Кырымдагы Хан төрбәсенә охшашлыгын исбат итәргә? Вакытыннан элек кычкырган әтәчнең муенын боралар.

Т а ң з и ф а. Чаңбаев! Күзләрем сукырайгач кына, бик соң күзләрем ачылды. Менә шулай уйлаучыга кияүгә чыгып, мин ялгышканмын. Мин сине яратмыйча чыктым. Сөләйманны милләтче дип эштән кугач, бик авыр хәлдә калдым шул. Имеш, Алмасымны кеше итәм...

Ш ә м с и. Юлдан язган ул малаеңны искә дә алма. Көтмә син аны, кайтмый ул!

Т а ң з и ф а. Кайтыр, Алла бирсә... Ул сине күрмәс өчен генә кайтмый читтә йөри, бахырым.

Ш ә м с и. Ярар. Минем эшем бар. *(Сәхнәгә менеп эшли башлый.)*

Т а ң з и ф а. Нишлисең анда, исерекләрдән калган шешә җыясыңмы һаман?

Ш ә м с и. Усалланма! Бүген Халисә концерт беләнкилә. Сәхнә ясыйм.

Т а ң з и ф а. И-и, Халисә кызым киләмени? Сагындым үзен. Шигырен, җырын сагындым. Күңел бөтенләй бушап, таштай катып калган чак. Сөләйманны да, ул монда дачада яши башлагач, беренче тапкыр сәхнәдә күргән идем. Тормыш ваклыклары йөрәгемне ураган вакыт иде. Ул югарыда иде, мин менә алмаслык югарылыкта иде. *(Шәмсигә.)* Менәргә ярдәм ит, минем бик аз гына булса да Сөләйман югарылыгына күтәреләсем килә.

Шәмси менәргә ярдәм итә.

Ул сөйләгән шигырьне мин гел күңелемнән сөйләп йөрим.

Гомерем буе тауга, күккә ашып,
Түбән төшә-төшә ялыктым.
Тукталдым да Урал итәгенә,
Йөрәгемә ятып ял иттем.
Ишетелде шулчак серле бер җыр,
Ардым инде, талдым дигәндә:

«Төшсәң дә син Җиргә — бик түбәнгә,
Төшә күрмә Җырда түбәнгә...»
Табигатьне, йөрәгемне айкап,
Яшәртте Җыр Җирне, Күкләрне.
Таулар күкрәгеннән чыккангадыр,
Ул мине дә биек күтәрде.

Шигырь дәвамында Шәмси әкренләп түбәнгә төшә, ауган тирәккә утырып уйга тала.

Сөләйман, син шушында гына ятасың ич. Ишеттеңме? Уян, бәгърем, кичерә күр мине.

Шул сүзләрне кабатлап югарыдан төшә, Шәмсинең биргән кулын алмый.

Кичер мине, Сөләйман... *(Чыга.)*

Шәмси тирән уйда. Шулвакыт Алмасның тән сакчысы Мирхуҗа килеп керә. Ул килбәтсез олы гәүдәле, сакал-мыек үстергән. Күн тужуркадан. Ымлыклар белән генә сөйләшә. Тирә-якны барлап чыга, сәхнә асларын-өсләрен тикшерә, чишмә тирәсен карый. Сәләх бушаткан шешәне алып, иснәп карый да чишмә ташына бәреп вата. Шәмсине күреп, аның янына килә.

Шәмси *(торып, әдәпле генә кулын бирә)*. Чаңбаев!
Мирхуҗа *(кесәләрен капшап)*. Кит!
Шәмси. Аңламыйм.
Мирхуҗа. Ычкын! Сыпыр!
Шәмси. Ни әйтергә телисез?
Мирхуҗа. Сыз!
Шәмси. Әллә үгез киләме?
Мирхуҗа. Шым!
Шәмси. Төшендем. Затлы машина килеп туктаган. Белдем — олы хуҗа килгән. Обкомда бүлек мөдире булып эшләдем. Профессор Чаңбаев!
Мирхуҗа. Тай!
Шәмси. Мин моннан китмим. Минем дачам монда...
Мирхуҗа. Тәгәрә!

Көч кулланып, Шәмсине чыгара. Сәхнә артында тавышлар.

Чиген! Артка! *(Чыга.)*
Халисә тавышы.
Без очрашкан, без аерылган урын —
Елга ярындагы тал-тирәк
«Әллә кайта микән?» дигән кебек,
Җил искәндә куя калтырап.
Әйтә йөрәк: «Алай ашыктырма,
Газаплама, миңа ял кирәк.

Күрәсеңме, сабыр итәлмәгән,
Усал җилдә ауган тал-тирәк...»

Кич. Эңгер-меңгер.

Х а л и с ә *(сәхнәдә)*. Исәнмесез-саумысез, авылдашлар, туганнар, апалар, сеңелләр, абыйлар, энеләр! Иштирәктә һаман клуб булмагач, мин сезне Казансу буена чакырдым инде. Рәхмәт сезгә, килгәнсез. Әйдәгез, бүген барыбызга да кадерле булган Сөләйман абый Уразовны искә алыйк. Искиткеч кеше иде ул. Юкка гына без аны читтән алып кайтып, менә монда — Изгеләр зиратына җирләмәдек. Үзегез дә беләсез, шагыйрь булмаса да, ул җаны белән шагыйрь иде. Аның бер шигырен исегезгә төшерим:

Чит җирләрнең салкын туфрагы да
Якын күрә мине, үз итә.
Синнән башка — туңган күңелемә —
«Көтәм!» дигән тик бер сүз җитә.
Син яшәгән җирнең җылы җилен
Сулышларым белән тартырмын.
Өметеңне өзеп, көтмәсәң дә,
Онытсаң да, барыбер кайтырмын.

Кинәт ут сүнә.

Нишләп ут сүнде?
Кем сүндерде? Борчылмагыз, мин аны ут кабынганчы сөйли торам. *(Соңгы юлны кабатлап әйтә.)*
Онытсаң да барыбер кайтырмын!
А л м а с *(соңгы юл әйтелү белән, караңгыдан)*. Мин кайттым!
Х а л и с ә. Кем ул? Мин берни дә күрмим.
А л м а с. Танымыйсыңмы?
Х а л и с ә. Тавышың таныш кебек...
А л м а с. Иске танышыңны оныттыңмы?
Х а л и с ә. Кем соң син?
А л м а с. Мин сүземдә тордым. Син боздыңмы әллә вәгъдәңне?
Х а л и с ә. Берни аңламыйм.
А л м а с. «Көтәм» дигән сүзеңне кемгә әйттең?
Х а л и с ә. Әллә төш күрәм инде?..
А л м а с. Димәк, «көт, кайтам» диючеләр мин генә түгел?
Х а л и с ә. Нигә соң син күренмисең?
А л м а с. Син дөрес әйтәсең: мин күренми торган адәм идем! Хәзер син мине күрерсең! Барс! Ут!

Машина фарасының уты сәхнәне яктырта. Сәхнәнең бер читендәге кәнәфидә заманча затлы киенгән, сакал-мыек үстергән Алмас утыра. Аннан читтәрәк аның тән сакчысы Мирхуҗа урнашкан.

Халисә, мине әле дә танымыйсыңмы?

Пауза.

Кайчан да кайчан мине эзләүдән туктарлар, кайчан да кайчан мине онытырлар, ул кайтыр... тик...

Халисә. Алмас?!

Алмас. Таныдың тәки? *(Сәхнәгә сикереп менә.)*

Халисә. Үз күзләремә үзем ышанмыйм. Чыннан да синме бу, Алмас?

Алмас. Алмаска охшамаганмыни?

Халисә. Танырлык та түгел. Үзгәргәнсең.

Алмас. Дөнья үзгәртә адәм баласын. Син үзгәрмәгәнсең диярлек. Мине күргәч, нишләптер, куркып калдың. Син шат түгел кебек...

Халисә. Үзем дә белмим. Каушап калдым әле.

Алмас. Әйт, син шатмы, түгелме? Мине онытсаң, дөресен әйт!

Халисә. Онытмадым, Алмас.

Алмас. Ышанмыйм. Нишләп, алай булгач, кочакламыйсың көткәнеңне?

Халисә. Халык алдында... оялмыйча...

Алмас. Халык юк. Бу концертың бары минем өчен!

Халисә. Чыннан да... Ут кабынгач, карасам, ике генә кеше! Кем ул әнә тегесе... әллә нинди адәм?

Алмас. Төкер! Ул кеше түгел. Аны юк дип сана.

Халисә. Ул бездән күзен алмый.

Алмас. Аның һөнәре шул. Минем тән сакчысы. Ә син — минем җан сакчысы бул! Барс, югал!

Мирхуҗа китә.

Халисә. Ә халык кайда?

Алмас. Мин кусам китә, мин чакырсам килә халык. Безнең бәхетле очрашуны карап тормасыннар. Кудым әлегә. Йә, сагындыңмы мине, Халисә?

Халисә. Безне очраштырган әнә теге тирәк сине көтәкөтә түзәлмәде, сынды. Мин саргайдым гына. Ә син үзең?

Алмас. Мин дә сынмадым, Халисә! *(Кочаклашалар.)*

Халисә. Кара, чәчләрең агарган ич... Күзләрең һаман да чем-каралар...

Алмас. Синең күзләреңнең зәңгәр икәнен әле генә күрдем... Яшь чакта күрмәгәнмен.

Халисә. Бабай булгансың.

Алмас. Заманнан артта калып булмый. Акыл үстереп булмагач, сакал үстердем. Ә сакаллы адәмне акыллыга санyйлар. Ни эшләсәң, шул килешә...

Халисә. Өйләнмәгән егеткә... дисеңме. Чынлапмы?

Алмас. Законлы хатыным юк.

Халисә. Законсызлар?

Алмас. Алар белән шаярырга вакытым юк. Мин эш кешесе.

Халисә. Син кем соң? Бик зур түрәме? Тән сакчысы белән генә йөрисең...

Алмас. Мин чын Алмас! Мине беркем бөгә дә, сындыра да алмый. Беркем кимсетә, өркетә, куркыта алмый! Һәм сине дә! Мескенлек, коллык бетте!

Халисә. Сине көтә-көтә картаеп беттем, Алмас.

Алмас. Миңа ошый болай картаюың. Мин Иштирәккә сине яшәртү өчен кайттым, Халисә.

Халисә. Яшәрт инде алай бик теләгәч...

Алмас. Сөеклесен унсигез ел көткән артистка Халисә Сарманаева шушы сәләмә сәхнәдә җырларга тиешме? Барс! Келәм!

Мирхуҗа сәхнәгә затлы келәм җәя.

Барс! Чемодан!

Мирхуҗа чемоданны Алмас алдына куя да, хуҗасы кул селтәгәч, чыга. Алмас чемоданны ача.

Сиңа! Мине көткәнең өчен! Хәзер мин халыкны чакыртырмын! Әтием яраткан җырны җырларсың, аңладыңмы?

Халисә чемоданны алып чыга.

Барс!

Мирхуҗа. Ау!

Алмас. Чакыр халыкны! *(Магнитофоннан музыка җибәрә.)* Халык, җыелдыңмы? Сәлам! Тамак туйдымы? Сыйландыгызмы? Кем куйды сезгә бу затлы тәгамнәрне дисәгез, мин — Уразов булырмын! Бу фамилия таныштыр сезгә. Сездә дача сатып алып яшәгән Сөләйман Уразовны яхшы беләсез дип уйлыйм. Сез минем үземне танымыйсыз, кәнишне. Без үзебез Алмас Уразов, ягъни Сөләйманның улы булабыз. Кайберегез, бәлкем, хәтерли торгандыр, мин әтинең дачасында тордым. Казансуда вактөяк балык тоттым. Аннан, үлгәч кенә булса да, исән чакта кадер күрмәгән атамны хөрмәтләргә кайттым. Анысын үзегез күрерсез ничек икәнне. Атамны Изгеләр зи-

ратына алып кайтып җирләдегез, анысына рәхмәт. Үзегез беләсез, атамны исән чакта типкедә йөрттеләр. Эшеннән кудылар, язган эшләрен басмадылар, милләтче булуда гаепләп... Ул өметен өзеп Йошкар-Олага китте, шунда җан бирде. Мин аның китапларын бастырып, сезгә алып кайттым. Барс! Тарат халыкка! Бушлай! Ә хәзер мин бу сәхнәгә татарның мәшһүр артисткасын — Халисә Сарманаеваны чакырам! Халисә, чык! Күрен!

Музыка, кул чабулар.
Затлы киемнәр кигән, зиннәтле алка-төймәләр таккан Халисә сәхнәгә чыга.

Минем сорау буенча! Атамның яраткан җырын! *(Аска кәнәфигә төшеп утыра.)*

Халисә *(җырлый)*.

Урманнарга кереп кисеп алдым
Дугалыкка диеп төз элмә.
Йөрәккәем бигрәк түзем лә.
Гомер язларында аерылдык,
Очраштык тик гомер көзендә,
Яз да, көз дә чагыла йөземдә.
Әллә хәсрәт, әллә сөенечтән
Ике яшь бөртеге күземдә,
Йөрәккәем, чыда, өзелмә.
Кыңгыраулар булып яшьлек калды,
Чыңлап калды гомерем эзендә.
Йөрәккәем, түз лә, өзелмә...

Кул чабулар.

Алмас. Халисә, нигә әле син бүгенге шатлыклы көндә халыкка хәсрәтеңне ирештерәсең?.. Биеп җибәр әле бер яшь чагыңдагы кебек авылларны селкетеп! Халык! Давай, кул чап!

Кул чабулар.

Халисә. Юк, Алмас, хәзер булдыралмыйм.

Алмас. Мин сорыйм! Музыка!

Бию көе уйнала. Халисә соңгы чиккә җиткәнче бии дә хәле бетеп егыла һәм йөзтүбән капланып елый. Алмас сәхнәгә йөгереп менә, Халисә янына килә.

Халык! Тарал! Барс! Сыйла! Ни булды, Халисә, әллә инде елыйсың? *(Күтәреп торгыза.)*

Халисә. Әллә нишләп... күңелем тулды...

Алмас. Әйдә, төшик моннан, ял ит.

Х а л и с ә. Ә концерт?!

А л м а с. Мин әйттем, концерт тәмам! Иптәшләрең сәхнәгә чыгып тормасыннар. Менә аларның өлешен үзләренә бирерсең. *(Акча төргәген суза.)*

Х а л и с ә. Шулкадәр акча... безнең күргән дә юк...

А л м а с. Минем белән булганда күрерсең. Мин әйткәч, ал!

Х а л и с ә. Рәхмәт.

А л м а с *(аска төшеп)*. Бир кулыңны.

Х а л и с ә. Хәлсезләнеп киттем. *(Төшкәндә туктап.)* Кала бит...

А л м а с. Нәрсә?

Х а л и с ә. Келәм.

А л м а с. Төкер. Миндә ул миллион! Артистларыңа бир. Әйдә, чишмә янына. Су эчеп җибәр.

Х а л и с ә. Рәхмәт, Алмас. *(Башын Алмасның җилкәсенә куя.)*

А л м а с. Тынычландыңмы инде?

Х а л и с ә. Эчкәч хәл кереп китте... Сөләйман абый матурлаган чишмә.

А л м а с. Әти җүләр. Ике айлык хезмәт хакын суга салды.

Х а л и с ә. Гаҗәеп бит. Тыңла әле аның челтерәүләрен... Читтә йөргәндә төшләреңә кергәндер инде, шулаймы?

А л м а с. Анда, Халисә, чишмә турында уйлау түгел, төш күрергә дә вакыт булмады.

Х а л и с ә. Мин сине төшемдә генә яшь итеп күрдем. Берсен сөйлимме? Испаниягә барганбыз, имеш...

А л м а с. Мин чыннан да анда бардым.

Х а л и с ә. Стадионда утырам. Ә син тореодор... Кызыл материя тоткансың да үгезгә каршы барасың. Сине үгез сөзә дигәндә генә, уяндым...

А л м а с. Мин үзем сөзәм хәзер! Беркем каршы тора алмый. *(Кулындагы магнитофонны кабыза, аннан Халисәнең җыры ишетелә.)*

Әллә хәсрәт, әллә сөенечтән —
Яшь бөртеге ике күземдә,
Йөрәккәем, чыда, өзелмә.

Х а л и с ә. Кара, язып та алгансың.

А л м а с. Кассета ясатып, дөньяга таратам әле мин синең тавышыңны!

Х а л и с ә. Алмас, чынлапмы?

А л м а с. Син әле һаман җырлап кына йөрисеңме?

Х а л и с ә. Ярты гомерем сәхнәдә узды.

Алмас. Тамак туйдырырлык сәмән бирәләрме соң? Ничә лимон?

Халисә. Төрле чак була инде. Чәйне лимонсыз гына да эчәргә туры килә.

Алмас. Моннан соң Халисә Сарманаеваны дөньяның төрле почмакларында ишетерләр. Кассета саткан табышның яртысы — үзеңә! Доллар белән!

Халисә. Шаяртма.

Алмас. Шаярмыйм. Дөньяның күп кенә нокталары минем кулда.

Халисә. Яшь чагыңа охшап калдың. Мактанырга ярата идең.

Алмас. Мин башка Алмас хәзер. *(Кесә телефонын ала.)*

Халисә. Нәрсә бу?

Алмас. «Эрикссон». Дөньяны кулда тота торган аппарат.

Халисә. Яшь чакта алдауларыңа рәхәтләнеп ышана идем...

Алмас *(номер җыеп)*. Истамбулмы? Әссәламәгаләйкем, Нурхан бәй. Минем товар үтәме? Эшләр майлаган кебек бара?! Хуп! Афәрин! *(Тагын номер җыя.)* Хельсинки?! Кадыйр әфәнде, сезме, йөрәк маем? Миңа нинди сорауларың бар? Анысын миннән сорап та торма, үзең хәл ит! Мин сиңа ышанам. Миннән фатыйха. Хуш, канәтем.

Халисә. Хәзер инде ышандым.

Кайдадыр шартлау.

Алмас *(сикереп тора. Ул үзен гел киеренке тота, сөйләшкәндә вакыт-вакыт тирә-ягына карап ала)*. Барс!

Мирхуҗа керә.

Мирхуҗа. Ау.

Алмас. Нинди шартлау? Тикшер!

Мирхуҗа. Момент! *(Чыга.)*

Халисә. Синең җаның тыныч түгел...

Алмас. Арылды.

Халисә. Әйт инде, Алмас, син кем соң?

Алмас. Үзебезчә әйткәндә, бай абзый! Яңа татар. Өряңа! Кайберәүләр малтабар дип тә җибәрәләр. Ягъни дә мәсәлән, мал артыннан чабучылар.

Халисә. Шулай бик баймы син?

Алмас. Бай, бик бай, Халисә! Син миннән ни телисең, шуны сорый аласың. *(Шәмси салган йортны карап.)* Бу нинди йорт?

Халисә. Буш шешәләрдән салынган.
Алмас. Шәп товар. Хуҗасы кем?
Халисә. Чаңбаев.
Алмас. Шул мин кабыргасын сыйпаган Чаңбаевмы?
Халисә. Шул.
Алмас. Ул әле исәнмени?
Халисә. Исән.
Алмас. Кеше гомерен кыскартучылар озак яшиләр. Үзе шунда яшиме?
Халисә. Дача йортында тора. Монысы — сату өчен.
Алмас. Әтинең үлеменә сәбәпче адәмнәрнең берсе.
Халисә. Алай ук түгел инде. Яши белеп яшәүче.
Алмас. Иң авыр чакта әтине якламады. Обкомда эшләвеннән файдаланып, әни дигән кешене үзенә алды.
Халисә. Алмас, нигә әни исәнме дип сорамыйсың?
Алмас. Аның исән булуы-булмавы мине кызыксындырмый. Әтигә хыянәтен мәңге кичермәм.
Халисә. Ул исән. Күзләре сукырайды.
Алмас. Шуннан? Һи. Мине менә бу сарай һәм аның хуҗасы кызыксындыра.
Халисә. Әнә үзе дә шунда йөри.

Шәмси күренә. Балта белән нәрсәгәдер суга. Алмас сискәнеп, сикереп тора.

Алмас. Барс!

Мирхуҗа керә.

Мирхуҗа. Ау! *(Шәмсигә таба бара.)*
Халисә. Зинһар, тимәгез аңа! Ул карт инде. Алмас, тынычлан...
Алмас. Барс! Кире борыл!

Мирхуҗа китә.

Әй, син, монда кил әле!
Халисә. Алмас, бәйләнә күрмә.
Алмас. Мин аңа тырнак белән дә кагылмам.
Халисә. Үзе бәйләнсә...
Алмас. Соңга калды... Хуҗа, кил минем янга!
Халисә. Бу киемнәрдән күренергә уңайсыз... *(Бер читкә китә.)*

Шәмси керә.

Шәмси. Хәерле көннәр, Алмас Сөләйманович!
Алмас. Сәлам, Чаңбаев! Кил, якынрак кил.

Ш ә м с и. Әлегә колакларым әйбәт ишетә, Аллага шөкер.

А л м а с. Аллага ышанасыңмыни?

Ш ә м с и. Мин элек тә күңелемнән ышана идем.

А л м а с. Ялгышмасам, син коточкыч атеист идең?

Ш ә м с и. Заманы шундый иде. Сезнең кебек игелекле бер бизнесмен Иштирәккә мәчет салып куйды. Шунда йөрим. Әмма халык бизгән, килүчеләр бер-ике генә.

А л м а с. Мактыйм. Заман белән бергә атлыйсың. Кабыргаларыңның җидесе дә исән-саулармы?

Ш ә м с и. Әй, искә төшермик инде, онытыйк...

А л м а с. Бу сарайны үзең эчкән шешәләрдән кордыңмы?

Ш ә м с и. Алла сакласын... Яшь чакта бераз капкаладым. Карт кешегә — гөнаһ.

А л м а с. Минем янга якынрак кил, Чаңбаев. Нигә куркасың? Син элекке Чаңбаев булсаң да, мин элекке Алмас түгел. Син аласыңны алдың.

Ш ә м с и. Тән ярасы онытыла, Алмас Сөләйманович.

А л м а с. Тел яраларын мин онытмыйм, тик мин үч алырга кайтмадым. Бу өеңне сатасыңмы?

Ш ә м с и. Сезнең кебек хөрмәтле кешеләр белән килешергә булыр дип уйлыйм.

А л м а с. Мин аны алам! Барс! Чемодан!

М и р х у җ а дипломат алып керә.

Ш ә м с и. Күпме?

А л м а с. Йөз мең.

Ш ә м с и. Йөз меңнәрне?

А л м а с. Азсынасыңмы?

Ш ә м с и. Мин алай ук сорарга батырчылык итмәс идем.

А л м а с. Мин бит беләм, сезгә, галимнәргә меңнәрне төштә генә күрергә туры килә.

Ш ә м с и. Минем хәл ярыйсы әле. Кайбер коллегаларым тамак ялына чит илгә китте. Урам себерүче булып эшләүчеләр дә бар, Алла сакласын!

А л м а с. Сине Алла саклар. Урам себерүче булмассың... Ал!

Ш ә м с и *(шикләнебрәк)*. Шаяртмыйсыңмы? Чынлапмы?

А л м а с. Яңа гына станоктан чыгып банкка кергән, буявы да кипмәгән. Барс! Оформить итсеннәр! Барыгыз! Тукта!

Ш ә м с и. Тыңлыйм, әфәндем.

Алмас. Син пенсиядәме?

Шәмси. Профессор буларак ипи-тозлык бирәләр.

Алмас. Мескен профессорлар, гомерегезне укып, интегеп әрәм иткәнсез. Заман башка. Дөньяның тоткасы — акча, чамаладыңмы? Кемнең арты тегермән тарта ди әле татар?

Шәмси. Көчленеке. Кызганыч, әмма факт.

Алмас. Шушы миңа саткан өйнең каравылчысы булырсың. Хезмәтең өчен түләрмен.

Шәмси. Риза!

Алмас. Сыпыр!

Шәмси белән Мирхуҗа чыгалар.

Халисә, кил!

Халисә. Сугышып китмәсеннәр дип котым очып торды.

Алмас. Хәзер ул минем кулда. Мин ни телим, шуны эшлим. Халисә, бу сарай — синеке!

Халисә. Кит аннан, мин анда нишлим?!

Алмас. Безнеке! Ял итә торган резиденция! Барс!

Мирхуҗа пәйда була.

«Тойота»ны әзерлә! Югал!

Теге китә.

Халисә, җаның кая тели — шунда алып барам! Әйт, кая китәбез?

Халисә. Иң башлап әниеңнең хәлен белик. Борчылам. Концертта да күренмәде.

Алмас. Юк, аңа — беркайчан да!

Халисә. Алмас...

Алмас. Исемен телгә алма.

Халисә. Хәзер Изгеләр зиратына, Сөләйман абыйга керик.

Алмас. Төп максатымның берсе — шул. Мин аның исемен мәңгеләштерергә кайттым. Башта Казансу буйларын әйләник. Тагын кемнәрне күрергә?

Халисә. Балаңны.

Алмас. Тагын бер кабатла әле...

Халисә. Балаңны.

Алмас. Нинди бала?

Халисә. Үзеңнең балаң.

Алмас. Минем балам? Ничек инде?

Халисә. Икебезнең балабыз.

А л м а с. Халисә, шаярма.
Х а л и с ә. Бала белән шаярмыйлар.
А л м а с. Валлаһи, диң.
Х а л и с ә. Үзең дә ышанырсың.
А л м а с. Исеме ничек?
Х а л и с ә. Инсаф.
А л м а с. Фамилиясе?
Х а л и с ә. Әлбәттә, Уразов.
А л м а с. Кемгә охшаган?
Х а л и с ә. Нәкъ Сөләйман абый инде.
А л м а с. Кызмы?
Х а л и с ә. Малай.
А л м а с. Малай?!
Х а л и с ә. Ир бала.
А л м а с. Аңа ничә яшь?
Х а л и с ә. Унсигез.

А л м а с. Халисә, ни җаның белән шуны әйтми торасың? Минем унсигез яшьлек малаем бар! Уразовларның нәселе корымаган? *(Кесә телефонын ала.)* Егетләр! Ура! Мине монда малаем көтеп торган. Котлагыз! Мичкәләрне тәгәрәтә башлагыз! Пир на весь мир! Миннән — йөз кешелек банкет! Сәлам! Рәхмәт! Халисә, ник син моны очрашкач та әйтмәдең?

Х а л и с ә. Курыктым.
А л м а с. Нидән? Баладан баш тартыр дип уйладыңмы?
Х а л и с ә. Андый уй да булгандыр. Мин бит әле сине белмим.

Шартлау. Алмас сискәнеп сикереп тора.
М и р х у җ а керә.

А л м а с. Барс! Кем атты?
М и р х у җ а. Мин. Котырган эт ташланды.
А л м а с. Пистолетка тотынма дип әйттемме сиңа! Бар!

Теге чыга.

Их, Халисә, син мине бәхетле иттең. Чыннан да, баш тартыр дип уйладыңмы?
Х а л и с ә. Хәзер тынычландым инде.
А л м а с. Барс, өстәл! Аля-фуршет!

Мирхуҗа тәгәрәтеп өстәл кертә. Шәраб сала.

Балабыз хөрмәтенә! Яшәсен Уразовлар һәм дә... Халисә Уразова! Инде, Халисә-җан, туп-туры Инсаф янына китәбез! Танышсын үз әтисе белән. Үзен ятим итеп тоймасын!

Х а л и с ә. Алмас, ул юк...

А л м а с. Ничек... юк?

Х а л и с ә. Әлегә Инсафның рәсемен генә күрә аласың. Менә... *(Фоторәсем ала.)* Менә...

А л м а с *(карап)*. Минем балам... Инсаф... Әллә... Үлдеме?

Х а л и с ә. Исән... исән...

А л м а с. Кайда ул?

Х а л и с ә. Аны армиягә алып киттеләр.

А л м а с. Кайчан?

Х а л и с ә. Ике ай элек.

А л м а с. Их, Халисә...

Х а л и с ә. Ул киткәннән бирле йокы күргәнем юк.

А л м а с. Хаты килдеме?

Х а л и с ә. Килде шул...

А л м а с. Нигә «шул»?

Х а л и с ә. Соңгы хатында «безне Чечняга җибәрәләр» дип язган.

А л м а с. Анда бит сугыш...

Х а л и с ә. Хәбәрләр тыңлаган саен тетрәнәм. Харап кына итмәсәләр ярый инде балакайны?!

А л м а с. Ярый, артык борчылма. Мин егетләргә хәбәр бирермен. Коткарырбыз.

Х а л и с ә. Коткара күр, Алмас.

А л м а с. Мин бик вакытында кайтканмын.

Х а л и с ә. Унсигез елдан соң...

А л м а с. Әле соң түгел. Туй ясыйбызмы?

Х а л и с ә. Картаеп беткәчме?

А л м а с. Без әле яши генә башлыйбыз, Халисә. Кайда яшисең килә?

Х а л и с ә. Инсаф кайтмыйча хәл итә алмыйм.

А л м а с. Өчәүләп хәл итәрбез. Инсафның соңгы адресы бармы?

Х а л и с ә. Бар. Үзем белән. *(Бирә.)* Менә. Укы.

А л м а с. Борчылма. Эзенә төшәрбез. Дөнья Алмаслар кулында! *(Телефоннан номер җыя.)* Серега, сәлам! Синең ярдәмең кирәк. Минем малайны коткарырга кирәк. Ут эченә җибәрәләр. Уразов Инсаф. Адресы: хәрби часть...

Шул вакыт үгез үкергән тавыш ишетелә.

*(Сискәнеп.)* Нәрсә бу?

Х а л и с ә. Үгез! Кызыл үгез!

А л м а с. Үкереп безнең өскә килә! Якыная...

Х а л и с ә. Ой! Мин куркам, нишлибез, Алмас?

А л м а с. Мин барында курыкма, Халисә... *(Пистолетын чыгара.)*

Сәләх *(йөгереп керә)*. Тотарга ярдәм итегез! Безнең качкан үгез ул! *(Алмас янына килә, атарга җыенганын күреп, пистолетына ябыша.)* Зинһар, атма! Дәүләткә тереләй тапшырасы үгез. Атма! Ату минем үземне пычаксыз суеп, җиде кат тиремне тунарлар!

Алмас. Халисә, әйдә машинага! Барс! «Тойота»!

Ашыгып чыгалар.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук декорация. Июль ае. Шул ук көнне. Кич. Чишмә буе электр белән яктыртылган. Тирә-ягына карана-карана, кача-поса Инсаф керә. Кеше юклыкны шәйләп, чишмә янына килә. Йотлыгып су эчә, битләрен чылата. Котелогына су ала. Кемдер килгәнне күреп, ауган тирәк артына кача. Айгөл керә.

Айгөл *(алдындагы сәхнәне күреп)*. Ой, сәхнә! Мөгаен, Халисә апа килгәндер! Казанда йөреп мин соңга калганмын. Әллә килеп җитмәде микән әле? Сәхнә! Хыялым минем! Менә мин, каушый-каушый, дулкынлана-дулкынлана, сәхнәгә күтәреләм. *(Әкрен генә сәхнәгә күтәрелә.)* Тамашачылар мине көтәләр, кул чабып каршылыйлар. Мин сәхнә уртасына басам да хөрмәт белән башымны иям. Кайсысы үтемлерәк булыр икән дип, сөйлисе шигырьләремне күңелемнән барлап чыгам. Менә монысын, Сөләймән Уразовныкын...

«Сөясеңме мине?» дип сорыйсың.
Андый төче сүзләр, юк, әйтмәм.
Күзләреңә сүзсез карауларның
Хатирәсен мәңге югалтмам.
Матур сүзләр очып югалалар
Усал җилләрендә язмышның.
Сине генә өзелеп сөюемне
Әйтми калдым, бик тә ялгыштым.
Син йөрисең кайсы тарафларда,
Нинди хәбәр килер ул яктан?
Гомерем буе эзләп таптым сине,
Юк, югалтмам сине, югалтмам!

Инсаф *(тирәк артыннан)*. Айгөл!

Айгөл. Ой! Кем дәшә миңа?

Инсаф. Монда кил.

Айгөл. Син кем?

Инсаф. Танырсың...

Айгөл. Белмәгән кеше янына бармыйм мин.

Инсаф. Күп сөйләшмә, тизрәк кил!

Айгөл. Кем икәнеңне әйтсәң, барам... *(Сәхнәдән төшеп, Инсафка таба бара, аны күреп туктап кала.)*

Инсаф. Миннән курыкма, Айгөл.

Айгөл. Инсаф?! Синме бу?!

Инсаф. Әйе. Мин.

Айгөл. Сәләмә киемнәр. Тавышың карлыккан. Ябыккансың.

Инсаф. Әйе, мине тудырган анам да танымас иде.

Айгөл. Үз күземә үзем ышанмыйм. Инсаф, ни булды?

Инсаф. Шулай... язмыш җилләре какты.

Айгөл. Син бит армиядә... солдат...

Инсаф. Мин хәзер солдат түгел.

Айгөл. Котлыйм, Инсаф! Ура! Сине кайтардылар?

Инсаф. Тс-с-с... шаулама...

Айгөл. Хәзер үк документларыңны үзең теләгән тарих факультетына илтеп бирәбез. Бик вакытлы кайткансың.

Инсаф. Бу — мөмкин түгел...

Айгөл. Сине ялга гына кайтардылармы? Ничә көнгә?

Инсаф. Юк. Мин ялга кайтмадым.

Айгөл. Әллә авырып киттеңме? Дәваланырга кайттыңмы?

Инсаф. Дөресен әйткәндә...

Айгөл. Дөресен әйт...

Инсаф. Мин — дезертир.

Айгөл. Шаярма, Инсаф.

Инсаф. Мин армиядән качтым.

Айгөл. Качтың? *(Утыра.)* Качтың?! Ышанмыйм...

Инсаф. Ышанма. Әмма бу факт.

Айгөл. Ничек качтың?

Инсаф. Мин хезмәт иткән частьны Чечняга илтеп тыктылар. Бер мишеньгә атарга боердылар. Аттым. Янына барсам, аккош кебек ак күлмәкле чечен кызы кан эчендә ята. Күз алдымда кан, кан... Гаепсез, гөнаһсыз кеше каны... Мин моңа түзмәдем, качтым...

Айгөл. Сиңа... нәрсә булыр?

Инсаф. Трибунал.

Айгөл. Сине эзлиләрме?

Инсаф. Эзлиләр.

Айгөл. Нигә монда кайттың соң?

Инсаф. Бабам белән киңәшергә.

Айгөл. Зираттагы бабаң беләнме?

Инсаф. Ни генә кылсам да, мин аның белән киңәшәм. Минем урында ул нишләр иде микән дип уйлыйм.

Айгөл. Бу юлы ул сине хупламастыр.

Инсаф. Тыныч халыкны аткан, кырган өчен, «дөрес эшлисең, Инсаф!» дип әйтер идеме? Юк!

Айгөл. Син бит... хәрби антыңны бозгансың...

Инсаф. Мин аны үзем дә беләм! Кит! Юкны сөйләмә! Син дә мине аңламагач... *(Кузгала.)* Мондый черек армиянең уставын мин танымыйм!

Айгөл. Инсаф, тукта, ачуланма... Аптыраганнан әйтүем.

Инсаф. Әнием, әбием исән-саулармы?

Айгөл. Исәннәр. Аларга хәбәр итимме?

Инсаф. Нинди хәбәр... Бу аларга сөенеч түгел. Беркемгә бер сүз әйтмисең.

Айгөл. Хәзер нишлибез, Инсаф?

Инсаф. Үзем дә белмим. Беркемгә күренмәскә...

Айгөл. Син болай да адәмгә күренерлек түгел. Инде караңгы. Халык печән әзерли. Монда килүче булмас. Син ачтыр бит. Ашарга алып килимме?

Инсаф. Үзеңнең хәлләр ничек, Айгөл?

Айгөл. Әле генә Казаннан кайттым. Театр училищесына керергә йөрим. Августта имтиханнар. Шигырьне укыганымны тыңладың әллә? Шуны әзерлим. Ә син?

Инсаф. Миндә университет кайгысы юк. Мин зиратка керәм, Айгөл...

Айгөл. Кермә анда, керә күрмә. Анда... куркыныч...

Инсаф. Миңа тере адәмнәр куркынычрак. Анда тыптын. Анда мине аңлый торган затлар ята...

Айгөл. Анда сине эзләмәсләр дә... Аңладым. Ашарга нәрсә алып килим, Инсаф?

Инсаф. Бер бөтен ипи, чишмәдә су бар. Башка берни дә кирәкми... Мин сине шушында көтәрмен.

Айгөл. Сак бул, Инсаф.

Инсаф. Кара аны, аны-моны сиздерә күрмә...

Айгөл. Борчылма, Инсаф.

Инсаф. Кәккүк булып миңа бер тапкыр кычкырырсың.

Айгөл. Ярар. Көт. *(Кәккүк булып кычкыра.)*

Инсаф *(җавап бирә)*. Мин сине күрергә дә кайттым, Айгөл... *(Зират ягына китә.)*

Айгөл. Мин хәзер киләм! *(Чыга.)*

Алмас белән Халисә керә. Халисә джинсыдан.

Алмас. Йә, Халисә-җан, икәү генә «тойота»да гулять итү ошадымы?

Халисә. Рәхәтлек диңгезендә йөздеммени... Алмас, әйдә, утырыйк әле. *(Тирәккә утыра.)* Мин бик арыдым, Алмас.

А л м а с. Мине көтепме?

Х а л и с ә. Сине көтеп тә... Артист тормышын син әле белеп бетермисең...

А л м а с. Чәбәкәй итүгә алданып йөрисез инде.

Х а л и с ә. Төрле чаклар була. Күчмә тормышның авырлыклары күп инде аның. Ягылмаган клублар. Буранлы-яңгырлы көннәр-төннәр, ачлы-туклы яшәү дигәндәй. Ашказаны бозылып бетте...

А л м а с. Авыр яшәвең йөзеңә чыккан, Халисә.

Х а л и с ә. Үзем дә сизәм. Ялгыз хатын — ятим бала белән бер.

А л м а с. Ял итәргә вакыт, Халисә. Яшәртәм мин сине, үзем белән ял итәргә Анталиягә алып китәм! Сине Урта диңгезнең иркә җиле, кайнар комы, җылы дулкыны көтә. Үзем дә синең кебек сөйләшә башладым бугай.

Х а л и с ә. Чынлапмы, Алмас? Ә Инсаф?.. Аның язмышын хәл итмичә торып, нинди ял турында сөйләргә була?!

А л м а с. Борчылма. Тиздән ул безнең янда булыр. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә соңгы чиккә җитеп арыдым. *(Халисә янына утыра.)* Яраткан кешеңнән бер иркәләнәсе килгән минутлар да була. Ә вакыт юк, вакыт!

Шартлаган тавыш. Алмас сикереп тора да кире утыра.

Х а л и с ә. Синең дә нервыларың какшаган, Алмас. Бездә монда карьерда таш чыгаралар.

А л м а с. Син минем бердәнбер якын кешем, Халисә. Сиңа кайбер серләрне дә ачарга була.

Х а л и с ә. Сереңне эчеңдә саклама. Ач. Үзеңә җиңеллек килер.

А л м а с. Мин мишеньдәге нокта, Халисә.

Х а л и с ә. Аңламыйм.

А л м а с. Миңа мылтык көпшәсе төбәлгән.

Х а л и с ә. Ничек... төбәлгән?

А л м а с. Мине һәр минутны атып үтерүләре мөмкин.

Х а л и с ә *(торып)*. Юк, бу — мөмкин түгел. Кемнәр, ни өчен?

А л м а с. Киллер дип аталган төз атучы җәлладларым мине адым саен эзәрлеклиләр. Мин шуны аркам белән гел тоеп торам.

Х а л и с ә. Синдәге сәер ул халәтне сизгән идем шул.

А л м а с. Минем фирма мәрмәр ташлар белән дә эш итә, читтән кайтартам. Мин сиңа каберләр өстендә калкып чыккан һәйкәлташлар урманын күрсәтер идем. Утызкырык яшьлек әзмәвердәй ир-егетләр ята ул таш асларында. Минем дусларым да, дошманнарым да.

Х а л и с ә. Мин синең өчен куркам, Алмас...

А л м а с. Һәркемнән шикләнәм хәзер. Хәтта үземнең Барстан да.

Х а л и с ә. Аның күзләре чыннан да мылтык көпшәсе кебек... Атарга тора...

А л м а с. Минем чын дошманнарым болай да муеннан. Бугазларына аркылы сөяк булып яттым. Тыңла, бердәнбер көнне чын ату тавышы ишетелсә, ул мин — Алмас Уразов булырмын. Киллер бер эләктерсә, минем малларым гына торып калачак бу дөньяда...

Х а л и с ә. Ул турыда сөйләргә ашыкма, Алмас.

А л м а с. Тыңла, әле әйтеп бетермәдем. Гомер буе җыйган байлыгыма кем хуҗа булачак?

Х а л и с ә. Әйтә алмыйм.

А л м а с. Уразовлар нәселен кем дәвам итәр? Ни өчен мине кайткан дисең? Ул-бу була калса, мирасымны Инсафка... Һәм сиңа калдырырга. Кәртләрне ачып бетерим. Мин сине дә, Инсафны да бәхетле итәргә кайттым, Халисә-җан. Төенчекләреңне төйнә. Алай дисәң, әртиснең нинди төенчеге булсын... Мин сине үзем белән алып китәм. Хәерче тормышың белән бәхилләш.

Х а л и с ә. Ә Инсаф?

А л м а с. Мин әйттем: Инсафны без ял иткән Анталиягә, беренче разрядлы кунакханәгә китерерләр.

Х а л и с ә. Алла бирсә диген.

А л м а с. Доллар, доллар барысына да хуҗа! Ә ул миндә, Аллага шөкер! Исән чакта яшәп калыйк дөньяның артына тибеп! Атам миңа Болгар ханының исемен биреп ялгышмаган. Хөрмәтнең иң олысы аңа! Хәзер мин максатымның икенче өлешенә күчәм: атам алдындагы бурычны үтим. Һәйкәлне күрдеңме?

Х а л и с ә. Күрдем. Бигрәк тә биек, затлы инде!

А л м а с. Әллә каян күренеп торсын! «Алмас Уразов куйган!» дисеннәр.

Х а л и с ә. Сөләйман абый аңа лаек инде.

А л м а с. Ә теге хәерчеләр куйган ташны алып ыргытабыз!

Х а л и с ә. Һәйкәл бик кыйммәткә төшкәндер.

А л м а с. Уразовлар нәселе турында сүз барганда — вакланмыйбыз. Мәрмәр үзебезнең кулда. Иң шәбен шәхсән үзем сайладым.

Х а л и с ә. Аны ничек кертерсез икән зиратка?

А л м а с. Бәләкәй ташны алып ташларга кереп китteләр инде. Иштирәкнең алкашларын ялладым. Һәйкәлне куябыз да, Төркия оҗмахына очабыз!

Х а л и с ә. Туктале, ә мин ничек итеп эшемне калдырып китим?
А л м а с. Сәхнәне димәкче буласыңмы?
Х а л и с ә. Ул — минем гомерлек юанычым.
А л м а с. Моннан соң дуңгыз фермасына охшаган салкын клубларда чит-ятларны түгел, ә бәлки, затлы рестораннарда, диңгезнең кайнар комнарында мине юатырсың, үзең дә юанырсың. Үзең үк күреп торасың, заман алышынды! Сәхнәдә — без — мал табучылар! Йә, киттек! *(Телефонга.)* Һалло! Уразовтан сәлам!! Анталиягә — өч урын! Аерым бүлмәләр! Үзем барам!
Х а л и с ә. Ашыкма. Нигә өч?
А л м а с. Инсафны шунда китерерләр. Йә, ризамы?
Х а л и с ә. Риза.
А л м а с. Бәхилләш сәхнәң белән.
Х а л и с ә. Сәхнә белән бәхилләшергә? Юк, Алмас...
А л м а с. Балабыз Инсафның бәхетле булуын теләмисеңмени?
Х а л и с ә. Инсаф өчен мин үземне дә корбан итәргә әзер.
А л м а с. Икенең берсе: йә сәхнә, йә бала! Бар, соңгы тапкыр сәхнәңә менеп төш.
Х а л и с ә *(әкрен генә сәхнәгә мендә)*. Сөләйман абыйның да тормышында шундый чагы булгандыр инде... *(Аның шигырен сөйли.)*

Канатларым кинәт хәлсезләнде,
Мин очалмый торган кош инде.
Әкрен-әкрен генә Күктән төшәм...
Җырлы иткән Күгем, хуш инде.
Үз балаңны Күктә күрү өчен
Җаның белән кирәк түләргә.
Бигрәк авыр, бигрәк авыр икән
Зәңгәр Күктән төшү түбәнгә.

*(Теләмичә генә сәхнәдән төшә. Алмас аңа төшәргә ярдәм итә.)*
А л м а с. Бар, өең белән дә хушлаш инде.
Х а л и с ә. Миңа хуҗама чылтыратырга, мондагы иптәшләрем белән дә хушлашырга кирәк.

Прожектор нуры Изгеләр зираты ягын яктырта.

А л м а с. Барс!

М и р х у җ а зираттан килеп чыга.

М и р х у җ а. Ау!

Алмас. Нигә озакладыгыз? Нигә ташны алып чыкмыйсыз?
Мирхуҗа. Бирми.
Алмас. Нәрсәне?
Мирхуҗа. Ташны.
Алмас. Кем?
Мирхуҗа. Бер селәгәй.
Алмас. Кем?
Мирхуҗа. Бер малай ташны бирми.
Алмас. Алып ыргыт!
Мирхуҗа. Булмый!
Алмас. Син? Мирхуҗа!
Мирхуҗа. Тешли. Менә... бармак...
Алмас. Яле аны монда!
Мирхуҗа. Килми.
Алмас. Син тимә. Яхшылык белән...
Мирхуҗа. Момент!

Алмас магнитофонны кабыза, аннан Халисәнең тасмага язылган шигыре ишетелә.

Үз баланңны Күктә күрү өчен
Җаның белән кирәк түләргә...

Мирхуҗа Инсафны алып чыга.

Инсаф. Тотма! Мин үзем барам.
Мирхуҗа. Шушы! *(Инсаф белән Алмас арасына баса.)*
Алмас. Төнлә... зиратта нишлисең?
Инсаф. Изгеләрнең рухын саклыйм.
Алмас. Син үзеңне дә изге саныйсыңмы?
Инсаф. Юк. Кызганыч, изгеләр көннән-көн азая бара. Исән чакта аларга көн күрсәтмиләр.
Алмас. Бу фикереңң белән килешәм. Мин изге кешенең үлгәч кадерен белергә кайттым.
Инсаф. Соңга калдың.
Алмас. Нигә алай уйлыйсың?
Инсаф. Үлгәч аның кадерен белделәр инде.
Алмас. Ничек?
Инсаф. Исемен, үзе кабатларга яраткан сүзләрен язып таш куйдылар.
Алмас. Ул изге адәмнең исеме ничек?
Инсаф. Ул пәйгамбәр затыннан.
Алмас. Кем ул?
Инсаф. Сөләйман.
Алмас. Мин ныклап карамадым. Ташка нинди сүзләр язылган?

Инсаф. «Эзләдем. Таптым. Югалттым.»

Алмас. Ни әйтергә теләде икән ул?

Инсаф. Мин үзем дә гомерем буе бу сүзләрнең мәгънәсен эзлим.

Алмас. Акыл иясе булса да, аның яшәве яшәү булмады. Шулай да ул татарның бөек кешесе. Үзенә адәм рәтле таш та куя алмаганнар. Мин ул бәләкәй ташны алып ташлыйм. Үзенә лаек затлы һәйкәл куям. Аңладыңмы?

Инсаф. Мин рөхсәт итмим.

Алмас. Син... кем?

Инсаф. Кем булсам да, сиңа барыбер.

Алмас. Минем кем икәнемне чамалыйсыңмы, малай?

Инсаф. Синең кем булуың мине кызыксындырмый.

Алмас. Кит юлдан.

Инсаф. Китмим.

Алмас. Яхшылап әйтәм, кит!

Мирхуҗа. Ыргытам!

Алмас. Сабыр. Көч кулланмыйча хәл итәргә тырышыйк.

Шәмси күренә. Эшләпәсен салып, башын ия.

Шәмси. Нигә йокы алмый дисәм, сез икән әле монда...

Алмас. Уразовка мин куясы һәйкәлне күрдеңме?

Шәмси. Искиткеч. Гениально! Мондый һәйкәлнең татар тарихында булганы юк! Бер чакрымнан балкып торыр! Үрелеп караган идем, эшләпәм шуып төште.

Алмас. Бу малайны таныйсыңмы?

Шәмси *(текәлеп карый, танымый)*. Юк, күргәнем юк... Ниндидер сукбай... бомж...

Алмас. Ул безне зиратка үткәрми. Син әйтеп карале...

Шәмси. Әй, малай актыгы, бу абзаңның кем икәнен беләсеңме?

Инсаф. Белергә дә теләмим.

Шәмси. Нигә син аларны үткәрмисең? Синең ни хакың бар?

Инсаф. Андый һәйкәл Сөләйман Уразовның рухына ят. Иштирәк халкы аңа башка изгеләрдән аерылып тормаган таш куйды.

Шәмси. Ялгышасың. Хуҗа дөрес әйтә. Сөләйман әнә шундый затлы һәйкәлгә лаек! Син аңла: заман үзгәрде, заман — көчленеке!

Инсаф. Лаек булгач, син нигә исән чагында аның

кадерен белмәдең? Нигә якламадың авыр чакларында? Ул заманда көч синдә иде бит!

Алмас. Мин бу сүзләрең белән килешәм. Шуның өчен ул үзе заманында бер кабыргасы белән түләде.

Шәмси. Әй-й... Искә төшермик... онытыйк узганнарны.

Алмас. Малай, безгә каршы торсаң, син дә берничә кабыргаңнан колак кагуың бар.

Шәмси куркып чыгып китә.

Соңгы тапкыр әйтәм: кит юлдан!

Инсаф. Сез монда бары тик минем гәүдәм аркылы гына үтә аласыз.

Алмас. Барс!

Әмер генә көтеп торган Мирхуҗа Инсафка ташлана, нокаут белән Инсафны ега.

Инсаф. Кабахәтләр!

Шул вакыт кулына чемодан тотып Халисә килеп керә.

Халисә *(улының тавышын танып)*. Туктагыз! Кемне кыйныйсыз? *(Инсаф янына бара.)* Инсаф?! Синме бу? *(Инсафны күтәрергә тырыша.)* Балам...

Алмас. Барс, кит...

Мирхуҗа китә. Алмас Инсаф янына бара.

Балам дисеңме? Инсаф?..

Инсафны күтәреп торгызырга ярдәм итә.

Халисә. Чынлап та Инсафмы син? Бер генә сүз әйт... Нишләттеләр сине?

Алмас. Ул үзе гаепле, каршы торды, атам янына кертмәде...

Халисә. Балам, хәлең ничек?

Инсаф. Борчылма, әни, хәлем әйбәт.

Халисә. Танырлык та түгелсең. Сакал-мыек баскан үзеңне... иске-москы киемнәр... Ни булды сиңа?

Инсаф. Берни дә булмады. Тынычлан.

Халисә. Син армиядән котылып кайттыңмы?

Инсаф. Котылдым, әни.

Халисә. Бөтенләйгәме?

Инсаф. Бөтенләйгә.

Халисә. Сине җибәрделәрме?

Инсаф. Әйе, әни.

Х а л и с ә. Авырыпмы?
И н с а ф. Әйе. Әз генә авырдым.
Х а л и с ә. Инде беркая да китмисеңме?
И н с а ф. Китмим инде, китмим.
А л м а с. Халисә, Инсафка минем кем икәнне әйт...
Х а л и с ә. Инсаф, таныш бул! Бу — синең әтиең...

Тынлык.

А л м а с. Исәнме, Инсаф? Саумы, улым?

Инсаф дәшми.

Х а л и с ә. Улым, дәш инде, бер генә сүз әйт...

М и р х у җ а керә.

М и р х у җ а. Тотыгыз!
А л м а с. Кемне?
М и р х у җ а. Менә моны!
А л м а с. Нигә тотарга?
М и р х у җ а. Кача!
А л м а с. Кем кача?
М и р х у җ а. Аны эзлиләр!
А л м а с. Кемне?
М и р х у җ а. Бу малай армиядән качкан.
А л м а с. Качкан?
М и р х у җ а. Дезертир! Мин күрсәттем!
А л м а с. Тукта, кычкырма!
М и р х у җ а. Зиратка качкан! Бәйләргә! *(Бау чыгара.)*
А л м а с. Авызыңны... яп!
Х а л и с ә. Чынмы бу, Инсаф?
И н с а ф. Әйе, мин зираттан качкан дезертир. Армия дигән зираттан. Мин үзебезнең халыкны атарга теләмим. Мин монда кайтып Сөләйман бабам белән киңәштем. Сезне борчымаска уйлаган идем. Менә болар мәҗбүр иттеләр.
Х а л и с ә. Харап иткәнсең бит үзеңне, балакай, хәзер нишлибез?
И н с а ф. Ни генә булса да, минем җаным тыныч хәзер.
Х а л и с ә. Алмас?..
А л м а с. Бер дә юкка борчыласың, Халисә-җан. Инсаф, бер дә кайгырма, барысын да үзем җайлармын.
Х а л и с ә. Хәзер сине ни көтә? Әйт, балам, ни көтә сине?
И н с а ф. Мине трибунал көтә, әни. Әмма вөҗданым саф кала.
М и р х у җ а. Киләләр!

Х а л и с ә. Инсаф, кач! Зиратка кереп кач.

А л м а с. Чыннан да, син зиратка кереп тор. Алар белән мин үзем сөйләшермен.

И н с а ф. Беркая да качмыйм.

Х а л и с ә. Әнә... килеп җитәләр... Балам, мин сине беркемгә дә бирмим. Хәзер безгә атаң ярдәм итәр.

А л м а с. Бер дә аптырап тормагыз. Атаңда сине генә коткарырлык көч бар. Акча гына төртәсе. Акча атаңда миллионлаган. Сатылмаган адәм юк дөньяда. Офицеры белән үзем сөйләшермен. Тынычланыгыз...

И н с а ф. Юкка борчыласың, ата кеше, мине берничек тә сатып алып булмый. Мин мал түгел. Аннары кемнең чын дезертир булуы турында да уйлыйсы бар әле.

Х а л и с ә. Инсаф...

И н с а ф. Тынычлан, әни. Мин үзем аларның кулына бирелән... Әни, сау бул, үзеңне сакла, мин тиз кайтырмын. *(Кузгала.)* Мин Уразов Инсаф! Килегез, мин әзер!

А л м а с. Улым... Инсаф... тукта... бер генә сүз... Икеөч кенә сүз...

И н с а ф. Эзләдем. Таптым. Югалттым.

Айгөл йөгереп керә.

А й г ө л. Инсаф, кач, сине эзләп киләләр!

И н с а ф. Мин үз язмышымны хәл иттем. Сау бул, Айгөл, исән булсак, бер кайтырбыз... Алла бирсә...

Х а л и с ә. Исән булырсыңмы соң, балакаем?

А й г ө л. Кайтырсыңмы соң?

И н с а ф. Сезнең янга кайтмыйлар димени?

Х а л и с ә. Тамагың ачтыр бит, балакаем...

И н с а ф. Безне инде ач торырга өйрәттеләр...

А й г ө л *(чүпрәккә төрелгән икмәкне биреп)*. Инсаф, ал...

И н с а ф *(ала)*. Тормышыгыз шушы ипи кебек түгәрәк булсын, авылдашлар...

Х а л и с ә. Котелогың бушмы? Бир әле, су алып бирим...

И н с а ф. Бушаган икән шул...

Халисә, Инсафның котелогын алып, чишмәгә китә, Айгөл Инсаф янына килә.

Кайткач кочаклармын... Исән бул!

А й г ө л *(кочакларга ашыга)*. Мин сиңа кәккүк булып кычкырырмын.

И н с а ф. Кайда гына булсам да, мин ишетермен. Кара аны, бер генә тапкыр түгел, йөз тапкыр кычкырырсың...

Х а л и с ә *(котелогын биреп)*. Зинһар, үзеңне сакла, бала... Әнә килеп тә җиттеләр... Инсаф!..

Туктап кала. Инсаф үзен эзләп килүчеләргә каршы китә.

Айгөл *(Халисә янына барып)*. Халисә апа, түз... Кайтам диде бит...

Халисә. Көтүнең ни икәнен беләм мин, Айгөл...

Таңзифа таягы белән кармаланып керә.

Таңзифа. Нинди төн булды бу? Беркем йокламый. Зират ягыннан шомлы тавышлар ишетәм. Әрвахлар уянып чыкканмы әллә?

Халисә. Таңзифа апа, балаң кайтты.

Таңзифа. Кайсы балам? Югалганымы? Алмасымы, Инсафымы? Кайда алар?

Халисә. Алмас, кочакла инде әнкәңне...

Таңзифа. Күрсәтегез миңа Алмасымны, Инсафымны...

Халисә. Алмас...

Алмас хәрәкәтсез басып тора.

Таңзифа. Күпме еллар зарыгып көткән Алмасыммы, чынлапмы? Йә Аллам! Кил, балам, кочаклашыйк әле. Син инде зур үскәнсеңдер. И-и-и! Күрәсем килә дә соң үзеңне. Күзләрем йомылды шул, күзләрем. Син нинди хәзер? Чәчләрең һаман чем-карамы? Кайда син, алдыма килдеңме инде? И, күзләрем, бер генә минутка, баламның нурлы йөзен күрү өчен генә ачылсагыз иде... Юк ла, мин болай да таныйм үз баламны, тәнендәге һәрбер ноктасын беләм. Кил, балам...

Алмас аның янына бармагач, Халисә аны көчләп Таңзифа янына китерә. Ул баласын капшап карый.

Юк, бу адәм Алмас түгел. Юк... юк. Әгәр ул Алмасым булса, унсигез ел өзелеп көткән анасының хәлен белми калмас иде. Мин бит ул бәхетле булсын, үлем кочагында ятканда терелсен, югары белем алсын дип, яраткан Сөләйманымны калдырып, Шәмсигә кияүгә чыктым. Гомеремдәге иң үкенечле ялгышым... Әгәр ул Алмас булса, озак еллардан соң булса да үпкәсен онытып, тудырган әнкәсен кичерер иде. Юк... юк... бу минем Алмасым түгел.

Алмас *(артык түзә алмыйча, талпынып)*. Әнкәй, тукта...

Таңзифа. Юк, ул минем балам түгел. Эзләдем. Таптым. Югалттым. *(Чыга.)*

Алмас. Атам ни әйтергә теләде икән бу сүзләре белән?

Халисә. Сөләйман абыйның соңгы сүзләре. Гаилә-

не саклый алмауга мин үзем гаепле, дигән, үз эшемә фанатикларча бирелеп, мин Таңзифаны да, Алмасны да югалттым, дигән.

Алмас. Халисә, без монда артык кала алмыйбыз. Киттек... Ал чемоданыңны...

Халисә икеләнеп тора да, чемоданын ала.

Айгөл. Халисә апа, сез кая?

Халисә. Мин сәхнәдән китәм, Айгөл.

Айгөл. Сез... мине үзегез артыннан сәхнәгә әйдәгән, җанга якын остазым... китәсез... ышанмыйм...

Халисә. Гомеремдә бер генә булса да мин дә бер рәхәт тормыш күрергә тиештер, Айгөл. Мин сиңа сәхнә бәхете телим.

Айгөл. Сез! Сөләйман абыйның шигырьләрен сөйләргә өйрәткән кадерле кешем, сез сәхнәдән китәсез?..

Халисә. Сау бул, сеңлем.

Алмас *(киеренке халәттә)*. Барс!

Сәхнә караңгылана. Шулвакыт бөтен дөньяны ватып-җимереп, ямьсез үкереп үгез килгән, куркышып йөгергән, кычкырган тавышлар ишетелә.

Алмас тавышы. Барс!

Мирхуҗа. Ау!

Алмас. Сакла! Халисә! Машинага!

Мирхуҗа. Момент!

Пистолет аткан һәм Кызыл үгезнең үлем ачысы белән үкергән авазы ишетелә. Прожектор нурлары кабына. Уртадагы сәхнә җимерелгән, аннан хәрабәләр генә калган. Аның янында — пистолетын тоткан Мирхуҗа. Кулында пычак. Ул шамакай көлүе белән көлә. Кулында кып-кызыл канлы зур пычак.

Кых!

Сәләх керә.

Мирхуҗаны син аттыңмы, кабахәт!

Мирхуҗа. Мин!

Сәләх. Ник аттың?!

Мирхуҗа. Дәүләткә тапшырасы хайван. Качкан. Дезертир. *(Көлә.)*

Сәләх. Яраткан хайваным иде. Үзем озатып бардым...

Мирхуҗа. Мин сине беләм: качарга үзең булышкансың...

Сәләх. Мин синнән курыкмыйм. Булыштым. Кузовны үзем ачтым. Нигә аттың?

Мирхуҗа. Мине гаепләмәкче буласың! Ул котырган!

Сәләх. Ул сине күргәч котырган. Ни өчен котырганын беләсеңме?

Мирхуҗа. Төкерәм!

Сәләх. Бисмилла әйтеп, тынычландырып эш кылсаң, мал тыпырчынмый, язмышына буйсына.

Мирхуҗа. Ә нинди аерма?

Сәләх. Аерма зур! Синең исемеңне аңа биреп ялгышканнар. Син ул котырган! Без ул — адәмнәр — котырган! Мирхуҗа, мин сине эзләдем, таптым...

Мирхуҗа. Шуннан ни?

Сәләх. Яшер пистолетыңны, куй пычагыңны! Мин сине тигез көрәшкә чакырам.

Мирхуҗа. Синеңчә булсын. *(Коралларын яшерә.)* Көрәшкә? Ха-ха-ха!

Сәләх *(сөлге ала)*. Башладык!

Тигезсез көрәш, дөресен әйткәндә, сугыш башлана. Мирхуҗа Сәләхне тупас көч-нокаут белән ега. Үзе чыгып кача. Сәләх егыла, соңгы көче белән тора. Хәрабәләрдә Айгөлнең тавышын ишетеп, аны такталар арасыннан күтәрә.

Сеңлем, син исәнме?

Айгөл. Мин... исән. Ә сез?

Сәләх. Сеңлем, ачу белән дөньябызны җимерсә дә, үгезгә ачуланма, ул гаепле түгел. Аны шул хәлгә җиткерделәр. Байлык, көч изге күңелле адәмнәрдә булмаса, сәхнәгә Мирхуҗалар менәчәк... Бирмик сәхнәне аларга!

Айгөл *(сәхнә хәрабәләре арасында Сөләйманның шигырен сөйли)*.

Ишетелде шулчак серле тавыш
Ардым инде, талдым дигәндә,
Төшсәң дә син Җиргә — бик түбәнгә,
Төшә күрмә Җырда түбәнгә!

Артта — пистолеттан аткан тавыш ишетелә. Чын ату тавышы.

Сәләх. Кемнедер аттылар...

Халисә керә. Кулында чемодан.

Айгөл *(каршына йөгерә)*. Халисә апа!

Халисә. Алмасны харап иттеләр!..

Үзәк өзгеч кәккүк авазы ишетелә.

*Пәрдә*

*1997*

# Хуш, Хәйбуш!

*Ике пәрдәле комедия*

**Катнашалар**

Сәнифә — элек мәдәният сараенда эшләгән, хәзер — кафеда җырчы, 35 яшьтә.

Талия — элек китапханәдә эшләгән, хәзер кафеда официантка, 27 яшьтә.

Таминдар — элек партия органнарында эшләгән, хәзер цирк директоры, 37 яшьтә.

Шакир — элек — циркта клоун, хәзер эшсез, 50 яшьтә.

Тайфур — психотерапевт, 40 яшьтә.

Абдул — элек аспирант, хәзер айныткычта дежур-милиционер, 30 яшьтә.

Хаккый — элек — аспирант, хәзер айныткычта врач, 30 яшьтә.

Вакыйга безнең көннәрдә Казанда бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кафе-бар. Бер якта — буфет. Эчке яктарак — эстрада сәхнәсе. Уртада — өстәл, берничә урындык. Диварларда — чит ил артистларының рәсемнәре, шәрә кызлар. Иң күп реклама: хәмер-шәрабкә. Чит ил музыкасы бизәлешендә реклама:
«Ханымнар, әфәнделәр! Дөньяның иң гүзәл илләренә ял итәргә, сәяхәткә чакырабыз!»
«Чибәр, яшь кызларны Урта диңгезнең алтын комы, иркә җиле, ягымлы карашы көтә!»
«Круиз Килиманджаро!»
«Шри-Ланкада — могҗизалы җиде төн!»
«Дөньяда иң арзан урыс аракысы: «Асланов», «Распутин»! «Барселона! Хельсинки! Париж!»

Талия өстәлләрне матурлап, салфеткалар куеп йөри.
Сәнифә керә.

Сәнифә. Булды, Талия!

Талия. Әйттем бит! Минем сүз — үтемле! Алдымы?

Сәнифә. Вакытлыча инде.

Талия. Штатка түгелмени?

Сәнифә. Җырчы, биюче штатта каралмаган, кайчан чакырам, шул көнне киләсең, ди.

Талия. Күпмегә килештең?

Сәнифә. Биегән-җырлаган кадәр.

Талия. Әллә ни түгел түгелен.

Сәнифә. Безгә, эштән куылганнарга, ярап тора. Син уңдың. Официантка! Сугасың акчаны!

Талия. Алдамасаң сугарсың...

Сәнифә. Алдыйсыңмы?

Талия. Дөньясы алдауга корылган. Йә син алдыйсың, йә үзеңне алдыйлар...

Сәнифә. Китапханәдә алдый да, алдана да алмый идең...

Талия. Ярый әле кыскарттылар. Ятар ием тиеннәргә алданып...

Сәнифә. Мәдәният сараенда мин сезне биергә өйрәттем. Хәзер кыргый базар биергә өйрәтә. Менә ничек керергә ул базарга? Керүен бер кереп китсәк, ятар иек ябышып...

Талия. Һәй! Хәзер акыл кирәкми. Аяк белән типтем-кердем. Ишектән кертмәсәләр, тәрәзәне ватып керәм!

Сәнифә. Керерсең, бар... акыл, хәйлә булмаса... Кем мал таба? Аеклар, акыллылар...

Талия. Син эчмисең.

Сәнифә. Бик эчәр ием дә, ярамый, аллергия!

Талия. Мин компаниядә — йөзәм!

Сәнифә. Син батмыйсың!

Талия. Үзем батырам!

Сәнифә. Өстерәп чыгар шунда бер ирне!

Талия. Суга салсаң, калкып чыгар
Безгә тигән яр булса!

Сәнифә. Ирнең шәбе циркта да, кафеда да, Казанда да, Кабанда да ятмый, матурым!

Талия. Кайда ята?

Сәнифә. Әнә тыңла!

Телевизорда реклама ишетелә: «Диңгез буенда ял итәргә теләсәгез, Казаннан самолет белән рәхим итегез: Төркия. Анталия. 230 доллар! Кипр — 450 доллар! Греция. Солоники. 480 доллар!..»

Т а л и я. Кая инде безгә импортный кияү... Доллар, доллар, доллар...

С ә н и ф ә. Теге миңа биергә йөргән Жаннаны беләсеңме?

Т а л и я. Теге шикәр кебек ап-ак кызмы?

С ә н и ф ә. Әйе, озын борынлы...

Т а л и я. Нишләгән?

С ә н и ф ә. Чыккан.

Т а л и я. Юкка чыкканмы?

С ә н и ф ә. Кияүгә чыккан!

Т а л и я. Уф, шартлыйм!

С ә н и ф ә. Кемгә чыккан дип сора?

Т а л и я. Муллагамы? Попкамы?

С ә н и ф ә. Эфиопка!

Т а л и я. Сенсация! Кияү монда калганмы?

С ә н и ф ә. Ире — миллиардер, үзе белән алып киткән.

Т а л и я. Булдыра безнең кызлар!

С ә н и ф ә. Миргә чыга татар! Бөтен дөнья милләтләренең санын арттыра. Үзе бетсә бетә, әмма арттыра.

Т а л и я. Узды мәхәббәт заманы!

С ә н и ф ә. Хәзер мәхәббәт тә — бизнес! Әнә тыңла...

Телевизордан диктор: «Европага чыгару өчен 17—24 яшьлек сылу кызларны көтәбез. Адресыбыз...»

Т а л и я. Без ул юл белән бармабыз!

С ә н и ф ә *(көлеп)*. Без башка юл белән барырбыз! Татар Казанында күп кайнадык, җитте! Җырлый-җырлый, бии-бии минем арттан!

Икесе дә «Ай җаный, вай җаный»ны бозып җырлыйлар.

С ә н и ф ә. Күпме еллар чыгалмыйча
Яшәдек камалышта.
Әйдә киттек Европага,
Калмыйк без Мамадышта!
Һай Джони, вай Джони,
Бармыйк без Мамадышка!

Т а л и я. Эте-бете читкә китә,
Этә-төртә мал таба.
Әллә без дә китәбезме
Йә Цейлон, йә Мальтага?
Һай Джони, вай Джони,
Йә Цейлон, йә Мальтага!

С ә н и ф ә. Кызыгып карап торганчы
«Адидас» ыштанына,
Әйдә, чыгыйк без үзебез

Дөнья масштабына!
Һай Джони, вай Джони,
Дөнья масштабына!

Шакир керә. Кызларның җыр-биюен карап тора да үзе дә катнашып китә.

Шакир. Кызлар, бер дә кызыкмагыз
«Адидас» ыштанына,
Шул ук әбиләр ыштаны,
Төймәсе тыштан гына!
Һәй җаный, вай җаный,
Шакирның да бар җаны!

Сәнифә. Шакир абый?! Нинди җилләр ташлады монда?

Шакир. Кыргый базар җилләре!

Сәнифә. Әллә сине дә?

Шакир. Җырлап йөрим хәзер
Манный ботка кабып:
«Начальниклар — симез,
Еллар — ябык!»
Алар калҗа каба
Коньяк эчәләр дә,
Җилләр генә исә
Безнең кесәләрдә.
Ошбу җилләр җитсен
Халык массасына,
Сәламемне илтсен
Саклык кассасына!

Сәнифә. Кыскарттылармы?

Шакир. Миннән башкалар барсы да
Малтабар йә эшкуар,
Мине дә эштән кудылар,
Шакир хәзер — җилкуар.

Сәнифә. Утыр, Шакир абый!

Шакир. Рәхмәт, утырттылар инде төп башына!

Талия. Меню! Мерси, месье Шакир. Француз коньягы? «Наполеон»?

Шакир. «Вермут» булса да ярар ие дә... Сезнең янга эш эзләп килдем, кызлар. Белдерүне укыдым. «Хуш, Хәйбуш» кафесына швейцар кирәк. Югары белемле булса да ярый, французча белсә, татарча белүнең кирәге юк. Белемем югары, борын — түбән, французча сукалыйм беraз, ләкин татарчаны яхшы белү аяк чалмаса гына инде?!

Сәнифә. Бәхетеңне сынап кара, Шакир абый. Синең кебек мәшһүр клоунны, бәлкем, алыр да?!

Шакир. Тәвәккәлләдем, кызлар. Кайсы ишектән

кире чыгарга? Хуш, Хәйбуш! Бисмиллаһи рахман рахим... *(Ишектән эчкә кереп китә.)*

Т а л и я. Милиция!

А б д у л керә.

А б д у л. Сәнифә апа? Талия? Сез?!

С ә н и ф ә. Без...

Т а л и я. ...идек.

А б д у л. Әллә мин ялгыш кердемме? Китапханә, мәдәният сарае монда күчтеме әллә?

С ә н и ф ә. Базар!

А б д у л. Кесә бар, карман юк.

Т а л и я. Дәрт бар, дәрман юк.

С ә н и ф ә. Карман бар, доллар юк!

А б д у л. Бие, бие, Абдулла,
Биегән кеше бай була!

С ә н и ф ә. Биегән кеше бай булганда...

А б д у л. Карт алаша тай була! Сәнифә апа, биеп баемады Абдул!

С ә н и ф ә. Базар биетә, Абдул!

А б д у л. Их, кызлар, сезне күргәч, әллә нишлисе килеп китте!

Т а л и я. Салып биримме?

А б д у л. Ураза!

С ә н и ф ә. Озаккамы?

А б д у л. Капитализмга җитеп, аякларны салындырып утырмыйча капмыйм!

Т а л и я. Фу! Авызыннан американски сигара, виски исе килмәгән егетләрне яратмыйм!

А б д у л. Дөнья безнең кулда! Кабарбыз тегесен дә, монысын да! Яратырсың, канәтем, әле Абдул абзаңа йөгереп кияүгә чыгарсың!

Т а л и я. Юк! Милиционерга чыкмыйм.

А б д у л. Кемгә чыгасың?

Т а л и я. Миллионерга.

А б д у л. Канәтем, мин ике тапкыр миллионер, ике ай саен миллион алам!

Т а л и я. Сөйләнгән буласың, машинаң да юктыр әле!

А б д у л. «Мерседес»!

С ә н и ф ә. Абдулдан булыр!

А б д у л. Сезне дә утыртырмын бер! Шәһәр уратырмын!

Т а л и я. Булмас. Күргән юк.

А б д у л. Алып кайтам. Польшадан!

С ә н и ф ә. Чит илгә алып чык, Абдул. Польшага булса да...

Абдул. Карап карарбыз.

Сәнифә. Мин шаярмыйм.

Талия. Мин дә!

Абдул. Икегезне дә! Бер генә нәрсә кирәк...

Сәнифә. } Нәрсә?
Талия. }

Абдул. Доллар!

Сәнифә. Безнең акча ярамыймы?

Абдул. Поты бер тиен аның дөнья базарында.

Талия. Анысы да юк әле...

Сәнифә. Син нишләп йөрисең әле айныткычыңны ташлап?

Абдул. План тулмый, анасын сагыныйм! Чыктым берәр чит илдән килгән исерек эләктереп булмасмы дип... Француз наркологы килгән диләр. Туп-туры Париждан...

Сәнифә. Париждан?! О!

Абдул. Кесәсе тулы франк инде аның. Ул сезгә керми калмас...

Талия. Керсәме... керсә... миннән ычкыналмас.

Сәнифә. Чит ил белән алай кыланырга ярамый.

Абдул. Дөрес, аны милиция сакларга тиеш. Яшерен-батырын түгел, безгә эләксә, айлык план — шалт! Барып җиттеме? Кабатлыйм, сезгә керсә...

Талия. Кереп кенә карасын!

Сәнифә. Керә генә күрсен...

Абдул. Кабатлыйм, сезгә керсә... Эчертегез... юк, юк, тиененә дә кагылмыйсыз. Исертегез, аннары шушы номерга телефоннан — шалт Абдул! Карагыз аны, француз өчен без үзебез җавап бирәбез! Мин әйткәнчә булсын! Гутбай! *(Чыга.)*

Ишектән Шакир атылып чыга. Кызлар аны күтәреп торгызалар.

Сәнифә. Алдымы?

Шакир. Алды... Котны алды! «Әртисләрнең поты бер тиен!» дип артка тибеп чыгарды, кабахәт! Бисмилла да әйттем инде югыйсә кергәндә... Дәү әни әйткән иде: «Начальнигың янына кергәндә дүрт тапкыр «бисмилла» дип әйт, нигә дисәң, начальник бүлмәсенең дүрт почмагында дүрт шайтан ятар, «бисмилла» әйтү белән чыгып «сызарлар» дип. Сүзләре бу юлы расланмады: үзе шайтан булып чыкты, ерткыч!

Сәнифә. Тс-с-с... әкрен...

Талия. Үзе ишетмәсен...

Шакир. Төртмәсәң дә аварга торасың, йолкыш, ди, хәшәрәт!

Сәнифә *(авызын каплап).* Кычкырып әйтмә, Шакир абый!

Талия. Тынычлан, Шакир абый, бар, бар...

Шакир. Кесәңдә акчаң булмаса, тавышы да әкрен чыга шул. Иблис! Кемнәр кулына калдык, кызлар, ә? Әле минем баҗам бар! Ишегалды себерә! Йөз дә утыз кило! Аны беркем дә куалмый! Киттем баҗама! Бирешмәгез, кызлар! Алга, Шакир абый! *(Китә.)*

Сәнифә. Бирешмик, Талия!

Талия. Керсен генә француз, эләктерәм!

Сәнифә. Талия, кагылма французга, минеке!

Талия. Нишләп ул синеке булсын, синең ирең бар.

Сәнифә. Әй, бер мәртәбә чит илгә алып чыгалмагач, шул да ир булдымы! Париж! Гомерлек хыялым! Эйфель башнясы төшләремә килеп керә...

Талия. Әгәр ул миңа караса, нишләрсең?

Сәнифә. Таракан булып төшмәкче буласыңмы? Мин французларның зәвыгын беләм. Алар нечкә билле кызларга карыйлар.

Талия. Ул үзе дә минем кебек юан булса?

Сәнифә. Юан булса да, нечкә булса да, минем хыялыма тимә, Талия!

Талия. Ярар, миңа берәр эфиоп булса да ярар. Ирең булганга гына әйткән идем.

Сәнифә. Һәй, искә төшермә әле шуны! Ул Парижны бар дип тә белми. Күпме ялындым Парижга барыйк дип. Колагына да элми. Аның Финляндиягә барасы килә. Имеш, арзанга төшә. Бүген, мәхлук, йөгереп кайтып кергән: «Киттек Финляндиягә!» — ди. Үзендә циркта булган фин татарлары чакыру җибәргәннәр. Хатын белән килү мәҗбүри икән. Гаиләгә багышланган корылтай үткәрәләр икән. Мин Финляндиядә булдым. Мин: «Париждан башка беркая да аяк басмыйм!» — дип, өйдән чыгып киттем.

Талия. Таминдар абый үпкәләп калдымы?

Сәнифә. Ул бик ачуны китерсәң, алдым-кайттым булыр яшь хатын,— дип кычкырып калды.

Талия. Алып та кайтыр!

Сәнифә. Әй, таптың яшь хатын ала торган ир!

Талия. Ә мин барыр идем Финляндиягә!

Сәнифә. Таптың барыр урын! Париж, бары тик Париж!

Француз музыкасы. Телевизор экранында — Тайфур һәм Жан Дустэн.

Тайфур. Месье Жан Дустэн, мин Сезне Татарстан җирендә сәламлим.

Ж а н. О, сәлам татарларга!

Т а й ф у р. Сез татарча беләсез?

Ж а н. Татар бизнесменнары белән татарча сөйләшәм.

Т а й ф у р. Без бик шат. Димәк, тәрҗемәче кирәкми. Әйтегез әле, Сез Париждан Казанга нинди максат белән килдегез? Хөрмәтле тамашачылар, Жан Дустэн — минем коллега, наркология белгече.

Ж а н. Мин килдем өйрәнергә татарлар ничек эчәләр. Ничек аларны дәвалыйлар. Тайфур әфәнде ничек эшли. Тайфур әфәнде мине өйрәтә, мин аны өйрәтәм. Без аның белән төзибез... татарча ничек әле... договор. Мин белмим татарлар күпме эчәләр, но беләм Татарстанда аракы сатыла күп. Була шундый эчүче, аны булмый дәвалап... татарча ничек... не поддается... Шундый биш кешене Парижга алып китәм...

Т а л и я. Ишеттеңме?

С ә н и ф ә. Тс... с... с!

Т а й ф у р. Үз чиратында коллегабыз биш французны миңа алып киләчәк.

Ж а н. Әйе. Дәваларга татарча.

Т а й ф у р. Безнекеләрне кайчан алып китәргә уйлыйсыз?

Ж а н. Бик тиз.

Т а й ф у р. Ярый. Ә акчаны кем түли?

Ж а н. Түли безнең фирма.

Т а л и я. Сәнифә апа, бушлай!

С ә н и ф ә. Бушлай!

Ж а н. Француз кызыксына татар белән. Эчүче татар бар, беләм. Эчмәүче татар бармы? Күрсәтегез, булса...

Т а й ф у р. Борчылмагыз, коллега. Бөтенләй эчмәүчене табуы авыр булыр булуын, шулай да табарбыз. Минем күршемдә генә эчмәүче ирле-хатынлы күршеләрем бар. Шулар белән бүген үк таныштырырмын...

Ж а н. Мерси. Рәхмәт.

Т а й ф у р. Кемнәрне алып китәргә уйлыйсыз. Ирләрне генәме?

Ж а н. Эчүче кызлар юктыр татарда?

Т а й ф у р. Кызганыч, әмма, күп шул.

Ж а н. Алайса, бер хатын-кыз алам...

С ә н и ф ә *(Талияне кочаклап)*. Талия, булды!

Т а л и я. Нишлисең, тилердеңме әллә?

С ә н и ф ә. Без китәбез!

Т а л и я. Кая китәбез?

С ә н и ф ә. Мин — Парижга! Син — Финляндиягә!

Т а л и я. Минем бер доллар да юк.

С ә н и ф ә. Минем дә юк. Бушлай китәбез!

Т а л и я. Ничек?

С ә н и ф ә. Ишетмәдеңмени? Тайфур Алтынбаев — минем күршем. Ул французны безгә алып керәчәк.

Т а л и я. Аңламыйм.

С ә н и ф ә. Әрсез, хәйләкәр булмасаң, батасың бу заманда.

Т а л и я. Нишлибез соң?

С ә н и ф ә. Хәзердән үк мин — алкаш, син — Таминдарның хатыны!

Т а л и я. Ә?

С ә н и ф ә *(җыр башлый, Талия аны күтәреп ала).*

Суга салсаң, калкып чыгар
Безгә насыйп яр булса!

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Таминдар Хәбиб фатиры. Сәнифә өйдә юк. Кич.

Т а м и н д а р *(телефоннан).* Һалло! Кем бу? Тайфур? Безгә кунакка киләсез? Телевизор карамадым. Кем белән? Җан дустың белән? Жан Дустэн? Француз? Нигә безгә? Эчмәүче гаиләгә? Башканы таба алмадым? Юк! Мин әйттем, эш сәгате бетте. Мин өйдә кабул итмим. Син аны циркка алып бар. Юк, юк! Суыткычта җилләр уйный. Алты ай хезмәт хакы алган юк. Сәнифә кайтмады әле. Эш эзләп йөри. Әллә кайта, әллә юк. Үпкәләштек. Финляндиядән булса бер хәл, Франциядән — юк! Мин әйттем, кѳтмим! Сәлам белән Таминдар. *(Трубканы куя.)* Мәхшәр! *(Ишекле-түрле йөри. Ишектә — кыңгырау.)* Теге кайтты... *(Ишек ачарга бара.)*

Ш а к и р. Элекке партия хезмәтчесенә элекке клоуннан сәлам!

Т а м и н д а р. Сәламеңне алмыйм, кереп торма. Фу, хәмер исе килә. Сәнифә кайтып керсә, җаныңны алыр!

Ш а к и р. Юк, керәм.

Т а м и н д а р. Нишләп йөрисең? Мин сине чакырмадым.

Ш а к и р. Шакир хәзер эшсез клоун. Хуҗасы чакырмаса да килә.

Т а м и н д а р. Приказ эленгән. Мин әйттем!

Ш а к и р. Анда сәбәбе әйтелмәгән.

Т а м и н д а р. Өстән күрсәтмә килде. Штатны кыскартырга!

Ш а к и р. Хуш, Хәйбуш! Ә нигә клоунны кыскартырга? *(Узарга уйлый.)*

Т а м и н д а р. Узып торма. Мин әйттем!

Ш а к и р. Әйтеп бетер. Нигә мине?

Т а м и н д а р. Кемне кыскартыйм?

Ш а к и р. Үзеңнән башларга иде.

Т а м и н д а р. Миңа бер клоун бик җиткән. Утырып торма! Синең сул колагың бик әйбәт ишетми. Уң колагың белән тыңла! Беренчедән, Степановны кыскартып булмый.

Ш а к и р. Милләтчелектә гаеплиләр.

Т а м и н д а р. Мин — интернационалист! Икенчедән, син саласың...

Ш а к и р. Сәхнәдә салган юк бит. Менә минем баҗам бар...

Т а м и н д а р. Баҗаңны катыштырма, үзең турында сүз бара. Кайда эчсәң дә, салу — салу инде ул.

Ш а к и р. Өченчедән...

Т а м и н д а р. Бизнес заманы! Адәм көлдереп, авыз ерып доллар эшләп булмый. Минем план: дөнья масштабына чыгу. Мин әйттем!

Ш а к и р. Чыгалмыйсың син дөньяга миннән башка! Менә минем баҗам бар...

Т а м и н д а р. Чыгам! Юлбарыслар гына исән булсын. Ерткычларга җитәкче булу җиңелрәк, аюны да биергә өйрәтәбез... Эчмиләр, тартмыйлар, ашарга гына сорыйлар. Мәхшәр!

Ш а к и р. Ачтан үтерәсең инде мескеннәрне. Хуш, Хәйбуш!

Т а м и н д а р. Хуш, хуш, киттеңме?

Ш а к и р. Миннән җиңел генә котылмакчы буласыңмы? Әйтәсе сүзләрем бар әле.

Т а м и н д а р. Ара өзелгән.

Ш а к и р. Мин кунакка чакырылган.

Т а м и н д а р. Сине чакырдылармы?

Ш а к и р. Мине! Сәгать җидегә.

Т а м и н д а р. Синең кемгә кирәгең бар?

Ш а к и р. Мине хөрмәт итүчеләр бетмәгән шул. Шакир абзаңны бөтен дөнья белә. Мине кем чакырганны беләсеңме?

Т а м и н д а р. Беркем дә!

Ш а к и р. Тайфур Алтынбаев шәхсән үзе мине чакырды. Парижның үзеннән килгән доктор чакырырга кушкан. Белдеңме?

Т а м и н д а р. Сине Парижда түгел, Казанда да белмиләр. Тайфур кирәк булса, бар, кер үзенә, әнә күршедә... Артыңа тибеп чыгарырлар...

Ш а к и р. Син, энекәш, үзең белән бутама кешене.

Т а м и н д а р. Мин сине дөрес куганмын. Аеклыгың турында белешмә алып килсәң, бәлки, уйлап та карармын. Ә хәзер, хуш, хуш, Хәйбуш!

Ш а к и р. Шакир абзаң чакырган җиргә килә, куган җирдән китми.

*(Түргә барып утыра.)*

Ишек кыңгыравы.

Әнә кунаклар каршыла!

Т а й ф у р белән Ж а н Д у с т э н керә.

Т а й ф у р. Хәерле кич, күрше!

Ж а н. Исәнмесез?

Ш а к и р. Пардон! Мерси!

Т а м и н д а р *(югалып кала)*. Мин әйттем...

Ш а к и р. Юк, мин әйттем.

Т а й ф у р. Көтелмәгән визит булмасын өчен, без алдан искәрттек.

Т а м и н д а р. Мин белмәдем...

Т а й ф у р. Жан Дустэн әфәнде, таныш булыгыз, минем иң якын күршем, цирк директоры Таминдар Хәбиб! Хәмерне авызына да алмый торган гаиләнең бер әгъзасы, ягъни мәсәлән...

Ж а н. Жан Дустэн. Бик шатмын.

Т а й ф у р. Париждан. Нарколог. Минем коллега, ягъни мәсәлән. Рәхим итеп түргә узыгыз. Таминдар әфәнде, эчмәүгә дә карамастан, бик кунакчыл кеше.

Т а м и н д а р. Мин әйттем...

Т а й ф у р. Син әйтсәң әйтәсең инде... Сәнифә кайда?

Т а м и н д а р. Кайтмады әле.

Т а й ф у р. Таминдар әфәнденең сөекле вә сөйкемле хатыны мадам Сәнифә белән дә танышырсыз, ягъни мәсәлән. Утырыгыз.

Ж а н *(утыра)*. Рәхмәт.

Ш а к и р. Мерси.

Т а м и н д а р. Аңламадым. Наркологиягә минем гаиләнең ни катнашы бар? Безнең өйдә, үзегез беләсез, коры закон...

Т а й ф у р. Менә, менә! Хөрмәтле кунакны нәкъ әнә шул нәрсә кызыксындыра да. Тәк... ие... Татарларның хәмергә мөнәсәбәтләрен тикшерү өчен, ул Париж кадәр

Париждан махсус килгән, ягъни мәсәлән. Ул минем дәвага бирелми торган биш эчкечемне, үз ысулы белән терелтү өчен, Парижга алып китәчәк, ягъни мәсәлән.

Таминдар. Мин эчкән кеше белән рәттән басып та тора алмыйм, минем моңа ни катнашым бар?

Жан. Месье Таминдар, мине эчмәүче һәм шулай ук эчүче татарлар кызыксындыра. Әгәр алар булса...

Шакир. Менә минем баҗам бар...

Жан. Мин бер китапта укыдым, татар хәмердән баш тарткан халык дип...

Шакир. Борын заманда ул, борын заманда...

Жан. Фәнни эшем өчен миңа бер мисал кирәк. Эчми торган татарлар!

Тайфур. Иң уңышлы мисал: эчми торган ике татар!

Шакир. Безнең заман геройлары!

Тайфур. Таминдар әфәнде, хөрмәтле коллега алдында үзегезнең аракы эчмәү тәҗрибәгез белән уртаклашсагыз иде.

Таминдар. Эчмим, бетте-китте!

Тайфур. Конкретно! Эчәсегез килеп тә эчмисезме, әллә...

Таминдар. Эчәсе килә... Коточкыч эчәсе килә... Хатыным...

Жан. О! Бу бик кызык! Хатыныгыз?

Таминдар. Хатынымның да бик эчәсе килә. Әмма...

Жан. Йә, йә?

Шакир. Үзе эчәлмәгәч, ирен дә эчерми! Хуш, Хәйбуш!

Таминдар. Хатында — алкогольгә аллергия!

Жан. Аллергия? Искиткеч кызык!

Таминдар. Кызык түгел, бәхетсезлек! Мәхшәр! Бәйрәм күргән юк! Хәмер исе килгән адәмне дошман күрә!

Шакир. Хуш, Хәйбуш!

Таминдар. Үзара әйткәндә, нормаль тормыш түгел.

Шакир. Бик зур бәхетсезлек. Менә минем баҗам бар...

Тайфур. Хуш, Хәйбуш!.. Инде килеп, кадерле коллега, сезне фәнни объект буларак кызыксындырырлык икенче бер мисал! Таныш булыгыз, Шакир иптәш!

Шакир. Әфәнде!

Тайфур. Әлегә әфәнде түгел! Бик тә принципиаль үҗәт адәм. Сезнең өчен бик һәйбәт субъект, ягъни мәсәлән.

Ж а н. Хәмергә мөнәсәбәте?

Т а й ф у р. Бик тә уңай.

Ш а к и р. Хуш, Хәйбуш!

Т а й ф у р. Миңа биш тапкыр килеп, биш тапкыр эчүен ташлады. Дәвага бирелмәүче клиентларымның иң көчлесе, ягъни мәсәлән. Иң лаек кандидатым шушы!

Ж а н. Мин сезне аңладым.

Ш а к и р. Хуш, Хәйбуш!

Т а й ф у р. Шакир иптәш...

Ш а к и р. Әфәнде...

Т а й ф у р. Әлегә әфәнде түгел. Чын әфәнде буласың киләме?

Ш а к и р. Тагын дәваланырга кил димәкче буласыңмы? Хуш, Хәйбуш!

Т а й ф у р. Шәһәрләрнең шәһәре Парижга барып, Эйфель башнясына менеп, дөньясына төкерәсең киләме?

Ш а к и р. Менә минем баҗам бар. Ул төкерсә...

Т а й ф у р. Ул төкерде инде... риза булмады. Менә сиңа шул мәгълүм булсын, миндә исәптә торучыларның иң зур стажлы ветераны буларак, әгәр Жан әфәнде алса...

Ж а н. Мин сезгә тапшырдым.

Т а й ф у р. Мин сине Парижга җибәрергә уйлыйм.

Т а м и н д а р. Шәп! Мин дә котылырмын!

Ш а к и р. Парижга?

Т а й ф у р. Парижга.

Ш а к и р. Мине? Шакирны?

Т а й ф у р. Сине. Шакирны.

Ш а к и р. Күпме түләргә?

Т а й ф у р. Бушлай.

Ж а н. Безнең фирма хисабына.

Т а м и н д а р. Мәхшәр! Сөенә дә белми!

Т а й ф у р. Шакир әфәнде! Бие! *(Шакирны уратып җырлыйлар, Жан да селкенә.)*

Т а м и н д а р, Т а й ф у р.

Безнең урам чокыр-чакыр,
Париж урамы такыр;
Парижларга бару белән
Безне кунакка чакыр.
    Ай Шакир, вай Шакир,
    Париж урамы такыр.
Парижга баргач та Шакир
Мадам ишеген шакыр;

Без дә анда барыр идек —
Кесә яклары такыр.
Ай Шакир, вай Шакир,
Кесә яклары такыр.
Анда безне дә онытма,
Без калабыз, без — фәкыйрь;
Иптәш булып киткән Шакир
Әфәнде булып кайтыр.
Ай Шакир, вай Шакир,
Әфәнде булып кайтыр.

Т а м и н д а р. Хуш, Хәйбуш! Кире кайта күрмә!

Т а й ф у р. Үзеңне Парижда дип уйла!

Ш а к и р. Туктагыз әле, нигә җырлыйсыз, нигә сөенәсез?

Т а й ф у р. Парижга китәсең бит!

Т а м и н д а р. Бушлай!

Т а й ф у р. Миндә ирешмәдең... анда, бәлки, юлын табарлар. Жан әфәнде ышандыра. Курыкма, минем белән барасың!

Ш а к и р. Мин бармыйм!

Т а м и н д а р. Парижга?! Бушлай?!

Т а й ф у р. Тәк... ие... Гаҗәп.

Ж а н. Ул бармый? Кызык.

Т а м и н д а р. Мәхшәр! Үзем китәр идем! Нигә генә сәрхуш булмадым...

Т а й ф у р. Кыланма, шаярма.

Ш а к и р. Аек баштан әйтәм. Бармыйм. Менә минем баҗам бар...

Т а й ф у р. Мин аңа әйтеп карадым инде. Баҗаң да үзеңә охшаган. Кәҗәләнә. Салих белән Борис риза.

Ш а к и р. Юк, бармыйм. Хуш, Хәйбуш!

Т а м и н д а р. Безнең татар шул инде, киребеткән нәрсә! Дөнья аренасына чыгарга нинди шәп момент бит, ә! Их, нигә генә сәрхуш булмадым! Синең урында мин булсам... *(Әрле-бирле йөри.)* Үзең турында уйламасаң, милләтең турында уйлар идең. Юк, булмый болар белән!

Т а й ф у р. Сине дәваларга бөтен дөньяның наркологлары алына икән, нигә баш тартырга?

Ж а н. Кызык кеше, кызык.

Т а й ф у р. Бер дә дөнья күрәсең килмимени?

Ш а к и р. Дөньяның мине күрәсе дә килми. Клоун буларак чыгарсагыз бер хәл.

Т а й ф у р. Клоун һөнәре Жан әфәндегә кагылмый. Соңгы тапкыр сорыйм, бармыйсыңмы?

Ш а к и р. Әгәр ошбу адәм цирктан кумаса, мин аренада җырлар идем, менә болай дип:

Эчәм дисәң суы,
Чәе-мәе бар ич,
Юк мин бармыйм анда,
Нигә миңа Париж?
Эйфельләрең белән
Дан казанган Париж,
Кызыктырма мине,
Сөембикәм бар ич!
Син дә барма, баҗа,
Син дә барма, Борис,
Казаныбыз бар ич,
Нигә безгә Париж?

Ишек кыңгыравы чылтырый.

Т а м и н д а р. Сәнифә!

Т а й ф у р. Ул!

Т а м и н д а р. Ярый әле эчмәдегез... *(Шакирга.)* Иптәш-әфәнде, сак бул, хәмер исеңне сизсә... Парижга кадәр очарсың!

Ш а к и р. Менә минем бер баҗам бар...

Т а й ф у р. Хөрмәтле коллегам, хәзер мин сине милләтебезнең иң мәдәниятле, тәртипле, тәүфыйклы, эчү-тартуның җан дошманы белән таныштырам. Сәнифә ханым Хәбиб...

С ә н и ф ә керә. Өйдәгеләрнең кемнәр икәнен чамалап ала да, исерек хатынны уйный башлый.

С ә н и ф ә. Әй, син! *(Плащын идәнгә атып бәрә.)*

Т а м и н д а р *(аптырап)*. Кем? Минме?

С ә н и ф ә. Син кем?

Т а м и н д а р. Таминдар ич.

С ә н и ф ә. Таминдар? Кайсы Таминдар?

Т а м и н д а р. Синең ирең.

С ә н и ф ә. Кайсы ирем?

Т а м и н д а р. Синең ирең бер генә.

С ә н и ф ә. Ни өчен бер генә?

Т а м и н д а р. Сәнифә...

Сәнифә. Нинди Сәнифә ул?! Сәнифә юк хәзер дөньяда! Мин — Сәниф!

Таминдар. Сәнифә, нишләдең син? Танымыйм...

Сәнифә. Син әле мине танымыйсыңмы? Танытырбыз! Кагылма плащка! Ятсын! Мин әллә башка фатирга кайттыммы? Бутаганмын... *(Чыгарга бара.)*

Таминдар. Син үз өеңдә. Кер, тынычлан... Әйдә, җаным, ятып тор...

Сәнифә. Синең белән ятарга әллә мине фахишә дип уйлыйсыңмы? Кит! *(Тегеләрне күрә.)* Әйттем бит ялгыш кергәнмен дип... Болар кемнәр?

Тайфур. Исәнме, Сәнифә?

Сәнифә. Исән булмасам, әллә син доктормы?

Тайфур. Әйе. Доктор.

Сәнифә *(Тайфурның галстугына тотына)*. Син мине ихтирам итәсеңме, юкмы?

Тайфур. Тәк... ие... ычкындыр, зинһар!

Сәнифә. Ихтирам итәсеңме, юкмы?

Тайфур. Итәм, итәм, Сәнифә ханым... әй... Сәниф!

Сәнифә. Ә монысы кем? Күзләрен җемелдәтеп утыра!

Шакир. Хуш, Хәйбуш!

Сәнифә. Хуш, Хәйбуш? Эштән чыгарылган татар артистымы?

Шакир. Тач өстенә бастың!

Сәнифә. Шакир абый, бәгърем, хуш Хәйбушым, ник аны әйтми торасың? *(Кочаклый.)* Бүгенге көндә иң яраткан кешем син!

Шакир. Мин әле чүп! Менә минем баҗам бар...

Сәнифә. Үзең булганда, баҗаңның кирәге юк.

Таминдар. Сәниф... ни бит... бездә зур кунак бар. Синең урында булсам...

Сәнифә. Кунак? Чакырылганмы?

Таминдар. Чакырылмаган да, татар да түгел.

Тайфур. Таныш булыгыз, Франциядән... Нарколог.

Сәнифә. Наркоман? Менә аларны мин ихтирам итәм.

Жан. Юк... юк... Париж. Клиника. Жан Дустэн.

Сәнифә. Кайчандыр кемнәрнедер биеткән мадам Сәнифә Хәбиб. Әй, ир!

Таминдар. Кем? Минме?

Сәнифә. Син кемнең ире соң?

Таминдар. Синеке.

С ә н и ф ә. Ирем булсаң, тыңла, үтә! Франция кадәр Франциядән затлы кунак килгән. Кайда яртың?

Т а м и н д а р. Үзең беләсең, безнең өйгә хәмер кергәне юк.

С ә н и ф ә. Тап!

Т а м и н д а р. Ярты юк.

С ә н и ф ә. Их, Шакир абзыкаем, болар мине бөтен дөнья масштабында көлкегә калдыралар бит. Коткар, җаным!

Ш а к и р *(куеныннан грелка тартып чыгара)*. Шәхси фирма: «Хуш, Хәйбуш»!

С ә н и ф ә. Ярар. «Хуш, Хәйбуш»ны эчәбез, безгә барыбер! Тик аяктан гына ексын! Месье Жан әфәнде. Пардон! Рәхим итегез, өстәлгә. Бонжур! *(Таминдарга.)* Стакан!

Таминдар бокал китерә.

Стакан! Сез дә утырыгыз... Сал, Шакир абый!

Өстәл тирәли утыралар.

Ж а н *(алдындагы тулы стаканны иснәп)*. Бу нәрсә?

Т а й ф у р. Соңгы елларда кулланылышка кергән халык иҗаты әсәре. Сак булыгыз, Жан әфәнде! Тост!

С ә н и ф ә *(чәкешә)*. Ля Париж!

Ж а н *(каба да кире куя)*. Ой! Янам!

Ш а к и р *(каплап куя)*. Хуш, Париж!

Ж а н. Исәнме?..

С ә н и ф ә *(Шакирны кочаклап җырлый)*.

Стаканның шунсы яхшы —
Мөлдерәп утырганы,
Дус-ишләрнең шунсы яхшы —
Гөлдерәп утырганы!

Хуш, Хәйбуш! *(Таминдарга.)* Син минем ирем булсаң, сал, капла. Кабымлыкка — чемечкә! *(Кесәсеннән ала.)* Бүлегез!

Т а м и н д а р. Мин әйттем... эчмим!

С ә н и ф ә. Мин әйтәм, эчәсең! *(Көчләп эчерткән булып, үз стаканын түгә.)* Мин хәмернең исеннән исерәм, борчылмагыз, әфәнделәр! Их, Шакир абзыкачкаем, узган икән гомерләрем заяга. Ирләр юкка гына салмый икән. Рәхәтләнеп бер җырлыйк әле, биик әле, Шакир абзыкаем! *(Икесе җырлап-бииләр.)*

Күңелләр тирән булса да,
Кесә яклары сай, буш.
Хуш, Хәйбуш!
Үзеңнең җырың җитмәсә,
Минем җырымны да куш!
Хуш, Хәйбуш!
Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде чит илгә,
Хуш, Хәйбуш!
Китмәс идем дә чит илгә,
Үз илемдә читен лә!
Хуш, Хәйбуш!
Китә инде, китә инде,
Китә инде кораблар,
Хуш, Хәйбуш!
Бәлки, бөтенләй кайталмам,
Җаным, бәгърем, карап кал!
Хуш, Хәйбуш!

Сәнифә *(Тайфур алдына барып тезләнә)*. Тайфур, коткар мине! Мин эчүдән тыела алмыйм. Дәвала мине, харап итмә...

Җан. Тайфур әфәнде, әллә без ялгыш кердекме?

Тайфур. Бер минут, коллегам. Тәк... ие. *(Сәнифәгә.)* Бу сезнең нервыларның вакытлыча ычкынуы гына. Стресс. Мин сезне бу хәлдә беренче тапкыр күрәм. Шунлыктан сезне сәрхуш дип кабул итә алмыйм.

Сәнифә. Мин әлегә кадәр яшердем. Сиздермәскә тырыштым. Үзегезгә алыгыз.

Тайфур. Берни дә эшли алмыйм. Минем өчен бу — аз.

Сәнифә. Ах, шулаймы? Дәваларга теләмисез? Кыскасы, булдыра алмыйсыз. Хатын-кызны биздерү авыр шул, мөмкин түгел. Шакир абый, мә акча, бер ярты алып кер!

Шакир. Менә минем бер баҗам бар...

Сәнифә. Баҗаңны да кыстырып кил. Өчәү типтербез!

Таминдар. Сәнифә, ял ит, ятып тор!

Сәнифә. Синең белән ятып шушы көнгә калдым инде. Шакир дус, бир әле каешыңны!

Шакир. Минем баҗам... *(Каешын бирә.)*

Сәнифә. Баҗаңны да күтәреп бәрәм! Мин ирләр белән тигезсез көрәшкә чыгам. *(Каешын тотып.)* Та-

тарчамы, французчамы? Йә, кемнән башлыйбыз? Селяви! Ля Париж? Ля татар? Йөрәгегез булса, чыгыгыз! Таминдар?! Тайфур?!

Кыңгырау чылтырый.

Ш а к и р. Минем баҗам түгел микән? Ярый, хуш, Хәйбуш!

С ә н и ф ә. Шакир абыкаем, тукта. Болар белән булмый! Киттек салырга! Баҗаңны да кереп алабыз! Икебезгә бер баҗа, өчебезгә бер ярты! Үзем сыйлыйм!

Т а м и н д а р. Сәнифә, айны...

С ә н и ф ә. Сәлам белән Сәнифә. Исәр җилләр, чыгар кояш, бездән сәлам шул булыр! *(Шакирны кочаклап җырлый.)* Әйдә, шешәдәш дустым, киттек!

Стаканым путалы,
Уң кулыңа тот әле,
Алай бигүк эреләнмә,
Вак-вак итеп йот әле!

Чыгалар. Бүлмә тын кала. Таминдар башын игән. Тайфур белән Жан да дәшми.

Т а й ф у р. Шундый-шундый хәлләр...

Ж а н. Коллега, ни булды бу?

Т а й ф у р. Үзем дә аңламыйм. Безнең районда эчмәүче бердәнбер гаилә дип йөрсәм...

Ишектә — кыңгырау.

Кемдер килә... Без киттек... *(Чыгалар.)*

Т а м и н д а р. Нишләргә бу хатын белән? Ничек яшәргә?

Алдында яшь гүзәл кыз Т а л и я басып тора.

Нигә килдегез?

Т а л и я. Мин сезгә икенче хатын булып килдем, Таминдар абый!

*П ә р д ә*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Айныткыч. Исерекләрне кабул итү бүлмәсе. Лозунглар эленгән.
«Исеректән исерек туа». *Плутарх.*
«Исерү — үзең теләп акылдан язу». *Пифагор.*
«Исерек халык белән идарә итү җиңелрәк». *Екатерина II.*
«Килеп кермә монда, аек баш,
Исерек булсаң гына аяк бас!» *Абдул Айнутдинов.*
Пәрдә ачылганда ак халатлы Хаккый ялгызы.

Хаккый *(җырлый).*

Париж, Париж,
Гүзәл матур кала,
Халык шунда бара,
Казан озатып кала...

Абдул *(формадан керә).* Хаккый, ура!

Хаккый. Ни булды?

Абдул. Дөнья аренасына чыгабыз!

Хаккый. Ничек?

Абдул. Күрәсеңме?

Хаккый. Нәрсәне?

Абдул. Кара урамга! Малайлар ташып өлгерә алмыйлар. Исерекләр машинага сыймый. Чират! Бер чакрым!

Хаккый. Ни булган бу халыкка?

Абдул. Париждан килгән Жан Дустэн бөтен шәһәрне аяктан екты.

Хаккый. Кем соң ул Жан?

Абдул. Белмәмешкә салышкан буласың. Яшермә, канәтем. Күрдем бит... Жан Дустэн курсларыннан чыкканыңны. «Парижга баргач үзеңне ничек тотарга?»

Хаккый. Ярар инде. Мин дә сине күрдем. Син салгансың... Тәки ычкындың.

Абдул. Парижга барам, Хаккый, бармыйча калмыйм!

Хаккый. Мин дә сала башладым. Өмет уятты ул каһәр суккыры!

Абдул. Бонжур! Үзебез генә белик! Болай булса, Париж безнеке!

Хаккый. Алла бирсә, Париж урамнарыннан бер җырлап узабыз!

Чакырдым кый, килмәдең кый.

Җаннарымны кыйдың кый! О' кей, Хаккый!

Абдул. Утыр урыныңа! Кабул итә башлыйбыз! *(Ишеккә бара.)* Чират тәртибендә кертегез! Кабаланмагыз! Берәм-берәм! Француз?! Иң беренче булып кертегез! Кадерле кунакны кабул итегез!

Жан *(керә)*. Мин кайда?

Абдул. Рәхим итегез, хөрмәтле кунагыбыз! Сез айныткычта!

Жан. Ай-ныт-кыч? Пардон!

Абдул. Мерси!

Жан. Бу нәрсә? Мин беренче тапкыр.

Абдул. Беренче тапкыр аяк басуыгыз белән котларга рөхсәт итегез, Жан әфәнде. Бу — безнең өчен зур дәрәҗә, Жан әфәнде!

Жан. Сез мине беләсез? Ничек?

Абдул. Телевидение... Аннан соң без сезнең курсларда булдык...

Жан. Минем курсларда? Әһә... Парижга бару? Сез алкоголь яратасыз, шулаймы?

Абдул. Яратам!

Хаккый. Мин аннан башка яши алмыйм.

Жан. Мин кайда икәнемне белмим. Налог? Полиция? Ни белән шөгыльләнә бу фирма?

Абдул. Бизнес!

Жан. Бизнес? О! Бизнес нинди?

Абдул. Сезнең кебек үк, исерекләрне дәвалыйбыз.

Жан. Төшенмим.

Абдул. Сез безне дәвалыйсыз, без — сезне.

Жан. Ничек?

Абдул. Безне Парижга алып китәсе төркемгә кертәсез.

Жан. Алкашлар төркеменә? Сез бит полиция!

Абдул. Без монда — полиция. Парижда без — сезнең авыру. Сез хәзер бездә йоклап чыгасыз. Без сезгә йокларга урын тәкъдим итәбез. Рәхим итегез!

Жан. Йокларга? Пардон! Мерси! Бушлай?

Абдул. Бизнес! Чишенегез!

Жан. Сез мине чишендерергә уйлыйсыз?

Хаккый. Кыйммәтле әйберләрегезне, акчаларыгызны тапшырыгыз. Рәхим итегез!

Жан. Юк, юк, мин йокламыйм.

Абдул. Ярый, йокламагыз. Кадерле кунакка хөрмәт! Әмма монда кергән һәрбер клиент акча түли.

Ж а н. Акча?

А б д у л. Бизнес!

Ж а н. Күпме?

Х а к к ы й. Ун франк!

А б д у л. Сез — кунак. Биш франк!

Ж а н. Мәгез, бизнесмен әфәнделәр, биш франк. Парижга барасыгыз киләме? Күрсәтәм мин сезгә Парижны, күрсәтәм! Инде мине һотельгә илтеп куясыз.

А б д у л. Илтәбез, әмма сездән франк алмыйбыз. Бушлай. Әмма безнең икебезне Парижга барасы төркемгә кертәсез.

Ж а н. Миңа кирәк документ. Булса, алып китәбез.

А б д у л. Документ була. Табабыз!

Ж а н. Бул сау! Рәхмәт.

А б д у л. Мерси! Безне онытмагыз. Килгән саен кергәләп йөрегез! Хушыгыз, Жан Дустэн әфәнде! Бонжур, месье! Егетләр, хөрмәтләп озатыгыз!

Жан Дустэнны озаталар.

Болай булса, «мерседес»ны Польшадан түгел, Франциядән алып кайтабыз, канәтем! *(Франкны тотып.)* Менә ул җанашым франк! Бизнес шулай башлана. Мая!

Х а к к ы й. Ничек эләктердең бу акуланы?

А б д у л. Хәйлә кирәк, хәйлә! Малайларга әйтеп куйдым. Барып алдылар.

Х а к к ы й. Ну, малай, чи мишәрсең икән!

А б д у л. Бер-береңне таламыйча бизнес ясап булмый. Без әле, Хаккый канәтем, кыргый базарны үзебезгә ияләштерербез. Әйтте диярсең.

Х а к к ы й. Ай-һай, булыр микән?

А б д у л. Булмый карасын!

Х а к к ы й. Нишләмәкче буласың?

А б д у л. АО «Хуш, Хәйбуш». Хуҗасы — Абдул Айнетдинов!

Х а к к ы й. Ә мин?

А б д у л. Син — уң кулым.

Х а к к ы й. Синең белән коммунизмга да, капитализмга да барырга була!

А б д у л. Сәрхушләр генә исән булсын! *(Сәхнә артында шау-шу.)* Иптәшләр, чиратка басыгыз!

Х а к к ы й. Генерал!

А б д у л. Чит ил кешеләренә, генералларга ташлама

ясыйбыз! Генералны чиратсыз! Әйттем бит үзебезнең айныткычны бөтен дөньяга танытабыз дип! Әйдә, генералны үзебез язган «Алкашлар маршы» белән каршылыйбыз!

Атлый-атлый җырлыйлар.

Татарның җене,
Русның чорты без,
Айныткычыбыз —
Туган йортыбыз!
Салган булсаң да,
Аума син, аума,
Айныткыч алда,
Алга, гел алга!

Маршны генерал формасы кигән, танымаслык итеп грим салган, сакал-мыек ябыштырган Шакир булә.

Шакир. Алга, генерал! Кем язды бу маршны? *(Абдулга.)* Син?

Абдул. Без яздык, иптәш...

Шакир. Галиҗәнап генерал! Үрә кат! Кабатла!

Абдул. Без яздык, галиҗәнап генерал!

Шакир. Исемең?

Абдул. Айнутдинов! Абдул!

Хаккый. Хаккый Фәтхрахманов!

Абдул. Сорарга рөхсәт итегез!

Шакир. Рөхсәт.

Абдул. «Хуш, Хәйбуш» айныткычына килеп безне бәхетле иткән генерал, ягъни сез кем буласыз?

Шакир. Генерал Шаке Кәлтрифунович Буш Хәйбуловский! Исерекләрне айнытырлык марш язуыгыз өчен сез минем исемнән, хуш... ие... медаль белән бүләкләнәсез! Икегезгә бер медаль! Петр патша эчкечеләргә «исерек» дип язылган шушы бер потлы медальне тактырган. Котлыйм, бөркетләр! *(Абдулның муенына тага.)*

Абдул. Аның тәҗрибәсе зуррак. *(Хаккыйга тага.)*

Шакир. Ошбу медальне айныткычта беренче булып кулланыгыз. Әле генә президентка кереп чыктым. Медальне указ белән раслауны сорап. Моны исереккә таксаң, оялудан шундук салуны ташлар, дидем. «Хәл итәрбез, генерал!» дип вәгъдә бирә калды... Минем люкс бушмы?

Абдул. Нинди люкс?

Ш а к и р. Нинди булсын, хуш, Хәй... Инструкция буенча кабул итегез! *(Утыра.)* Чишендер! *(Абдул папахасын, Хаккый шинелен салдыра. Шакир галифеен үзе сала, трусиктан гына кала.)* Кесәдән акча эзләп тормагыз, сукыр бер тиен дә юк.

Х а к к ы й. Тәнендә эзләр, яралар юк.

А б д у л. Исемегез?

Ш а к и р. Ничек булсын... *(Сакал-мыегын ала.)* Хуш, Хәйбуш!

А б д у л. Шакир абый?!

Х а к к ы й. Син?!

Ш а к и р. Сизгерлек җитми, җегетләр!

А б д у л. Каян синдә мондый форма?

Ш а к и р. Кичә цирк белән исәп-хисапны өздем.

А б д у л. Цирктан киттеңмени?

Ш а к и р. Кудылар. Клоун кирәкми аларга.

Х а к к ы й. Әйбәт булган. Синең тамашачыларың монда киләчәк. Шуннан?

Ш а к и р. Бераз төшереп алгач, хәрбиләр кибетенә кергәнмен дә шушыларны сатып алганмын. Хуш, Хәйбуш! Киткәнмен урам буйлап, үз-үземә команда биреп: «Алга, Шакир абый!» Аннары туган йортка, сезгә килеп кердем... И, җегетләр, эчмәс җиреңнән эчәрсең. Ни туган йорт, ни туган ил юк... Бөтен ил айныткычка әйләнде. Кызык бетте тормышта. Элек әле киләчәккә өмет яшәтә иде. Хуш, Хәйбуш! Генералларга гына әз-мәз хөрмәт калды. Бер кадер күрәсе килгән ие генерал булып...

А б д у л. Кереп ят үз урыныңа! Бар, бар, генерал Хуш, Хәйбулловский! *(Төрткәләп озаталар.)*

Х а к к ы й. Ну, малай, шәп урнашып калдык. Әнә Хуш-Хәйбулларны куалар.

А б д у л. Ярый әле яшьлек җүләрлеге белән галим булып җитмәдек. Йөрер идек ач пират булып, ачка койрык чәнчеп...

Х а к к ы й. Дөньяның тоткасы милиция! Акча җәлләмиләр!

А б д у л. Һәрбер адәмне милиционер яки генерал итмичә торып, тормыш рәтләнмәячәк. Әйтте диярсең!

Тышта шау-шу.

Кем тавышлана анда?

Сәнифә *(килеп керә)*. Нахал! Тотма мине!

Абдул. Утыр!

Сәнифә. Утырыгыз!

Абдул. Утырыгыз, зинһар!

Сәнифә. Утырмыйм.

Абдул. Үтенәм, мадам, утырыгызчы!

Сәнифә. Җитәр инде, күп утырттыгыз төп башына. Мин беләм ирләрне.

Абдул. Фамилиягез?

Сәнифә. Минем кем булуымда синең ни эшең бар?

Абдул. Үзегез матур гына кыяфәтле. Кем белән эчтегез?

Сәнифә. Әй, эчәбез, эчәбез,
Эчтек бүген, кичә без,
Шакир дуста эчкән идек,
Шунда калган шешәбез!

Хаккый. Чишен!

Сәнифә. Ә? Нәрсә?

Хаккый. Плащыңны гына.

Сәнифә. Юк инде... күп чишендерделәр. Беркөнне урамда пальтомны таладылар. Алкалар, балдаклар юк... сатып эчтем...

Хаккый. Яраланган, кагылган-сугылган урыннарыгыз юкмы, карыйк...

Сәнифә. Минем бөтен җаным яраланган, кагылган-сугылган... *(Бик моңлы итеп җырлап җибәрә.)*

Чит җирләргә киткән кошлар сыман,
Ак болытлар ага еракка.
Үз-үземне тыеп кына торам,
Китәр идем мин дә шул якка.
Ак болытны юлдаш итәр идем,
Хәлләремне алар аңласа,
Шул болытлар белән китәр идем,
Туган-үскән җирләр калмаса.
Баш очымда ак болытлар йөри:
Яңгыр микән, әллә кар микән?
Җанны яралаучы күп дөньяда
Җанны дәвалаучы бар микән?

Абдул *(таныып)*. Сәнифә апа...

Хаккый. Сәнифә апа, сез?

Абдул. Сез... нишләдегез?

Хаккый. Безне җырларга...

Абдул. Биергә өйрәткән... Сәнифә апа. Сез, шәһәрдәге иң айнык кеше, нишләдегез?

Сәнифә. Мин сезне танымыйм. Танырга да теләмим. Элекке Сәнифә апа мин.

Хаккый. Сез дә шул хәлгә төшкәч, безгә ни кала?

Сәнифә. Бу хатын гомерендә бер тапкыр айныткычка эләккән. Урнаштырыгыз аны!

Абдул. Сәнифә апа, әйдәгез, өегезгә илтеп куябыз.

Сәнифә. Мине? Ах, сез миннән җиңел генә котылмакчы буласызмы? Юк, мин монда кунам.

Абдул. Инструкция буенча, сез түләргә тиеш буласыз.

Сәнифә. Миндә акча бер букча! *(Өстәлгә ыргыта.)* Калдык кирәкми! Квитанция! Кунган өчен дә!

Хаккый. Эш урыныгызга кәгазь китәчәк.

Сәнифә. Эш — тю-тю! Кәгазен үземә!

Абдул белән Хаккый бер-берсенә карашып торалар.

Абдул. Ярар, сезнеңчә булсын. Кәгазен чыкканда алырсыз. Әйдәгез! *(Хаккыйга.)* Ля Париж?

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Таминдар фатиры.

Таминдар *(телефонда)*. Һалло! Кем бу? Дежур милиционер? Абдул Айнутдинов? Студент чакта циркка сәхнә эшчесе итеп алган идем. Хәтерләдем. Сәнифә апа сәлам әйтте? Борчылмаска кушты? Айныткычта? Мәхшәр! *(Әкрен.)* Абдул иптәш-әфәнде, ярдәм итегез, өйгә бер кыз басып керде. Коткара күрегез. Килеп куркытсагыз, чыгып китәр иде. Көтәм. *(Номер җыя.)* Тайфур дустым, күршем! Мәхшәр! Бер кыз басып керде. Минемчә, ул ычкынган. Зинһар, килеп, тиешле урынга озат. Минем эш түгел? Коткар, күрше! Син бит доктор. Көтәм. Ул әле кибеткә чыкты. *(Маңгай тирен сөртә.)*

Шакир керә.

Ш а к и р. Хуш, Хәйбуш!

Т а м и н д а р. Хуш, хуш... *(Төртеп чыгарырга уйлый.)*

Ш а к и р. Минем партнерша кайтмадымыни әле?

Т а м и н д а р. Нинди партнерша?

Ш а к и р. Мин бүген синең хатының белән кундым.

Т а м и н д а р. Кундың?

Ш а к и р. Хуш, Хәйбуш!

Т а м и н д а р. Сәнифә белән?

Ш а к и р. Кем белән булсын, синең хатының бер генә ич.

Т а м и н д а р. Кайда?

Ш а к и р. Айныткычта.

Т а м и н д а р. Икегез бергә?

Ш а к и р. Керүен аерым-аерым кергәнбез, аерым бүлмәләрдә йоклаганбыз. «Иртәрәк чыксаң, Таминдарга сәлам әйтә тор» диде. Әманәтен үтим.

Т а м и н д а р. Шакир әфәнде, утыр әле, киңәшләшик.

Ш а к и р. Минем үземә киңәш кирәк.

Т а м и н д а р. Әйт, нишләргә? Миңа бер кыз басып керде.

Ш а к и р. Менә минем бер баҗам бар, ул...

Т а м и н д а р. Икенче хатының булып килдем ди.

Ш а к и р. Үз аягы белән басып кердеме?

Т а м и н д а р. Үз аягы белән.

Ш а к и р. Картмы?

Т а м и н д а р. Яшь шул.

Ш а к и р. Ямьсезме?

Т а м и н д а р. Чибәр шул, каһәр суккыры!

Ш а к и р. Соң?

Т а м и н д а р. Минем хәлдә калсаң, нишләр идең?

Ш а к и р. Минме? Мин, энекәш, әйтер идем: Хуш, Хәйбуш!

Т а м и н д а р. Минем хатыным бар. Никахлы булмаса да...

Ш а к и р. Исең киткән иске чикмәнгә. Хәзер эте-бете законлы хатын белән яшәп яткан була. Законсыз хатыннан шәбе юк аның, энекәш. Сәнифәне куып чыгарырга ниятлиме әллә? Хуш, Хәйбуш!

Т а м и н д а р. Юк шул. Сәнифә апаны ихтирам итәчәкмен ди.

Ш а к и р. Язмыш бүләге бу! Әлбәттә, киләчәктә ул си-

нең үзеңне дә куып чыгарырга мөмкин, мине куып чыгарган кебек, әмма анысы вак мәсьәлә.

Таминдар. Зуррак мәсьәләгә күч.

Шакир. Таминдар, синнән бәхилләшү акчасы алгач, кәефләнеп, генерал киеме сатып алганмын да урамда йөргәнмен. Хуш, Хәйбуш! Кибеттә кире алмыйлар, шуны сатып алмассыңмы?

Таминдар. Кит әле, аның кайгысымы миндә?

Шакир. Ярты бәясенә бирәм.

Таминдар. Нигә кирәк ул миңа?

Шакир. Киттем алайса. Хуш, Хәйбуш! Миннән хатыннарың санынча сәлам!

Таминдар. Тукта, Шакир әфәнде, ярдәм итсәң, шинелеңне алам.

Шакир. Шартың?

Таминдар. Сәнифә кайтып җәнҗал куптарганчы, теге кызны куып чыгарырга ярдәм ит.

Шакир. Хуш?

Таминдар. Син Сәнифәнең яңа гына кайтып төшкән генерал җизнәсе буласың.

Шакир. Хуш.

Таминдар. Бар, бүлмәгә кереп киен. Теге кайтып керү белән, зәһәрләнеп чыгарсың. Тыңла, үтә!

Шакир. Алга, Шакир абый! *(Кереп китә.)*

Таминдар. Котылам болай булгач... Таминдарны тиз генә эләктерә алмассыз...

Талия керә. Кулында сумка.

Талия. Таминдарым, уяндыңмы?

Таминдар. Йокламадым.

Талия. Сәнифә көндәш кайтмадымы әле?

Таминдар. Кайтмавын гына теләп тор инде. Кайтса...

Талия. Мин аңардан курыкмыйм, әйбәт апа ул.

Таминдар. Кайтсамы... кайтса... О... О!..

Талия. Нишләтә?

Таминдар. Чәчләреңне йолка!

Талия. Шушы кап-кара толымнарымнымы? Ышанмыйм.

Таминдар. Аның куллары! Тәрәзәдән атып бәрә. Башта сине, аннары мине!

Т а л и я *(җырлап)*. Без барыбер бергә булырбыз! Мин Сәнифә апаны андый мәрхәмәтсез итеп күз алдына китерә алмыйм. *(Җырлый-җырлый табын әзерли.)* Мин сине яратам, яратам, барыбер үземә каратам.

Т а м и н д а р. Сәнифәнең бик усал җизнәсе — генерал кайтып төште әле генә. Теге бүлмәдә.

Т а л и я. Шулаймыни? Искиткеч! Кунак итәрбез!

Т а м и н д а р. Сез... кеше өендә нишләргә уйлыйсыз?

Т а л и я. Сәнифә апаны табын әзерләп каршылыйм. Бу вакыйганы билгеләп үтәрбез.

Т а м и н д а р. Нинди вакыйганы?

Т а л и я. Минем сезгә килү бәйрәм түгелмени?

Т а м и н д а р. Кайтып кына керсен... күрсәтер ул сиңа бәйрәмне... миңа да!

Т а л и я. Хәзер без өчебез бер гаилә. Сәнифә апаның алъяпкычы бармы? Әлегә икебезгә бер булыр. *(Алъяпкыч алып бәйли.)*

Т а м и н д а р. Бәлки, «карават та икебезгә бер булыр» диярсез?

Т а л и я. Өчебезгә!

Т а м и н д а р. Талия, сеңел, хур итмә мине хатын алдында, абруемны төшермә!

Т а л и я. Сезнеке күтәреләчәк кенә! Нидән куркасың, Таминдар абый?

Т а м и н д а р. «Ике хатын белән тора» дип бөтен дөнья шаулар!

Т а л и я. Аның ние бар! Коръән дә каршы килми. Әгәр матди яктан хәле бар икән, хәтта җиде хатын белән яшәргә рөхсәт ителә.

Т а м и н д а р. Бәлки минем хәлемнән килмидер, каян беләсез?

Т а л и я. Минем хәлемнән килә, Таминдар абый. Нигә безгә бабаларыбыздан үрнәк алмаска?

Т а м и н д а р. Ә Сәнифә?

Т а л и я. Без — ике хатын янәшә тыныч яшәрбез. Борчылма, сөеклем... *(Янына барып утыра, иркәләмәкче була.)*

Ш а к и р керә. Генерал киемендә.

Ш а к и р. Ни бу? Минем баҗам күз алдымда чит кызлардан иркәләтеп утыра. Хуш... Тор! Үрә кат! *(Икесе дә*

*сикереп торалар.)* Генерал Шаке Кәлтрифунович Бушхәйбуловский! *(Таминдарга.)* Хәзер үк аңлатма яз!

Т а м и н д а р. Телдән әйтергә рөхсәт итегез!

Ш а к и р. Рөхсәт.

Т а м и н д а р. Шушы кыз минем өемә басып керде.

Ш а к и р. Ничек басып керде?

Т а м и н д а р. Икенче хатының булам ди...

Ш а к и р. Шушымы? *(Карап.)* Бик яшь бит бу!

Т а л и я. Үсә-үсә картаям мин, генерал җизни.

Ш а к и р. Минем баҗамнан да — шушы хөрәсәннән дә җүнлерәк кияү табалмадыңмы, ахмак кыз? Хуш, Хәйбуш!

Т а л и я. Язмышым шулдыр. Генерал җизни, аңлагыз хәлемне, бирегез фатихагызны. Без өчәүләп бик тату яшәрбез.

Ш а к и р. Фатиха бирә алмыйм. Хуш, Хәйбуш! Ычкын! Хуш...

Т а л и я. Җизни, мин сез килүгә бик һәйбәт табын әзерләдем. Рәхим итегез, җизнәкәем! *(Өстәлгә шәраб куя.)*

Ш а к и р *(Таминдарга)*. Нәрсә багана кебек катып калдың? Утыр!

Т а м и н д а р. Юк, юк, мин...

Ш а к и р. Утырырга! *(Утырта.)*

Т а л и я *(бокалларга сала)*. Тотыгыз, җизни! Мин бик шат!

Ш а к и р. Менә минем баҗам бар — армиягә дә алмадылар. Таминдарның беренче хатыны өчен! *(Эчә.)* Сал! Таминдарның икенче хатыны өчен!

Т а л и я. Димәк, сездән фатиха, җизни?

Ш а к и р *(үзе салып)*. Өченче хатыны өчен дә алдан эчеп куйыйк! *(Таминдарга.)* Син бөтенләй җебеп төштең. Ай-һай, ничек яшәр бу ике хатын белән!

Т а л и я. Рәхмәт, генерал җизни!

Ш а к и р. Миннән фатиха! Хуш, Хәйбуш! Ике хатыныңның да рәхәтен күр, баҗа! Алга, Шакир абый! *(Чыга.)*

Т а л и я. Таминдар абый, тагын шундый бер җизни юкмы?

Т а м и н д а р *(ачулы)*. Мәхшәр! Монысы да бик җиткән!

Талия тәрәзә пәрдәсен төшерә.

Нишлисең син?

Т а л и я. Карап тормасыннар...

Т а м и н д а р. Күтәр пәрдәне, әллә ни уйларлар.

Т а л и я. Уйласыннар... Мин синең качып-посып сөя торган сөяркәң түгел, хатының.

Т а м и н д а р. Законсыз!

Т а л и я. Законсыз хатының булырга да ризамын. Йөрәк законга буйсынмый. *(Таминдарга якыная.)* Икебезгә генә калырга һич тә ирек бирмиләр...

Т а м и н д а р. Ярый... Алай булса әз генә чигенәм. Болай мине хур итмә. Әйдә болай итик, син минем беркем дә белми торган сөяркәм генә бул.

Т а л и я. Сез мине кем дип беләсез? Юк, юк, бары тик хатыныгыз!

Ишектә кыңгырау.

Үзем ачам. Рәхим итегез!

А б д у л. Милиция өлкән лейтенанты Айнутдинов! *(Арты белән басып торган Талиягә карап.)* Хатыныгыз өйдәмени, Таминдар әфәнде?

Т а м и н д а р. Өйдә юк шул.

Т а л и я. Өйдә!

А б д у л. Хатыныгыз ничектер икенче кешегә охшаган дип әйтимме?

Т а л и я. Әлегә фамилияне үзгәртергә өлгермәдем. Анысы кечкенә мәсьәлә. *(Кулын биреп.)* Талия Хәбиб!

Т а м и н д а р. Юк, юк!

А б д у л. Сез беренче хатыныгыз белән яшәмисезмени инде? Аңладым, канәтем, алкашка белән яшәгәнче, эчми торган шушы яшь бикә белән яшәвең — мең артык!

Т а м и н д а р. Өлкән лейтенант, ышанмагыз, аферистка бу, хатыным өстеннән килде. Мин Сәнифәне аермадым.

Т а л и я. Мин дә Таминдар абыйны да, Сәнифә апаны да яратам. Без бик тату яшәрбез.

Т а м и н д а р. Коткарыгыз! Сәнифә кайтканчы моны куып чыгарыгыз! Протокол төзүне таләп итәм!

А б д у л. Минем ярдәм итүемне теләсәң, сиңа шул киңәшем... Син моны башта исерт, аннары безгә шалтырат, шуннан соң без аны машинага салып, айныткычка, беренче хатының янына илтеп аударырбыз.

Т а м и н д а р. Тукта әле, тукта...

Т а л и я. Туктама, туктама...

А б д у л. Аңла, мин айнык кешене алып китә алмыйм. Бигайбә, инструкцияне боза алмыйм. Хатын алганда, бигрәк тә икенчесен, аеруча сак булу сорала. Пардон! *(Чыга.)*

Т а л и я. Юк, Таминдар абый, безне бернинди көч тә аера алмый хәзер!

Ишектә кыңгырау.

Т а м и н д а р. Дуслар килер, мине азат итәр...

Т а й ф у р керә.

Т а й ф у р *(кулындагы газетаны өстәлгә салып)*. Укыдыңмы?

Т а м и н д а р. Берни дә белмим. Каяле... *(Укый.)* «Шәһәребезнең мәгълүм цирк директоры Таминдар Хәбибнең хатыны эчә башлаган. Шуңа җавап итеп, ул икенче хатын алып кайткан. Бу кыю адымны бабаларының гадәтләрен оныткан башка татарларның да күтәреп алуларына шик юк». Мәхшәр! Ялган! Провокация! Мин аны алып кайтмадым. Ул үзе килеп керде! Доктор, карагыз, зинһар...

Т а й ф у р. Шушымы?

Т а м и н д а р. Шушы.

Т а л и я. Исәнмесез, доктор? Сәламәтлегегез ничек?

Т а й ф у р. Рәхмәт. Әйбәт. Тыңлыйм сезне. Нидән зарланасыз?

Т а л и я. Аллага шөкер. Тап-тазамын. Берни дә борчымый.

Т а й ф у р. Хуҗагыз сезнең сәламәтлек өчен борчыла. Без тикшереп карарга булдык. Әлбәттә, үзегез риза булсагыз...

Т а л и я. Мин каршы түгел.

Т а й ф у р. Мин наркология белгече. Шулай да... күрше үтенгәч...

Т а м и н д а р. Доктор доктор инде...

Т а й ф у р. Авызыгызны ачыгыз әле, туташ.

Т а л и я. Күпме ачыйм?

Т а й ф у р. Ача алган кадәр.

Т а л и я. Ачтым.

Т а й ф у р. «А!» дип әйтегез.

Т а л и я. А-а-Аллага шөкер!

Т а й ф у р. Тешләрегезне күрсәтегез. Тәк... ие...

Т а л и я. Авызым уймак кадәр генә, табиб әфәнде. Барысы да күренмәс.

Т а й ф у р. Күренгәне дә бик җитә. *(Карап.)* Таман гына.

Т а м и н д а р. Акылга таманмы?

Т а й ф у р. Үтә матур, үтә зәһәр!

Т а м и н д а р. Нинди мәгънәдә?

Т а й ф у р. Тешләгән җирдән өзми куймый бу туташ.

Т а м и н д а р. Сез аның баш ягын тикшерегез.

Т а й ф у р *(чүкеч ала)*. Тезегезне тез өстенә куегызчы.

Т а л и я . Куйдым.

Т а м и н д а р. Мин әйттем... башын...

Т а й ф у р. Комачауламагыз. *(Чүкеч белән Талиянең тез өстенә суга.)*

Т а л и я. Нишлисез?! *(Аягы белән чүкечне бәреп төшерә.)*

Т а м и н д а р. Әйттем бит, котырган! Йә, ничек?

Т а й ф у р. Баш куям тезләреңә,
Яшь коям эзләреңә,
Әллә ниләр бирер идем
«Ах!» дигән сүзләреңә... дигән җырны ишеткәнегез бармы?

Т а м и н д а р. Аның монда ни катнашы бар?

Т а й ф у р. Әнә шул җыр кебек!

Т а м и н д а р. Анысын мин үзем дә күреп торам.

Т а й ф у р. Хәзер инде күзләрегезне тутырып, туп-туры менә монда... миңа карагыз. Миңа дим... тәк... ие...

Т а л и я. Карыйм ич.

Т а й ф у р. Карый алмый... Тәк... ие...

Т а м и н д а р. Шикле?

Т а й ф у р. Әйтүе дә уңайсыз...

Т а м и н д а р. Ниһаять!

Т а й ф у р. Аның күз карашы... коточкыч!

Т а м и н д а р. Әйттем бит! *(Телефон трубкасын суза.)* Чакырыгыз!

Т а й ф у р. Күз карашы... коточкыч матур. Башкага карый алмый. Бары тик сиңа гына төбәлгән.

Т а м и н д а р. Сез аның күз карашын түгел, күзләрен карагыз!

Т а й ф у р *(күзләрен карап)*. Зәңгәр күк сыман болытсыз, аяз... Тирән күл сыман серле... шомлы...

Т а м и н д а р. Акыл ягы... сай?

Т а й ф у р. Син хаклы. Саерак.

Т а м и н д а р. Әйттем бит!

Т а й ф у р. Әмма...

Т а м и н д а р. Нәрсә әмма?

Т а й ф у р. Акылына караганда хисләре тирәнрәк. Мондый сихри күзләр өчен ханнар ярты патшалыкларын биргәннәр. Котлыйм, гүзәлкәй, сез искиткеч нәфис булу өстенә, сау-сәламәт тә! Киявегез дә үзегезгә лаек.

Т а л и я. Эчмим, тартмыйм, чит ирләр белән йөрмим.

Т а м и н д а р. Лаек түгел! Түгел!

Т а й ф у р. Миңа калса, бу гүзәл кыз икенчегә түгел, беренче хатынлыкка шәп булган.

Т а л и я. Әнә... вакытында алмады бит.

Т а й ф у р. Соң булганчы, уң булсын! Киттем, сәрхушләрем көтәдер. *(Чыга.)*

Т а л и я. Таминдар абый, туганнарыгыздан, дус-ишләрегездән, рәсми органнардан ризалык алдык. Син — минеке!

Т а м и н д а р. Талия, нигә сорамыйсыз, мин сезне яратаммы соң?

Т а л и я. Беренче хатыныгыз яратамы?

Т а м и н д а р. Кем белә аны? Яратадыр...

Т а л и я. Сез аны яратасызмы?

Т а м и н д а р. Кем белә аны? Яратамдыр...

Т а л и я. Бер гаиләгә бер ярату бик җиткән. *(Көзге алдына килә.)* Таминдар абый, дөресен әйтегез, мин матур бит, әйеме? Карагыз инде бу гәүдәмне, күп ирләр мине төшләрендә дә күрмиләр. Мине яратмау мөмкин түгел! Әйт инде, матурмы мин?

Т а м и н д а р. Матурлык — туйда кирәк.

Т а л и я. Туйга махсус күлмәк тектем.

Т а м и н д а р. Кайтып кына кермәсен, күрсәтер ул туйны!

Т а л и я. Беренче хатының туйның түрендә — синең уң кулыңда утырыр. Икенчесе... Туйда «Әче!» дип кычкыргач, без ничек үбешербез икән? Әйдә, репитиция ясыйбыз! *(Үпмәкче була.)*

Т а м и н д а р. Җибәр! Кычкырам! Күршеләрне чакырам!

Сәнифә керә. Икесе дә катып калалар. Таминдар битенә буялган иннек табын сөртә.

Мин түгел... ул үзе... *(Ялагайланып.)* Сәнифә, кайттыңмыни?

Сәнифә. Минем ирем бармы, юкмы?

Таминдар. Бар, Сәнифә, бар!

Сәнифә. Кем ул?

Таминдар. Мин.

Сәнифә. Булса, нигә ул үзенең хатынын айныткычтан килеп алмый?

Таминдар. Җибәрми.

Сәнифә. Кем?

Таминдар. Менә бу!

Сәнифә. Кем бу?

Таминдар. Үзеннән сора.

Талия. Сәнифә апа, исәнмесез. Тормышыгызны җиңеләйтү нияте белән, мин Таминдар абыйга икенче хатын булып килгән идем.

Сәнифә. Син? Икенче хатын булып?

Талия. Әйе.

Таминдар. Мин риза түгел. Ул үзе...

Сәнифә. Синнән сорамыйлар! Тик тор! Өйне син җыештырдыңмы?

Талия. Мин. *(Урындыкны өреп.)* Утырыгыз.

Сәнифә. Моның... бу мәхлукның гомергә үтүк күрмәгән чалбарын да син үтүкләдеңме?

Талия. Тишек оегын да ямап, юып куйдым. Ашарга әзер. Өчпочмак. Китеримме? Җаныгыз ни тели? Башта әз генә ял итеп алыгыз. Әллә ваннага кертеп юындырып алыйммы?

Сәнифә. Үтереп баш авырта... махмыр...

Талия. Менә моны кабып җибәрегез, Сәнифә апакаем.

Сәнифә. Икенче хатын алып кайттым диген, ә?! Беренче хатынның баласы юк, диген, ә?!

Таминдар. Мин алып кайтмадым!

Сәнифә. Тәки алып кайттың, ә? *(Каршына бара.)*

Таминдар. Сәнифә... җаным... аңла... мин... мин...

Сәнифә. Өйгә бер тәүлек кенә кайтмый тордым... син...

Таминдар. Сәнифә кадерлем, үтенәм, тавыш чыгарма. Мине теләсә нишләт, аңа кагыла күрмә... кулларың...

С ә н и ф ә. Син әле аны яклап маташасыңмы?

Т а м и н д а р. Юк, юк, якламыйм...

С ә н и ф ә. Сеңелем, кил әле монда.

Т а м и н д а р. Тия күрмә...

С ә н и ф ә. Чәчләрең озын икән...

Т а м и н д а р. Саклан, умыра!

С ә н и ф ә. Кил әле якынрак.

Т а л и я. Мин куркам.

С ә н и ф ә *(кочаклап)*. Хыялым тормышка ашты, сеңлем. Иремә икенче хатынлыкка миңа көндәшкә килеп бик дөрес эшләгәнсең. Күпме көттем... *(Күз яшьләрен сөртә.)* Ул үзе дә яшь хатын алып кайтырга бик теләгән иде. Урамга чыгып бер сызгырсам, йөз хатын йөгереп килә миңа дигән иде. Сызгыруын ишеткәнсеңдер инде, шулаймы?

Т а л и я. Мин сызгырганны да көтеп тормадым, килдем.

Т а м и н д а р. Сәнифә, мин бит юри генә әйттем, чынга алдыңмы?

С ә н и ф ә. Минем ирем көчле, сеңлем, шикләнмә, ике хатынны асрарлык!

Т а л и я. Без икебез бер хатын кебек яшәрбез, Сәнифә апа.

С ә н и ф ә. Безнең кебек хатыннарга кәтүк кебек кенә бер ирне карау вак мәсьәлә.

Т а м и н д а р. Сәнифә, акылыңа кил, айны!

Т а л и я. Сез мине үз гаиләгезгә кабул иттегез дип аңларга ярыймы?

С ә н и ф ә. Ярый. Тик бер шарт белән! Син картаймыйча торып, Таминдарга өченче хатын алып кайтуны тыябыз. Мактыйм, Таминдар, хатынның...

Т а л и я. Кызның...

С ә н и ф ә. Шәбен тапкансың.

Т а м и н д а р. Мин тапмадым. Ул үзе!

С ә н и ф ә. Бигрәкләр дә әйбәт. Хатын-кызны магнит кебек тарту көче бар синдә. Мине дә тарттың бит яшь чакта.

Т а м и н д а р. Сәнифә, нишлисең син, нигә көләсең иреңнән! Мин сезне аңладым, сез юри шаяртасыз. Әйт, шулаймы? Син бит эчмәдең? Айныткычка да эләкмәдең?

С ә н и ф ә *(рольдән китеп, «айнып»)*. Шаяртуны син үзең башладың: «урамга чыгып сызгырсам...»

Т а м и н д а р. Ачуны китергәнгә инде... Ә син?

С ә н и ф ә. Мин шаярырга мәҗбүр булдым.

Т а м и н д а р. Ни өчен?

С ә н и ф ә. Минем Парижны күрәсем килә.

Т а м и н д а р. Парижның ни катнашы бар?

С ә н и ф ә. Миңа ничек кенә булса да, Парижга барачак сәрхушләр төркеменә эләгергә кирәк, аңладыңмы?

Т а м и н д а р. Димәк, син эчкече түгел?!

С ә н и ф ә. Беренче сынауны син уңышлы үттең, Таминдар. Ышандым, син мине яшь чибәр кызларга да алыштырырга җыенмыйсың икән...

Т а м и н д а р. Алла сакласын!

С ә н и ф ә. Хәзер икенче сынауны башлыйбыз. Монысында инде синең дә артистлык сәләтең күренергә тиеш. Бу сынаудан мин дә, син дә...

Т а л и я. Мин дә...

С ә н и ф ә. Талия дә отарга тиеш. Бизнес! Шартнамә төзибез!

Т а м и н д а р. Аңламыйм.

С ә н и ф ә. Синең Финляндиягә барасың киләме?

Т а м и н д а р. Бик килә.

Т а л и я. Минем дә!

С ә н и ф ә. Талиянең дә Финляндиягә барасы килә. Минем анда барасым килми. Бары тик Париж! Төшендеңме?

Т а м и н д а р. Юк.

С ә н и ф ә. Мин — Парижга, сез Талия белән — Хельсинкига! Ирле-хатынлы булып. Чөнки сине бары тик хатын белән генә чакыралар.

Т а м и н д а р. Талия минем хатыным булып?

С ә н и ф ә. Вакытлыча гына... бөтенләйгә түгел...

Т а л и я *(җырлап)*. Син гашыйк бул миңа, вакытлыча гына булса да...

Т а м и н д а р. Мәхшәр! Нигә аны башта ук әйтмисез? Нигә башны катырасыз?

С ә н и ф ә. Димәк, син риза!

Т а м и н д а р. Риза булмаган кая! Син дигәндә мин, Сәнифәм, вакытлыча гына убырлы карчык белән яшәргә дә, дөнья читенә барырга да риза!

Т а л и я *(авызын ерып)*. Таминдар абый... *(Кочакламакчы була.)*

С ә н и ф ә. Шартнамә өч нөсхәдә. Рәхим итеп кул ку-

егыз. *(Таминдарга карап.)* Сиңа... Талиягә кагылмаска. *(Талиягә карап.)* Таминдарны Хельсинкидан саф килеш алып кайтырга... Үземә... Исән-сау Париждан кайта алсам, Таминдарга хыянәт итмәскә! Хуш, Хәйбуш!

Өчесе бергә. Хуш, Хәйбуш!

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче пәрдәдәге кафе-бар. Чит ил музыкасы уйный. Сәнифә белән Талия банкетка өстәл әзерлиләр.
Телевизордан соңгы хәбәрләр бирәләр.

Диктор. Француз наркологы Жан Дустән Гурье әфәнде шушы көннәрдә үзебезнең танылган психотерапевт Тайфур әфәнде Алтынбаев белән бергә, биш якташыбызны, яңа ысул белән дәвалау өчен, Парижга алып китәчәк.

Халык телендә «Хуш, Хәйбуш!» дип исем алган айныткыч, клиентларны кабул итү буенча, беренче урынга чыкты. Болай булгач, дөнья масштабына чыгарга да күп калмады.

Соңгы вакытта цирк тамашасына йөрүчеләрнең саны күпкә кимеде. Моны мәшһүр клоун Шакир Хәйбулловскийның штаттан кыскартылуы белән аңлаталар.

Сәнифә. Ишеттеңме, Талия, кандидатуралар бүген министрлыкта раслана. Шуларның берсе — мин!

Талия. Синең Парижга китүеңне миннән дә ных теләүче башка кеше юктыр, валлаһи!

Сәнифә. Беркем сүз әйтерлек түгел. Документлар тәртиптә!

Талия. Көнләшәм!

Сәнифә. Син дә хыялыңа ирешәсең.

Талия. Минем хыялым — печтик кенә. Берәр бай фин мишәре күз салмас микән?! Һич тә булмаса, үзебезнең Казан татары да ярап куяр иде.

Сәнифә. Миңа да берәр француз әфәндесе күз салмас мәле! Көнбатышта — ирекле мәхәббәт! Парижда торыр өчен берәр байның сөяркәсе булырга да ризамын!

Талия. Кара аны, кайтсаң, миңа косметика алып кайт!

Сәнифә. Кайтмасам да! Сәләви! Париж! Париж! Хы-

ялымда Эйфель манарасына менәм. Түбәсенә күтәреләм дә, бар дөньяны яңгыратып, җырлап җибәрәм:

Эйфель манарасы биек,
Шуңа менәсем килә,
Шунда менеп, түбән карап,
Сезне күрәсем килә!

Талия, Парижга шушы күлмәгемне киеп китсәм, килешер микән?

Т а л и я. Элекке совет кешеләрен гаеп итмәсләр әле. Синең өчен үземнән дә артык сөенәм, җаным. Сөенечтән җырлыйсы килә. Ә синең аякларың биергә әзер торалар.

Т а л и я. Тәти күлмәгеңне киеп
Кайларга китеп барыш?

С ә н и ф ә. Дөньядагы иң шөһрәтле
Өч шәһәр эзләп барыш!

Т а л и я. Һәр кеше белә аларны:

С ә н и ф ә. Париж!

Т а л и я. Малмыж, Мамадыш!
Минем нәфес бик бәләкәй,
Түгел байлыктан азмыш.

С ә н и ф ә. Мин барасы юллар ерак,
Кайсына ташлар язмыш?

Т а л и я. Мамадыш? Малмыж?

С ә н и ф ә. Париж!

С ә н и ф ә. Мадемуазель Сәнифә белән месье Жан Дустән менә монда утырачак.

Т а л и я. Ә җан дустың?

С ә н и ф ә. Кемне әйтәсең?

Т а л и я. Иребезне.

С ә н и ф ә. Уң ягымда — Жан Дустән, сул ягымда — җан дустым. Юк, Жан мине ялгыз мадам дип уйласын. Таминдар вакытлыча менә монда утырсын.

Т а л и я. Минем беләнме?

С ә н и ф ә. Минем белән дә түгел, синең белән дә түгел. Син — официантка, йөгереп йөрисең.

Т а л и я. Мин бүгеннән ял алдым. Хельсинки! Син чакырганга гына килдем.

С ә н и ф ә. Әйдә, бер сәгатькә түз инде. Жан Дустәнны сыйлау өчен Таминдар туйга бүләк иткән балдагымны саттым. Үзенә әйтмә!

Т а л и я. Син дигәндә, аяк идәндә, көндәшем-көндәшкәем.

С ә н и ф ә. Ой, йөрәгем леп-леп килә. Сәгать җиде!

А б д у л белән Х а к к ы й керә. Гади киемнән.

А б д у л. Мадамнарга сәлам!

Х а к к ы й. Ля Париж!

С ә н и ф ә. Сәлам, месье!

Х а к к ы й. Кунагыбыз кайда?

С ә н и ф ә. Көтәбез. Утырыгыз. Сез кунак түгел, хуҗа. Акчагыз түләнгән.

А б д у л *(бокалга сала)*. Ялган аракы түгелме? Юк. *(Эчә.)* Мамадыш! Үзебезнең фирма!

Х а к к ы й *(эчеп)*. Мамадыш!

С ә н и ф ә. Париж! Бары тик Париж!

А б д у л. Жан Дустэн хөрмәтенә!

С ә н и ф ә. Сабыр итегез, аның хөрмәтенә сөенечле хәбәр килгәч, үзе белән тост күтәрербез!

Т а м и н д а р *(керә)*. Мәхшәр! Мин әйттем...

Т а л и я. Таминдар абый... Кайчан китәбез?

Т а м и н д а р. Беркайчан да!

С ә н и ф ә. Финляндиягә кайчан китәсез?

Т а м и н д а р. Тоттырдылар Финляндияне!

С ә н и ф ә. Ничек тоттырдылар?

Т а м и н д а р. Кире уйлаганнар!

С ә н и ф ә. Харап кына булгансыз икән.

Т а л и я. Юк, Сәнифә апа, харап булмадык. Безнең тагын бер мөмкинлек бар иде.

С ә н и ф ә. Нинди?

Т а л и я. Фин юлы барып чыкмаса...

Т а м и н д а р. Татар юлы.

С ә н и ф ә. Нинди?

Т а м и н д а р. Син Парижга барып, французга кияүгә чыгасың...

Т а л и я. Мин үзебездә татарга кияүгә чыгам.

С ә н и ф ә. Кемгә?

Т а л и я. Синең элекке иреңә.

С ә н и ф ә. Уйнапмы?

Т а м и н д а р. Уйлап. Без Талия белән уйладык-уйладык та...

С ә н и ф ә. Ә шартнамә?

Т а м и н д а р. Шартнамә, ул ике яклы гына була ала, дигән карарга килдек.

Т а л и я. Үпкәләмә, Сәнифә апа, син безне үзең мәҗбүр иттең.

А б д у л,
Х а к к ы й } *(чәкешә-чәкешә эчеп, җырлыйлар).*
Үпкәләсәң, әйдә, үпкәлә...

С ә н и ф ә. Әй, бик кирәгегез бар ие! Эйфель манарасына менеп бер җырласам, йөз француз йөгереп килә миңа!

Ш а к и р керә.

Ш а к и р. Сезләргә соңгы сәламем!

С ә н и ф ә. Йөрмә әле монда эч пошырып, безнең кунак көткән чак!

Ш а к и р. Иптәш әфәнделәр, бер генә минутка, сөенечемне әйтергә генә кердем. Сал әле, Талия сеңелем... акчам бар...

А б д у л. Мескен, ул да сүләшкән була...

Х а к к ы й. Аңа тагын сөенеч...

Ш а к и р. Финляндиядән чакыру алдым. Хельсинкига клоуннар ярышына чакырганнар. Үзләре түли.

Т а м и н д а р. Кит аннан, булмаганны!

Ш а к и р. Без дә «әфәнде» булдык! Менә укы!

Т а м и н д а р *(укып)*. Мәхшәр! Барасыңмы?

Ш а к и р. Нишләп бармаска? Бушлай бит.

Т а м и н д а р. Париж хәтле Париждан баш тарттың, фингә сөенеп барасың.

Ш а к и р. Анда мин сәрхуш булып барырга тиеш идем. Финнәр талантымны хөрмәтләп чакыралар.

А б д у л. Хуп! Китүең хөрмәтенә берәр тост әйтеп җиффәр!

Ш а к и р *(бокал тотып)*. Ярар, әйтәм алайса. Хөрмәтле... әй... милләтле... әй... милләтсез хөрмәттәшләр! Бетмәгән икән әле Шакир Хәйбуловский. Кадерен белүчеләр бар икән... Теге дөньяда ниләр бар икән. Мин дә бер күреп кайтыйм... Хуш, Хәйбуш! Хушыгыз! Сезгә дә уңышлар телим!

Чыга. Сәнифә моңсу җыр башлый, башкалар аңа кушыла:

Күңелләр тирән булса да,
Кесә яклары сай, буш.

Хуш, Хәйбуш!
Үзеңнең җырың җитмәсә,
Безнең җырларны да куш,
Хуш, Хәйбуш!
Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде чит илгә,
Хуш, Хәйбуш!
Китмәс идем мин чит илгә,
Яшәү бигрәк читен лә!
Хуш, Хәйбуш!

Сәнифә. Киләләр! Миңа да хәбәр алып киләләр!
Абдул. Миңа да!
Хаккый. Миңа да!
Сәнифә. Миңа да! Париж!

Тайфур керә. Башын игән, борчулы.

Тайфур, Парижга кайчан очабыз?
Абдул. Мин бармы?
Хаккый. Мин?
Сәнифә. Жан Дустэн кайда?
Тайфур. И егетләр, иптәш-әфәнделәр... Париж турында хыялланмагыз да! Без биргән исемлек расланмаган. Жан Дустэнга икенче исемлек биргәннәр.

Һәммәсе хәрәкәтсез кала. Сәнифә һуштан яза, аны күтәреп торгызалар. Ерактан моңсу җыр ишетелә:

Китә инде, китә инде,
Китә инде кораблар,
Хуш, Хәйбүш!
Бәлки бөтенләй кайталмам,
Тәрәзә ачып карап кал,
Хуш, Хәйбуш.

*1993—1995*

## СӘХНӘДӘ КУЕЛГАН ӘСӘРЛӘР

**«Ак калфагым төшердем кулдан...»** Драма. Башкорт дәүләт академия театры. 1991 ел. Режиссеры — *Рифкат Исрафилов.* 1994 елда театрның гастрольләре вакытында Казанда да күрсәтелде.

**«Безнең эти — мировой»**. Комедия. Кәрим Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры. 1991 ел. Режиссеры — *Илдар Хәйруллин.* Шул ук елны Минзәлә татар дәүләт драма театрында куелды. Режиссеры — *Ленар Садрыев.*

**«Гашыйклар тавы»**. Драма. К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры. 1992 ел. Режиссеры — *Ленар Садрыев.* Повесть варианты шул ук елны Чаллы татар дәүләт яшьләр театрында куелды. Режиссеры — *Фаил Ибраһимов.*

**«Хуш, Хәйбуш!»**. Комедия. Казан татар дәүләт яшьләр театры. 1998 ел. Режиссеры — *Ленар Садрыев.*

## ЭЧТӘЛЕК


Безнең әти мировой

3

Ак калфагым төшердем кулдан

42

Гашыйклар тавы

81

Эзләдем, таптым, югалттым

114

Хуш, Хәйбуш

148

Литературно-художественное издание

Илдар Юзеев

*(Илдар Гафурович Юзеев)*

**ТЕАТР ПОЭТА**

Пьесы

(на татарском языке)

Редакторы *Х.К.Ибраһимов*
Рәссамы *Й.М.Вәлиәхмәтов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *З.А.Николаева*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән

Оригинал макеттан басарга кул куелды 21.01.2002. Форматы $84\times108^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 10,08+форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 11,34. Нәшер-хисап табагы 10,71+форз 0,36.
Тиражы 2000. Заказ Б-15.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы
дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.